
Zinnur
Mansurov



ЗИННУР
МАНСУРОВ



# Җәрәхәтле йөрәк җылырак

ШИГЫРЬЛӘР
ҺӘМ ПОЭМАЛАР

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2003

УДК 820/89(470)
ББК 84(2Рос=Тат)-5
М23

**Мансуров Зиннур**

М 23 Җәрәхәтле йөрәк җылырак: Шигырьләр һәм поэмалар.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2003.— 448 бит.

Танылган шагыйрь Зиннур Мансуровның әлеге китабына әдәби җәмәгатьчелектә уңай бәя алган шигырьләре һәм поэмалары тупланды.

ISBN 5-298-01264-7 © Татарстан китап нәшрияты, 2003

## *Чәркәдәге чәнечке*

*Мансуров, закадычный друг,*
*Надень венок терновый!..*
*А.С.Пушкин*

*Сәламеңне алдым әлмисактан —*
*ничә еллар, ничә яздан соң!*
*Аллаһыдан узып... Әүлиядәй,*
*язмышыма өстәп язгансың.*

*Фәрештәләр шигъри фатиханы*
*пышылдаган миңа бишектә.*
*Алмашынган төсле, адашларым*
*елагандыр шулчак биш йортта.*

*Шигърияткә сыя шәригатькә,*
*тотыйк, диеп, шушы бер денне, —*
*шәрафәтле Хәйям шәрабенә*
*имезлегем манып бирдеңме?*

*Вәсвәсәгә салды «вәхи»ләрең —*
*(мин дә Раббымызның бер колы).*
*Тыгылгансың минем тәкъдиремә*
*башланмаган гасыр аркылы...*

*Китабыңны кат-кат актарганда,*
*үз-үземә әллә фал ачтым?!*
*Ырымланган битләр арасында*
*гөлчәчәген күрдем... Парнасның.*

*Тамгаланган серле такыядай,*
*агып төшкән күпме җәй аша!*
*Язмышыма үзем җайлашаммы,*
*әллә язмыш миңа җайлаша?!*

*Исемемне атап искәрткәнсең,*
*хәбәр биргән кебек гаиптән.*
*Чәнечкеле таҗның сөенчесе*
*тоташ газап, тоташ гамь икән.*

*Карулашмыйм хөкем карарыңа —*
*тоеп яшим аның бар ямен.*
*Чәркәмдәге һәрбер чәнечкене*
*йөрәгемә күмеп барамын...*

*Исемемне укып исәйгәнмен,*
*рәхмәт инде сиңа, җан дустым!*

*...Әлмисактан килгән сәламеңне*
*чынга алып әллә ялгыштым?!*



# І БҮЛЕК



## *Аллаһ бүләге*

Азга гына сорап торам Күктән
ерак малай чакның бар көнен.
Төшләремне ялгап өнн әремә,
хәтер сурәтләрен барлыймын.

Төенләнгән җете тасмаларның
тартыйм икән кайсы очыннан?
...О Илаһым! Печән олаулары
чыгып килә буран эченнән.

Җәйге болын үзе күчеп кайта,
саклап кара аны халыктан —
яшеллеккә сусар яшьтәшләрем
печән йолкып кала һәр йөктән.

Могҗизага ничек ымсынмыйсың,
җәннәт үләннәре каршыда!..
Олаучыдан ертлач оланнарга
эләккәли ачы камчы да.

Ә мин... эчтән генә әйтәм шуны:
«Баскын дуслар»ымнан ваз кичәм;
дөньяныкын талап алуларда
түгел бугай минем вазифам...»

Ап-ак көрттән калкып дәште кебек
Хозыр пәйгамбәргә тиң кеше:
«Борылмада печән олавыннан
төшеп калды... сиңа тиеше!»

Ишарәгә бик үк ышанмадым —
нинди мәгънә мине алдауда?!
Кабатлады: Аллаһ бүләкләре
булыр әле, имеш, алда да...

...Төшләремә өннәр төшендерде,
аныклады Картның тел-ымын.
Карда яткан учма акбаш* өчен
сабыр гомрем буе түлимен.

---

* Акбаш — пәйгамбәр чәчәге.

## *Чистару*

Кер күтәрә алмас ак бүз
кабат ничек агара?

Терекөмеш туңар җилдә
катып-өшеп агара.

Кер күтәрә алмас ак бүз
кабат ничек агара?

Кар эчендә, көртлек сыман,
туңа-уңа агара.

Кер күтәрә алмас ак бүз
кабат ничек агара?

Тимер кертактаның сырын
ашый-ашый агара.

Кер күтәрә алмас ак бүз
кабат ничек агара?

Бәләк һәм таш арасында
мең кыйналып агара...

Бер тапланган күңел, әйтче,
кабат ничек агара?..

# *Йөз суы*

Ай-яй, авыр — саклап яшәү
мөлдерәмә йөз суын.
Кан койса да, түктертмичә
тоткан аны йөз буын.

Аз булганмы җәлладларның
башны чабып өзүе?!
Ә барыбер тезләнмәснең
түгелмәгән йөз суы.

Сындырырга әзерләр күп
мәгърурларның төз буен.
Түгелсә дә, Җир йөзеннән
бер тап юсын йөз суың.

# *Дүнү*

Дүнә дөнья, дүнә денсез дөнья
дуамаллык тулы бер өйгә.
Әллә кайда җиде бажа улый:
«Бөрадәрләр идек бүрегә...»

Абыеңны, Йосыф, абайладым
(килеп җиткән ничә ел аша) —
әртиләндә һәрбер астыртынга
канлы күлмәк тегеп өләшә.

Дөньялыкны денгә димләгәндә,
хәтта анаң сөте каралыр.
Сукыр тәкә булып хаклык эзли
картлар йортындагы король Лир.

Җантаһире белән Җанзөһрәсе —
әллә ничек бүген ят алар;
сыендырган газиз сандыкларын
урталайга... кисеп яталар.

Үги кызың, дөнья, өйгә кайтмас,
Айдан иңмәс инде без барда.

Искитәрлек: әллә Иисусыңмы
кадак сатып тора базарда?!

## *Гарештән иңгән кызгану*

Әгәр дә михнәттән укмашып,
күкләргә тоташкан тау булса,
һәм шунда Аллаһның бәллүргә
әйләнгән күз яше табылса (?!)

Тынгылык бирмәстер бер сорау:
«Ни өчен тамган ул, кем өчен?»
(Көфер сүз сөйләсәм, истигъфар —
гөманым бәгырьне кимерсен.)

Вәләкин уй-исәп йөртүдән
ничекләр тыелып калыйм мин?!
...Аллаһның күз яше тамгандыр
кызганып бәхетсез кавемен...

## *Тартар*

Әүлияча әйтүләрдә
ишарәле өн ятар.
Көлешәләр колагыма:
«Бер тартарга дөнья тар...»

Искәртүнең астыртыны —
булам кайчак гарык та.
Кинаяләр кыйнаштыра
шәрык белән гарептә.

Кыйтгаларда — кайтавазы,
җанны талкып моң ага...
Канатыңны канатсалар,
сыярсыңмы дөньяга?!

Болгардагы болынынннан
киткән затмы ден сатар?!
Илаһ ямь бар әйтүләрдә:
«Бер тар-тар-га дөнья тар...»

# *Киек Каз Юлы*

Телебезнең сихри тылсымнары
иңгән йолдызлыклар аз сыман.
...Болгарларым сине барлагандыр,
туфрак киткәч аяк астыннан.

Шәм-шәрифле җиһан шарлавыгы,
җанга савыласың чыннан да.
Татарларым сиңа тартылгандыр,
шахта терәүләре сынганда.

Арабызда, аңлыйм, аргамаклар
кичә алмас бик күп ел барын.
Тоташтыра алган татарларым
сиңа хәтта лашман юлларын,
тәкъдирендә язган юлларын...

## *Рояльнең кара телләре*

Хәтерлимен урыс пианистын
йокы алмас көзге төннәрдә.
«Уйнар өчен сезнең татар көен
җитә,— диде,— кара телләр дә...»

Болдырымнан күзлим болытларны —
охшый кайсы кара рояльгә.
Кара телдән ничек акка күчеп,
җылауларга якты җыр ялга?!

Үз-үземә әйтәм өзгәләнеп:
«Шушы хакта бүген уйлан син!..»
Качкыннарның ачы «Карурман»ы
акта гына ничек уйналсын?!

...Бүлмәңдәге рояль телләренә
шомырт чәчәкләре сибәрмен...
Яктырырмы кара язмышлардан
кан-яшь кебек саркып чыгар моң?..

# *Баш*

**Җиде тишекле тукмак...**
*Кырым татар халкы табышмагыннан*

Борынгыдан бәргәләндең,
җиде тишекле тукмак:
кавемеңме кабахәтләр
җирдән себереп түкмәк!..

Ыруыңны, артыксынып,
гүргә терелəй тыкмак.
Орылудан арынмадың,
җиде тишекле тукмак.

Мәскәүләрнең мыскыллавы —
тагы якадан тотмак.
Диварларны дөбердәттең,
җиде тишекле тукмак.

Ишетмәгән ишекләргә
әйттең кан-яшьле такмак;
тораташлар төшенгәндер,
җиде тишекле тукмак.

Милләттәшең мәйданнарда,
янып, яңадан тугмак.
...Табышмактан тәшвишләндем,
җиде тишекле тукмак,
кагылудан-сугылудан
җитмеш тишекле тукмак!..

## *Чаң*

*Поляк шагыйре*
*Роман Гожельскийга*

Чаң кагалар, чаң сугалар,
чаң кыйныйлар даң да доң.
Чаңга авыр булганлыгын
яши-яши аңладым.

Саңгыраулар кыңгырауны
кирәксенми, дисәк тә,
кайвакыт чаң, ярылганчы,
кат-кат дәшеп кисәтә.

Бик кыендыр кыйналулар
шулай өсте-өстенә.
Сызса сыза, үзен-үзе
кызганалмый һич кенә.

Бәгырьләрне авырттырып
бәргәләнә чаң теле;
Җирнең һәрбер тетрәнүе
үтә җаны аркылы...

Чаң кагалар, чаң сугалар,
чаң кыйныйлар даң да доң.
Өзгәләнер йөрәкләргә
авыр —
шуны аңладым.

# *Екатерина II каретасы*

(Антигид монологы)

> Әби падишаның күт җылысын
> хәтерләгән затлы карета...
>
> *Р. Зәйдулла*

Мәскәүнең яулыклы патшасы
ул нинди кадерле тутаң соң?
Ыргытып калдырган арбасын
түрендә өф итеп тотасың.

Күкләрдән Илаһың иңдергән
яшенле фаэтон түгел лә.
Татарым, тәлинкә тотканда,
никадәр йөз суың түгелә!..

Тел төбен аңлыйсың киләме —
нигә ул калдырган арбасын?
Эшсөяр татарга алманча
боерган: җигелеп arbeiten*!

«Чыңгызхан токымы», хезмәттә
шулкадәр басымчак, юаш син;
балалар сабынын күбекләп,
падишаһ арбасын юасың.

---

* Arbeiten — эшләргә (немецчадан).

Юасың гөнаһлы әбине,
(гашрәттә таплана алтын да).
Кемнәрнең пычрагын күрисең
син... сират күпере алдында?

Балалар сабыны юармы
көпчәккә чәчрәгән кан табын?
Карета эзеннән үткәнгә
ничә кат әйләнеп кайтамын...

Йә, җитәр. Үчләнмим. Калганы
хакында авыртсын ар башы.
...Болытлар өстендә каңгырып
йөрәдер Акмуллам арбасы...

# *Илбакча һәм колонист*

*Кырым татар шагыйре*
*Риза абый Халидкә*

...Хуҗа булып алган, ә үзенең
агачларга, сизәм, җаны ят.
— Туфрак кына ачы...
(Нишләтәсең —
өлешеңә тигән ганимәт.)

Сорамакчы булам: «Нигә ачы?» —
бәгыремне шундый уй кисә.
Ашламага бәйләп аңлатасын
алдан белеп торам югыйсә.

— Бакчамдагы бадәм* ачыланды...
(Шулай була җирдә сер үлгәч,
шулай була, ачы кан-яшь түгеп,
туфрагыннан халык сөрелгәч.)

---

* Бадәм — миндаль агачы.

## *Ай кызына төбәлгән уй*

*Халык санын алган чакта*

Күкрәүләргә күнгән күңелемне
айкалдырдың әле, Ай кызы!..
Милләтеңне гүзәл мөлкәтеннән
«тарлык-татарлык»мы аерды?

Нәфесләнеп, нәсел-нәсәбеңнең
бергә туплар чакта бар көчен,
сөелүдән сөргән өммәтсезләр
Мәрьям анабызның варисын.

Шушы төндә, ахры, үги ана
яфрагына иртә кар яуган...
Таралгандыр тату татарыбыз
үзен-үзе шулай каргаудан.

Кардәшләрне төрле кыйтгаларда
Сак-Сок сагынуы саргайта.
Йөрәккәең өшер ераклыкка
сөрелгәнсең, сеңлем, син хәтта.

Барланганда милләт балалары,
тагын алынмыйсың исәпкә!
Түгәрәкләү өчен түгелгәнне
җитми бирәү — булмый нишләп тә.

Бәгырьдәге бәйдә бәргәләнгән
балаларың җитми, Ай кызы!
Мәхрүмият сиңа мәхәббәттән
табышмыйча «Талак!» әйттерде.

Киленлеккә сине килешкәндә,
түләр иде татар ун калым,
сөрелмәгән булса Сөембикә,
чукындыртмый калса угъланын...

Болгарымның кызы булмагандыр
кемнең генә «асыл ярты»сы.
Тәгәрәмәс өчен түшәгеннән,
ырусызлар сине «яр» итте.

Кызларыңны алар кәнизәккә
әйләндергән — яңа түл кирәк...
Барланганда милләт балалары,
булса икән дөньяң түгәрәк.

Оланкайлар кая олагышкан —
көтелгәннән күпкә ким чыга.
...Сантыйланып беткән санаучылар
исәпләми сине кешегә.

Мәэюсләнгән күзен мөлдерәтеп,
сиңа бага, сеңлем, чал кавем.
Күрәләтә нәсел корыганда,
нигә кирәк гыйффәт саклавың?!

Көтмәгәндә кызып китүемә
ачуланма инде, Ай кызы!
Барланганда милләт балалары,
күңелемне нидер айкады.

## *Һиҗрәт*

*Давыт Көгелтиновка*

Идел өсләп очып кына килдем,
(рәхмәт юлларыннан төшмәмен).
Җирдә мине Давыт үзе көткән —
әллә өндә, әллә төштә мин!

Күктә кече йорты* була торып,
пәйгамбәрләр намен йөртсә дә,
шулпа мисле милли чәе белән
кунак итте әдип юртада.

Даладагы барлык лаләләрне
килешемә чәчәк аттырган...
Чалкан яткан олуг затның чәчен
чуалтмакчы була ак кылган.

Газиз улын шулай җиргә бәйләп,
җибәрмәскә тели күгенә...
Затлы дәргаһ салып биргән илбаш —
яшәр урыннары күп кенә.

Калмыклары читкә куылганда,
туфрак киткәч аяк астыннан,
килешкәндер шагыйрь: «килмешәк»кә
сыяр почмак җирдә аз сыман.

---

* Д.Көгелтинов исемендәге кече планета күздә тотыла.

«Җиде ятта,— ди ул,— ятим чакта
күккә күбрәк, күккә таяндым...»
Аксакалның минем уйлаганны
уйлап ятуына таң калдым.

Каһәрләнгән язмыш кабатланса,
(ялгыш әйттем — гафу ит мине!) —
кылганнарсыз калган калмыгыңны
планетаңа алыр идеңме?

Картның шулай күккә озак карап
ятуында берәр сер бармы?!
Нинди һиҗрәт, юк, юк, эчтән генә
бирдем аңа мондый сорауны.

Ниләр уйлый икән дала угълы,
искә төшерәме Алласын?
...Офыктагы сарык көтүләрен
кара болыт суырып алмасын!..

«Күчеп булмый!» — диеп, —
«Күчеп булмый!» —
Давыт агай эчтән йөз әйтте.
Иделемә кайтып егылырга
үзе мине... күккә озатты...

# *Фәрештәгә әверелү*

Әүвәлгеләр кылган әүлиялык
әллә ялган шунда, әллә чын:
шәһит киткән синең һәрбер затың
ничек фәрештәгә әйләнсен?!

Хаталанмас милләт хадимнәре
әллә шуңа ихлас ышанган:
мәликлеккә дәгъва әйләгәндәй,
кемдер бер янганда өч янган...

Яугиреңә ясин укылганда,
көндәшләрме әллә көлешә:
«Күгәрчендәй ак-пакь кавемнәргә
фәрештәлек күбрәк килешә,
фәрештәлек күбрәк килешә...»

Юансыннар, имеш, югарыдан
Аллаһ вәхиләрен иңдереп...
Кемнәр безгә канат текмәк була,
әҗәл белән иңгә-иң торып?!

...Кардәшләрем рәхмәт юлларының
томанына кереп күмелә.
Бәхетлеме шулай фәрештәгә
әверелгән халык —
кем белә?

## *Ачык рояль*

Эчкә күзем төшә —
дулкыннары йөгерешә...

Йөрәгем «жу» итте,
баш әйләнеп китте;
тетрәндереп җанны,
янар тау авызы
актарыла, кайный!

Эчкә күзем төшә —
менә кайда бу дөньяның
иң-иң тирән төпкелләре!
Ачылган бер олы яра —
буй-буй нерв җепселләре...

Сыкрый, ярсый, өзгәләнә
кешелекнең җәрәхәте!..

Ачык рояль...

Моң дәрьясы ягасында
басып тору, йә, рәхәтме?!

## *Төрмә эчендәге читлек*

*Һадига*

Утырабыз икәү өтерманнең
түрәсендә ихлас гәп сатып.
Тоткын кызый кереп чыкты шулчак,
читлектәге кошны ашатып.

Төрмәбашым сөйли тормыштагы
үтә кызык «эшләр» турында.
Җаным тыныч түгел: хуҗа булып
гомер буе ничек тор монда?!

«Өеңдәге кебек иркенәеп
утыр»,— ди ул... шушы чит йортта.
Озак кына сайрап торды кошчык
төрмә эчендәге читлектә.

Аңлый алмый мәхлук, монда яшәп,
икеләтә мәхбүс булуын.
Йөрәк дертләп куйды — әллә инде
ошамады аңа бу уем.

Өтермәндә озак утырмабыз,
без бит кунак кына ич монда.
Хәтта ирек үзе яши әле
ничә катлы читлек эчендә.

Алгысынган рухың алданмасын —
чып-чын хөррияте еракта.

Читенсенеп, кысан читлегеннән
чыга алмый гаярь йөрәк тә...

Сәйрандагы коштай сайраганда,
кенәригә карап, ым кагам:
«Әллә монда чынлап җайлы микән
сакланырга вәхши дөньядан?!»

Иректәге кошны өркетәләр,
ничек кенә аң бул, аң булма.
Нигә әле капыл искә төште
юлда үтерелгән Акмулла?

Чәчәнебез казна читлегеннән
ашыкканмы әллә чыгарга?!
...Утырабыз икәү өтермәндә,
уйларыбыз сыймый чик-ярга.

Ишетелеп тора өшеттергеч
тимер ишекләрнең чың-шавы.
Утырасың хөкем ителмичә —
менә нинди язмыш сынавы.

Күпме черки, кордаш, каның эчте,
үтермәдең — имеш, җәлләтә.
Синдәй затлар кирәк: саксыз булмый
хәтта тәмуг белән җәннәт тә...

Зинахурлар тулы зинданында
өч-дүрт сәгать мин дә утырдым.

Яшергәләп килгән языгыма
җәза булсын — мин дә мут идем.

...Тәрәзәгә терәп тарттырылган
«тимер кояш» аша төн бага.
Чыгыйк әле
иблис авы белән
челтәрләнеп беткән дөньяга.

Өйдә тагын тимер ишек көтә,
инде моннан, ярый, чыктык та.
Шундый серле карап калды кошчык
төрмә эчендәге читлектә...

## *Кош очар биеклек*

Бер дә өстән карама, дип,
намус гел тыеп тота.
Ә үземне тоям кайчак
кош очар биеклектә.

Пеләшемә чия төше
төкерер, диеп көтмә.
Мондый уйны алып менмим
кош очар биеклеккә.

Һәм уйлама: башыбыздан
йөрмәсме биеп, дип тә.
Түбән җанлы булып кара
кош очар биеклектә.

Чүп кой, имеш, шул ләйсәнле
болытка тиеп кит тә...
Сөю яши, җыр туадыр
кош очар биеклектә.

Җир белән күк арасында
илаһи бөек нокта!..
Җир — балалар рәсемедәй —
кош очар биеклектән.

Дөрес, тормышваклыклары
чабудан бик еш тота.
Ничек булса да калырга
кош очар биеклектә!

Җир белән күк арасында
илаһи бөек нокта!..

# *Ике еглау*

Поэма

## **Башлам**

Җиде икълим чиген иңләп иңрәү йөри,
иңрәү кайта, кайта ничә ел аша.
Мәшрикъ якны тоташтырып мәгъриб якка,
кара-каршы ике бикәч еглаша.

Хәсрәтләргә чумган дөнья хәтерләми —
мондый аглау юктыр кебек бер җирдә;
кыйтгаларны айкап йөргән кайтавазы
үкси-үкси бәрелешә бәгырьдә.

Ике якта гомер сөргән чит-ят затлар:
берсе — Идел, берсе Дунай буенда.
Илләрендә көйләп-көйләп илерәләр,
үзәк өзгеч аһ-зар бардыр бу моңда.

Кенәзбикә, килешмәүчән килендәштәй,
ханбикәдә танып ала көндәшен...
Итәк тотып энҗе-мәрҗән җыйган төсле,
фәрештәләр санап бара күз яшен.

Йөрәгеңнән гамьнәр савып йөдәгәндә
килми калмый, килми калмый кан исе.
Бәгырьләрдә Вакыт... Хәтер бәрелешә,
хаклы итеп тоя үзен кайсысы?..

Ил-йорттагы барлык, барлык еглауларны
күмеп китә икәвенең еглавы.
Йодрык аша саркып чыккан ачы яшькә
кушылгандыр йөзәр-меңәр ел давы.

## 1

Сөембикә

Егла, халкым, әйдә, егла, халкым,
минем белән бергә еглачы.
Ходайдандыр бүген хадимәңә
тәкъдирләнде яңа юл башы.

Өметләнеп дәшәм: өммәтемә
әҗер килсә, куып йөрт кенә!
Һиҗрәт итү язган икән миңа,
әсир төшеп урыс йортына.

Килененңне, илем, килешенеп,
канлы туйга калым иттеләр, —
еглаганда... Казан нигезенә
салып калдырылган эт көләр...

Бүген инде, угълым, миңа кушыл,
күзләреңнән яшьләр түгелсен.
Сыктавымның асыл сәбәпләрен
әле аңлар яшьтә түгел син.

Ирексезләп ачам йөрәгемне —
тыңла җәрәхәтле кыл зарын.
Үзенеке итеп үзгәртмәкче
залим патша Аллаһ колларын.

Урда рухы бүген сызлый булыр —
җуйдык бугай инде барсын да.
Хөрлек таҗы ничек тора алсын
табан ялаучылар башында.

Канлы чыкка батып бара җирем,
Идел-йортның хәзер язы... көз.
Фәрештәләр, гамәл дәфтәремә
күз яшенә манчып языгыз!..

* * *

Чәчен йолкып, битен тырнап, кулын чәйнәп,
бузлый-бузлый еглый барча кыз-кыркын.
«Мәҗүсидәй хәттин ашып мавыкмагыз!
Җитәр!» — диеп, ник бер сәед кычкырсын.

Төшләрендә энҗе күреп тәшвишләнү
түгел икән, түгел икән яхшыга.
Егламаган ташлар юктыр ханкирмәндә,
бичураның күзеннән дә яшь чыга.

Йодрык белән сөртә сабый яшьле битен,
күкрәгендә кемдер елан җылыта.
Кыйтгалардан көйле иңрәү кайтарыла,
аһ-зарларны арлы-бирле җил йөртә.

**2**

Я р о с л а в н а

Гыйш-гашрәтле яшьлек бәйрәмнәре,
җитәр инде, озак көлдертте.
Еглашыгыз, кызлар, еглашыгыз,
яшебезне кояр көн җитте.

Яшьнәп торган төнге күкнең сүзе
канлы сөңге белән язылган.
Каргышыбыз төшсен каракошка —
безнең газизләрне ят кылган.

Канатлансын кыпчак кәнизәге —
дала хөкемедер бу яшен!..
Сиңа дәшәм, Игорь, таулар аша:
сизмәдеңме шулай буласын?..

Мәрхүм әнкәм төшкә кергән иде,
җиргә җәеп кара яулыгын.
Иртәгесен кояш тотылганда,
күләгәләр кисте яу юлын...

Иләмәннәр белән киңәшмичә,
качып киткән кебек ашыктың.
Көнчел күршең Көнчак ханга барып,
өрми генә утлы аш йоттың.

«Онытырмын,— дидем,— ятимлекне,
әгәр сине хәләл ир итсәм...»
Өзелерме, бәгърем, зынҗырларың,
күз яшьләрем белән эретсәм?

Юылырмы безнең еглаулардан
бәгырьдәге хәсрәт дуены?..
Үксезләрем ничек үксемәсен —
иртәләде соңгы туй көне.

Ахириләр, ягез, ахыргача
ахылдашыйк — күкләр ишетсен!
Адәм затын аяп еглый алган
фәрештәләр безне иш итсен.

* * *

Дерелдәшә кирмән-кала диварлары —
хәтта ташлар түзә алмый кан-яшькә.

Егылышып бөтен дөнья еглаганда,
көндәшләрең әверелә гамьдәшкә.

Җарияләр иңри башлый ирексездән,
коллыктагы җәберләрен онытып.
Мәдхияләр укып йөри мәшһүр Баян —
матур төшен күрсәтмәкче өн итеп.

Тавышында кайгы-шатлык тынышкандай,
әллә еглый, әллә җырлый бер кортка.
Сусыз дала кылганнары сәҗдә кыла
болытларның яшен койган бөркеткә.

Шомландырып яшьләр тама шәмдәлләргә,
еглый торгач дәргаһ-йорттан кот качкан.
Коргаксыган иске арба шыгырдавы
иңрәү булып кайта Дәшти Кыпчактан.

Җиңелүнең ачы яше җемелдидер
сәргаскәрен җуйган атның эзендә.
Угъланнары язмышыннан угаланып,
ачулана бөек кенәз үзен дә.

Җәберсенгән кальбе белән еглаганда,
үзен һәркем әүлиядай пакь саный.
Кирәк чакта яудаш булган гаярь кавем
хәзер инде әшнә түгел — «Поганый!..»

...Урамдагы мөлдерәмә канаулардан
әллә нинди кан-яшь катыш су ага.
Таралыша ыңгырашу тавышлары,
Куяба*дан кайтарыла Сула**га.

---

* К у я б а — Киев шәһәренең кыпчакча әйтелеше.
** С у л а — Днепр елгасының сул кушылдыгы.

Дала илен иңләп үтә бәгырь өне,
Җигүлетау яшененнән ут ала.
Казансуга килеп җиткән күкрәүләре
ачы нәгъръ ормак булып уктала...

### 3

С ө е м б и к ә

Аһ-зарларны бергә очраштырды —
әллә дөрестән дә Җир тармы?!
Миңа тиңдәш булып еглар өчен,
Ярыслауна, яшең җитәрме?

Сагышларны сыгып сыктаганда,
сабырлыклар булмый күпләрдә...
Ике күздән ташып чыккан яшьне
еглап бетермәстер күкләр дә.

Я р о с л а в н а

Безгә инде, бикәм, шулай язган —
азрак көлеп, күбрәк егларга.
Әмма синең кебек горур затлар
җебеп җавап бирмәс юк-барга.

Тыеп тоткан күпме хәләл яшең
сабыр бәгыреңдә тулгаклый...
Ачылуым өчен ачуланма —
толны кыен чакта тол яклый.

Башкарактыр иман багышлавым,
бүтәнчәдер күзем, кашым да, —
кайгы безне тигез күрә булыр
ихлас яшь бөртеге каршында.

С ө е м б и к ә

Бөтен галәм дәррәү көлгән чакта
күренербез игез булып та.
Синең яшь тә, бәлки, бардыр әле
Казан өсләп йөзгән болытта.

Сорасалар еглау сәбәпләрен,
безне кемнәр генә иш санар?
Дөресләсен хәсрәт дәрьясының
төбен күрә алган инсаннар.

Фәрештәләр безнең күз яшьләрен
үлчәп тормас мәхшәр көнендә...

Я р о с л а в н а

Кайгыларга саксыз кагылмыйкчы —
хакы бардыр анда кемнең дә.

Йөзеп китә бара фани дөнья,
еглап башланмаган көн әздер.
Исәнгерәп ята әсирлектә —
ул бит... кенәз кадәр кенәздер!..

С ө е м б и к ә

Җирдә сынау үткән һәрбер бәндә —
кылган гамәленең откыны.
Аңлатачак әле Аллаһының
җавап ала торган төп көне.

Борын чөеп, бакчы, сөңге кадый
кыпчак даласының читенә.
Очлым белән Донны эчеп кую
аның өчен, имеш, чүп кенә.

Ханның атын асылташлар бизи,
аткан угы, әйе, көмештән.
Балбалларның алтын билбавында
кылыч беләүләргә кем кушкан?

Бүрегендә кайсы бөрадәрең
каракошка оя ясаткан?
Чынлык өчен, әйдә, санап карыйк —
кемнәр башлап күбрәк яу чапкан?..

Әле кайчан гына Күбәк ханның
әсирлектә башы җуелды.
Яшьләнгәндә дала җәмшәннәре
сездә бәйрәм, уен, җыр булды.

Галибанә «җанлы ганимәт»не
яугирләргә бүлеп биргәндә,
кенәзлекнең колын кызганудан
еглап җибәрдеме бер бәндә?

Ничә ишкәк белән Идел суын
чайпалдырып кайтты кайнишең?
Хаталанса халык хәтерләре,
балык хәтерлидер кан исен...

Ярославна

Күңелдәге тутын күрсәтмичә,
йөри, әнә, Башту җыр әйтеп.
Һәрбер шәйне кабул итмик әле,
күз яшьләре аша зурайтып.

Орышларны уйлап чыгармадык,
шаны — иргә, яше... безгәдер.
Ике илче кебек, хаклык эзләп
еглашабыз менә бергә-бер.

С ө е м б и к ә
Еглаганда, сиңа элгәрләрең
инде күптән мәгълүм сер әйтер:
кайнар канның җирдә ачы яшькә
кушылмаган көне сирәктер.

Я р о с л а в н а
Олы халык сугыш белән яши,
ыру... узмый, диләр, бузадан.
Узаманлы дөнья үзгәрмәстер,
үзгәрмәстер безнең бу зардан.

Ничә тапкыр төштә кошлар күрәм —
әле агын, әле карасын.
Савап арты савап эшләп кенә
милләтеңне саклап кара син!..

С ө е м б и к ә
Бәләкәйдән адәм балалары
ияләнеп үсә кан-яшькә...

Я р о с л а в н а
Берәр газиз башны... кисеп кенә
илтә көндәш үчле көндәшкә.

Кылыч сорап торган чарыс затка
фатиханы бирми ил генә, —
Мөхәммәднең яугир тудыкасы
кулын салган, имеш, иңенә.

С ө е м б и к ә
Төрле хәлләр була: колмак бата,
ә таш йөзә башлый еш кына.
Беркетелгән антлар бозылганда,
җәясеннән ук та ычкына.

Иделләрне эчеп бетерүләр
иман-денгә ничек ялгансын?!
Очлым белән тәгам җияр ирнең
комсызлыгы арта яудан соң...

Җитеп торыр, мондаш, авыр чакта
сиңа хөтбә укый башладым.
Бетеренмик әле битәрләрдән —
еглар, көләр өчен баш лазим.

Күлмәк җиңең бигрәк озын икән —
кипмәс әле, кипмәс тиз генә.

Ярославна

Кара кашлы зур күз яшьле була,
дөреслеген җаным сизенә.

**4**

Чарт-чорт итеп багбөстанда борчак ата,
кипкән сәрви кузаклары ярыла.
Тып-тын очкан күбәләкнең өнен алып,
ханзираттан ыңгырашлы зар килә.

Болынлыкта бертуктаусыз бөтерелгән
шәүлегәннәр бүген яңгыр теләми.
Төрбә ташын соңгы тапкыр сыйпап сыктый
ирдән калган, илдән калган тол җаный.

Иләмсерәп тулгый-тулгый еглауларның
кайтавазы ишетелә дүрт яктан.
Дивансарай диварлары дерелдәшә
үзәк өзгеч сәмум-җилле фөрьядтан.

Кан-яшь белән Аллаһыдан яклау сорап,
рәкәгатькә егылганда ил-ыру,
сыенырга тыныч почмак сайлагандай,
манарада гүләп тора илерү.

Бүре кебек берәм-берәм улый башлый
куркынычны сизенүче сак этләр.
Гаҗиз хәлдән бөтен гавам үксеп еглый,
бәкләр еглый, мирза, тархан, сәедләр...

Моңлы азан тавышына ачы сыктау
авазлары кушылганда мең авыр!
Камчы белән үзен-үзе кыйнап еглый
каберлекне саклап торган мөҗавир.

Баскын кенәз ничек шулай йомшый ала
чиксез кодрәт иясенә тиң чакта?!
...Дөге-дөге яшен түгеп еглый икән
корбанына якынлашкан тимсах* та...

Бөтен халык сыктаганда, берәү генә
авызыннан аждаһадай ут ата:
көндәшенең янып-көеп кансыравы
анда бары ләззәт кенә уята...

Ханбикәне көймә көтә Казансуда,
«шөһрәт-сыйлы әсирлек»кә илтергә.
Икълимнәргә ишетелгән еглауларның
газиз яше сеңеп кала ил-җиргә.

---

* Тимсах — крокодил.

* * *

С ө е м б и к ә

Ярдәм итче, Сафам, мөмкин булса,
Аллаһыдан җибәрт иштирак*!
Җырлау өчен ят та ярап тора,
еглаганда якын иш кирәк.

Игътибарлап тыңла еглавымны,
җавап бирсәң — җаным сизенсен.
Хан-солтаным, бөтен хатыныңнан
артык күреп мине сөйдең син.

Күрәсеңме урыс яугирләрен —
зиратыңда гына алты пар.
Биектәге сылу бикәчеңне
аккош төслүк атып алдылар.

Кяфер колы иткән канлы туйда
матурлыгым нигә кирәк соң?!
Манарадан атыйм йөрәгемне —
ахыргача янып көйрәсен!..

Бигрәк елгыр атта чабып үттең
тәхет белән ләхет арасын.
Ялгызыма бик күп калдыргансың
мәкер, гайбәт, шелтә, әр ашын.

Тәкъдиремне еглап тәфсирләргә
юктыр, бәлки, юктыр хакым да.
Кемгә сөйлим өскә авып торган
янартаудай кайгым хакында?

---

* И ш т и р а к — булышлык.

Козгыннарның көтмим кызгануын,
ярдәм өмет итмим чит ымнан.
Кемгә сөйлим, җанкач, үксез углың
аерылмый әле сөтемнән.

Нугай ерак, әйтмә, Кырым ерак,
һәм дә арабызны корт чаккан.
Миңа киңәш биргән күпме затның
әйтер сүзе чыга корсактан.

Монафикътай йөри мөэминнәрең,
шикле ладан исе аңкытып.
Менә шулар инде сөрә мине,
ирекләре белән ант итеп.

Варисыңны нинди вәсвәсәләр
көтеп ята икән тегендә?
Имәндереп тора иманнары,
кабул итә алмыйм телен дә...

Ялыгудан гаҗиз ялгызлыгым
синең ялгызлыкка кушылсын, —
ятимәңне алдыр ятагыңа,
җаннарыбыз игез кош булсын.

Ничә алтын анда ишек бавы —
үткәр мине гүрең түренә!..
Еглап ташкан зарлы Идел аша
алып китәр безне зур көймә.

Шатлык яше белән кайгы яшен
бүлеп торган юллар, аһ, ерак.
Һиҗрәтемнең зур-зур әҗерләре
сиңа булсын, илем — әлфирак!..

**5**

Я р о с л а в н а
Ятим җаның тоташ яра икән,
сиңа карап, мин дә җебенәм.
Сөзелешеп чыккан сүзләреңне
бүлим әле ефәк җеп белән.

Казаланып торган Казаныңда
әйтмәдеме татар кардәшең:
«Бездә бикә булып яшәр өчен
җитәр микән,— диеп,— кан-яшең?!»

Еглашабыз менә икәүләшеп,
еглашабыз инде кай заман.
Ышанамы синең яшьләреңә
тәкъдир атлы кырыс кайнанаң?

Мөлдер күзне сөртеп торыр өчен
яулык очы күбәү, җиң озын...
Хафалану тулы халәтемне
аңлый аласыңмы син үзең?

Ялгыз баштан ниләр кылып була —
син бит байтак тарттың ир йөген.
Әсир хәлен әсир белми калмас —
һәркем җандай күрә иреген.

С ө е м б и к ә
Еглауларны тиңләп еглауларга,
тиңдәш эзләр өчен юк хакым.
Тәкъдир кушып, әйе, ханча булгач,
хөрлегемне мин дә югалттым.

Каударланып сөңге кадамадым
башка мәмләкәтләр читенә.

Газиз илдән улҗа малы итеп
алып китә мине чит көймә.

Кенәзеңнең канлы барымтасын
аклап күпме генә аһ орма,
әсир төшү белән әсир алу
арасында бардыр аерма.

Барлап тормыйм барча корбан санын —
каракошлар тагын ит теләр.
Хәрамиләр ил-күз хозурында
ничә ханны тоткын иттеләр.

Мордарлыкның гарьле моң-зарларын
әрнеп кичермәгән җан бармы?
Череттеләр ерак әсирлектә
Габдел Латыйф, Илһам ханнарны.

Тагын күпме асыл затлар шулай
җиргә күчте коллык базында.
Үтәмешем киеп өлгермәде
әтисеннән калган таҗын да...

Ярославна
Әсирлектә кенәз Василийны
күздән яздыручы кем иде?

Сөембикә
Нахак яла безнең бавыр итен,
җитәр инде, байтак кимерде.

Миннән йөз кат өлкән була торып,
кайчак әле һаман бала син.
Кемдер файда күрер — сылтыйк гелән
кара эткә ак эт бәласен...

...Яуга шулай качып китәр кенәз,
безнеңчәләп әйтсәк, кылтык ул.
Анда сөрән салып яткан ирең,
әсир ителсә дә, кол түгел!

Ерактагы кыпчак җәйләвендә
җайсызлыктан бер дә ертылмый:
тели икән, ауга чыгып керә,
кичен, кымыз эчеп, җыр тыңлый.

Кенәзлектән поп та китертелгән,
учакларда көйри куз гына.
Улыгызны димләп йөрүләре
Көнчак ханның кече кызына.

Тоткын җайдак тиздән кайтып килер,
кылганнарның коеп чык-яшен...

Я р о с л а в н а

Кодалашу артык көендерми —
сиздем шулай килеп чыгасын.

Ярәшүләр кайчак ярашуга
китергәли Кара Болгар*да.
Нәсарины әһле мөселманнан
ерагайтмас әле болар да.

С ө е м б и к ә

Сөенимме, ханнар суешканда,
тамырдагы каннар сугышса,
Туранымның соңгы туруннары
баскын очлымыннан су эчсә?!

---

* Киев Русенең шулай аталган чоры да булган.

* * *

Ярославна

Ничә меңле гаскәр саклап тора
гайрәт чәчәр Казан кальгасын.
Олугларың патша калгаеннан
нигә шулай куркып калган соң?

Мәгърур таудай басып торган калаң
батып бара, әнә, аһ-зарга.
Ханбикәсен биреп җибәрүче
кавемеңне ничек аңларга?

Сөембикә

Ачынышып еглый алучылар
ишарәгә күчми шикелле.
Күзгә бәреп әйтик туры сүзне —
нигә сиңа андый шик килде?

Күңелемдә урын калдырмадым
нахак яла, кинә, кер өчен.
Гаепләсәм сөйгән милләтемне,
хаксыз әйтсәм — телем корысын.

Аллаһыга ярсып әләклимме,
кемгә шикаятьләр языйм соң, —
килен булып төшкән ятим илдән
«Талак!» әйтеп куса язмышың?!

Сатылырга безне өйрәтмәгән
Ага-базар, ефәк юллары...
Гаҗизлекнең ниләр күрсәтәсен
белә булыр, белә Ул бары.

Я р о с л а в н а

Сәерсенмә, зинһар, соравыма,
җанга тынгы гына эзлимен:
ханбикәсе, биреп һамаюн*ын,
саклап калган, димәк, үз илен.

Янып сөйгән газиз иле генә
ханбикәсен саклый алмаган...

С ө е м б и к ә

Алай зурдан кубып хөкем йөртмик,
гөман кылмыйк, узып Алладан.

Бәйләнмәгән безнең ихтыярга
иртәгесе көннәр гамәле.
Кемнәр генә аны саклап калыр —
җанда өмет түгел, гамь әле.

Бәхет кошы озак тора алмас,
тәхетеңә менсә үч-кинә...
Күзем йомган чакта юк-бар төшләр
сискәндерә шуның өчен дә.

Я р о с л а в н а

Кайнатамның зәңгәр шәрабенә
кемдер гүя энҗе төшергән...
Кенәзнеке бер дә куандырмый,
ә ханбикә нинди төш күргән?

С ө е м б и к ә

Ышанмаслык шайтан ишарәсе —
башкаеңа сәер уй иңәр:

---

* һ а м а ю н — бәхет кошы.

әүлиядай диван әһелләре
Хансарайда... «бишташ» уйныйлар.

Бисмилладан башлый басымчагы —
Аллаһыга, имеш, тапшыра.
Ханлыгымның асыл чүлмәгенә
берсе уйнап кына таш ора.

Әллә кайдан шомлы тавыш килә:
«Аңа...
Олуг Мөхәммәдләр бакты ла!»
Ташны юри генә ата кебек,
чүлмәк исә чынлап ватыла...

### Я р о с л а в н а

Үзәгеңә тия үзеңнеке,
гарьләндерә — ни хәл итәсең.
Бөялгәндер, беләм, бәгыреңдә —
каргап булмый туган ил ташын.

Төшләреңә кереп тәшвишләтә,
өнгә саркып чыга бу ачы.
Кан-яшеңдә юган ташларыңны
нигезеңә салып булсачы...

* * *

### С ө е м б и к ә

Байтирәкләр бездә башкачарак,
очып куна торган кош башка.
Язмышымның яшьле яулыкларын
элеп куймыйк әле кояшка.

Гарше әгъля, сизәм, күрми калмас
миндәй кайгыручы мөмтаз*ны...
Үз-үземне артык кызгандырдым —
синең күзләреңдә моң азмы?

Я р о с л а в н а
Байтирәгем еглый вакытлыча,
шунысына ничек түзәсе?!
Ханбикәнең хәле хәвефлерәк,
күпкә ачырактыр күз яше.

Ярга сыймас дәрья кебек аккан
хәсрәтеңдә булмый батып та.
Дөнья тоткан илең ничек шулай
башсыз калган кыен вакытта?

С ө е м б и к ә
Минем улым ханлык таҗын киде —
нигә чыгарасың исәптән?

Я р о с л а в н а
Карышкыдан кечек нарасыйны
аердыңмы әле имчәктән?

Ачыклавым өчен ачуланма,
ачындыра болар мине дә.
Кыйтгаларга китсен кайтавазым,
еглый-еглый кылам мең нида.

Олег каны, имеш, Чыңгыз каны —
һәлакәтле шан бар бу канда.

---

* М ө м т а з — башкалардан аерылып торучы зат.

Хакимлеккә хөкем ителгәнсең,
җаһил,
чирле,
сабый булса да.

Хаким булып торса шундый кенәз,
шундый солтан, патша, корольләр, —
дан-шөһрәтле илең дошманында,
димәк, иң дәһшәтле корал бар.

Илаһлыктан ерак иләмәннәр
тәхет менсә — халык интеккән;
томаланып ыру тамырлары,
вәйранлыкка күпме ил киткән...

Фәрештәләр чын-хак патшаларның
күрә, диләр, нурлы каймасын.
Татарыңның Тәңре тамгалаган
изгеләре бүген кайда соң?

Йортын нигә саклап кала алмый
Күкләр билгеләгән хакимлек?..
Кичер мине, бикәч, барсын бергә
тоташ гаепләргә хакым юк.

С ө е м б и к ә
Зәнки затлар инде ничә тапкыр
сабыема тешен ыржайтты;
кимсетмәче: ул бит нәбиләрнең
җенестәше булган ир заты.

Җанҗылымлы Игорь җәнапләре
аерылды мәллә имидән?..
Бирелгәндәй шайтан коткысына,
шулай әйтәм әле мин нидән?!

Я р о с л а в н а
Бәрәкалла, шуңа бәйләнгәнме
ымсындырып торган тәхет тә?

С ө е м б и к ә
Сөттән бизгән Ватан үксез кала —
бөтен хикмәт шушы тәүхид* тә.

Хатын терәк булыр газиз иргә,
ил терәге, шиксез, ир булыр.

Я р о с л а в н а
Әйтеп бетер инде — таҗга әле
безнең таифә дә ыргылыр.

Мәрьям ана чынын раслап бирсен:
тәхет басу безгә хәләлме?
Дөнья тотар өчен нык кул кирәк —
бүгенгеңдә шундый хәл әле.

Кинаяле сүзләр күңелеңнең,
әйдә, әрнүләрен кузгатсын:
патша булып торыр, җае чыкса,
тик идарә итмәс кыз-хатын.

С ө е м б и к ә
Көчле куллар нигә саклый алмый
милләтеңә язган бер йортны?

Я р о с л а в н а
Әллә киеп карау уең бармы
Мономахтан калган бүрекне?

---

* Т ә ү х и д — бергәлек мәгънәсендә.

С ө е м б и к ә
Әгәр ният итеп киям икән,
яле, шуннан нәрсә була соң?
Ошбу бүрек Мәскәү-йортка барган
Көнчак* бикәнеке — беләмсең!

Я р о с л а в н а
Халыкларда кием алмашулар
була инде — читкә борма син.

С ө е м б и к ә
Бүләк иткән бүрек белән бергә
башың гына китеп бармасын...

Булган инде бездә төрле хәлләр:
күпләр яулап-талап таҗ алган;
сарык урлап угры атын йөртсә,
тәхет урлап патша саналган.

Аруланмый дөнья — ырусызлар
әрсезләнеп таҗга үрелсә.
Үртәләнмәс идем, Үтәмешем
ил куенына сыйган ир булса.

Йөрәгемне телә парә-парә
үксез кавемемнең һәр гаме.
Төрле хәлләр булды, гыйбрәт алсаң —
хәләленнән күбрәк хәрәме.

Күрмисеңме: күпме кардәшеңнең
тәхетеннән саркып тама кан.
Кенәзләрдән узып, Куябаны
кыпчаклармы әллә талаган?

---

* К ө н ч а к — Үзбәк ханның сеңлесе.

Я р о с л а в н а

Хак-нахактан азган хакимлеккә
мөһим түгел кан, сөт, тел ягы.
Оныттыра хәтта өммәтеңне
таҗга хуҗа булу теләге.

Сиңа инде барсы яхшы таныш,
гамем әле башка борчуда:
Казан башы булган ундүрт ханның
ник Болгардан түгел берсе дә?

С ө е м б и к ә

Килешмимен: әллә килмешәкме
монда туып үскән ханзадә?
Аттиладан килгән алмашчылар
чит-ят токым түгел кайда да...

Инде сүзләр генә ярдәм итмәс,
фәган* халәтенә кайтамын.

Я р о с л а в н а

Яшең белән әллә юмак булдың
бәхет кошындагы кан табын?!

## 6

Җиде икълим чиген иңләп иңрәү йөри,
иңрәү кайта, кайта ничә ел аша.
Мәшрикъ якны тоташтырып мәгъриб якка,
кара-каршы ике бикәч еглаша.

---

* Ф ә г а н — еглау-сыктау.

Гамьдәшләрнең көяләну гамәлендә
юктыр кинә, юктыр рия, ялган да...
Өзгәләнеп Аллаһыга ялваргандай,
Ана бүре улап куя яланда.

Әллә инде гасырларны пәрдә кебек
бүлеп тора бары ярты төн генә?!
Дәрья буйлый агып төшкән бөрчек яшьләр
мәрҗән булып ята диңгез төбенә.

Мәэюсләнеп мәликәләр моңланганда,
халык хәлен аңлый алыр балык та.
Сыктаулардан хәтта җир-күк сагаядыр —
актарыла күңелдәге бар нөктә.

* * *

Хәзрәти Мәрьям
Бисмилләһир-рахмәнир-рахим!

Яшең белән чыгып бетәр димсең
бәгыреңә тулган бар ачы?
Мәлҗерәмә әле мәҗүсидәй,
хәттин ашма, нугай баласы!..

Канны юып булмый кан-яшь белән,
кан-яшь тамган җирдә гөл үсми.
Кенәзбикә, болай кызгандыру
синең кебекләргә килешми.

Еглашулар бит ул сөйләшүне
дәвам итү башка әмәлдә.
Нәүхәчеләр кебек кыланмагыз —
бар бит әле фарыз гамәл дә.

Алыштырмый зекер әйләүләрне,
гыйбадәтне андый аһ-ваһлар.
Егламагыз шулай егылышып —
су эчендә ята әрвахлар.

Чыдамлыгын яшькә чылатмаган
сабырларны сөя Аллабыз.
Балакайлар, әйдә, бергәләшеп
«Вәл-гаср»ны укып алабыз...
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Сөембикә
Күздән яшең ничек чәчрәп чыкмас,
сабырлыклар тулып ашканда?!

Ярославна
Тирәнәя хәсрәт дәрьялары,
буаларын тырнап ачсаң да.

Сөембикә
Фөрьядыма каршы фәрештәләр
кара «амин» сүзен ник әйтте?

Хәзрәти Мәрьям
Пот-санәмнән килми авырлыклар —
барысы да Аллаһ нигъмәте.

Мәләкләргә үпкә белдергәндәй
карап алма рәхмәт юлына.
Иләмсерәр мәлдә елмайткан да,
еглаткан да бары Ул гына.

Ярославна
Әллә инде безнең яшьле күздә
көннәр белән төннәр буталды?!

Хәзрәти Мәрьям
Саргаешкан чакта сорашыгыз:
«Кайдан килде,— диеп,— бу кайгы?»

Үзегездән үзәк өзелүләр,
үзегездән килә барсы да...
Ихлас белән шуны икърар итсәң,
авыртулар бераз басыла.

Сөембикә
Йөрәгемнең тоймыйм җәрәхәтен,
яшемдә дә инде кан күрмим.
Сизәсеңдер: мин бит, сабырсыздай,
үзем өчен генә кайгырмыйм.

Хәзрәти Мәрьям
Туган халкы өчен бәхет даулап,
сез генәме шулай җан аткан?..
Гарше-көрси мотлак һәрнәрсәне
үз тәкъдире белән яраткан.

Галәлгомья* кылган гамәлләрне
хәтереңә син дә яза бар.
Көч-кодрәтле Аллаһ кавемнәрне
язагына күрә җәзалар.

Хак Тәгалә бәгъзе халыкларга
нигъмәтләрен өстәп биргәндә,
тәкәбберлек йота тәкатьсезен,
башларында калмый бер гамь дә.

Ил-суларын җәннәт мисалында
күреп масайганнар кем иде?

---

* Галәлгомья — сукырларча.

Кәпәренгән шундый кавемнәрнең
тора-бара... җире кимеде.

С ө е м б и к ә

Безнең илне оҗмах багы санап,
дошман нигә җирен арттыра?
Арабызда юкса ыруглыктан
килә торган изге ант тора.

Өммәтемнең шушы әманәтен
мирас итәр идем углыма...

Я р о с л а в н а

Вәгъдә сүзен кемнәр башлап боза —
белә булыр аны Ул гына.

С ө е м б и к ә

Хәләл халкым хакын хаклар өчен
миннән тагын күпме хак кирәк?

Х ә з р ә т и  М ә р ь я м

Дулашмагыз: сезнең дошманнарны
белә Ходай сездән яхшырак.

Я р о с л а в н а

Ачылыгы анда ачыкланыр,
кемнең — эре, кемнең вак яше...

Х ә з р ә т и  М ә р ь я м

Сезне гирьян* иткән дошман явы —
Аллаһ биргән сынау вәгъдәсе.

---

* Г и р ь я н — еглаучы.

С ө е м б и к ә

Татар иле авып барган чакта,
Хак йортына ничек килмә ди?!
Илчесенең биш мең фәрештәсе,
юк, барыбер ярдәм кылмады.

Я р о с л а в н а

Кенәземә сәлам күндергәндә
әйттем җилгә изге сүз генә.
Нигә алар яуда ике булып
күренмәгән кыпчак күзенә?..

Язык саен төшкән җәза кебек,
гел-гел безне эзли бу каза.

Х ә з р ә т и  М ә р ь я м

Үтәмисез фарыз кануннарны —
унның берсен генә булса да.

С ө е м б и к ә

Вөҗданымны сыгып вөҗүдемнән,
нинди бушлык изә бу җанны?
Әллә инде, халкым, сине саклар
фәрештәләр гаип булганмы?!

Х ә з р ә т и  М ә р ь я м

Ябырылса дошман яугирләре,
шик килмәсен Раббың хакында, —
чиратлашып торыр чарасызлык,
җиңү яулар синең халкың да.

Әлмисактан килгән әүлиялар
хикмәтенә дикъкать әйлә бер:

ирексезләп артта калдырылган
соңра... беренчегә әйләнер.

Әгәр Ходай ярдәм итәр булса,
хәтта зәгыйфьләргә көч керер...
Ялгыш юлга илен дәшкән рәһбәр
ике тапкыр газап кичерер.

Бер гөнаһтыр — хаким үз халкының
язмышында уйнап көн күрсә,
мең гөнаһтыр — башка кавемнәрнең
туфрагына бәла китерсә.

### Сөембикә

Казанымның кузлы казнасында
әллә, чынлап, азман эт бармы?
Өч-дүрт ахмак кылган гөнаһ өчен
Аллаһ безне һәлак итәрме?

### Хәзрәти Мәрьям

Уфтанулар тулы үткәннәрне
уйлар дәрәҗәдә аңлы сез.
Инде ничә халык юкка чыкты —
нигә бер дә сабак алмыйсыз?

Хафаламый сезне һәлакәтләр,
туклар белмәгәндәй ач хәлен.
Һичбер милләт узып китә алмас,
кичектерә алмас әҗәлен.

Ашкынышып хәттин ашканнарга
гарше-күктән нәфрәт аркылыр.

Хак Тәгалә алар урынына
башка бер халыкны бар кылыр.

Сөембикә

«Аллаһ әмре» белән килә Мәсих* —
татар үксез, татар ят һаман.
Иңдерелгән күпме пәйгамбәрнең
нигә берсе безгә язмаган?

Пәйгамбәргә лаек халыкларга
өстенлекләр өстәп бирелгән.
Үтсәң иде иң-иң кыен чакта
Хозыр Ильяс белән бер юлдан!..

Хәзрәти Мәрьям

Кыйбласызлар сымак кыйланганга
кабатларга әзер мең кабат:
мәхшәргәчә барлык кавемнәрнең
пәйгамбәре булыр Мөхәммәд!..

Балакайлар, күрә беләсезме
эчтән янып торган тау ямен?
Кайтарылыш көнгә калдырыгыз
кайгырышып еглау тәмамын.

Кемнәр хаклы, дисез, кемнәр хаксыз —
ачыкланыр шунда яхшырак.
Куанышып җәннәт капкаларын
үткәндә дә әле яшь кирәк.

Сыктамагыз!..

---

* Илбасар урыс патшаларының «Аллаһ исеме» белән басып алу сугышлары башлавына ишарә.

**7**

Сөембикә төштәй тонык хәтеренең
төпкелендә татлы-ачы уй саклый.
...Айдаланың өер-өер айгырлары
Нугай җирен дереддәтеп уйнаклый!

Кылганлыклар чайкалыша калкулыкта,
кызалакка ятып аунар ат сыман.
Әллә чыкмы, әллә яшьме, әллә канмы
чәчрәп китә утлы тояк астыннан.

Җилдертәләр Йосыф мирза җегетләре —
бүген алар изге йола үтәүдә:
«Иярдәге шушы тәүге ыргымыңны,
Сөем сабый, егламыйча үт, әйдә!»

Урдасының алтын йортлы уртасында
бүген бит ул җайдакларның япь-яше.
Аргамакта егламаган нарасыйлар
дәрәҗәдә гомер кичәр, янәсе.

...Айдаласы хәтер төбен айкалдырды,
тәкъдир җиле йолыкканда иярдән.
Әллә инде теге чакны чытлык кызга
еглап туймас кара болыт ияргән?!

* * *

С ө е м б и к ә

Мәхшәр көнгә тикле җитәр микән,
Ярыслауна, безнең түземнәр?..
Зинһар өчен, тыңлап торма мине —
кардәшләргә әйтер сүзем бар.

Галәмемнең оят гамәлләрен
белеп бетермәсен көндәшем.
Егламыйча әйтим уйлаганны,
син дә туктап торчы, күз яшем!..

Гомер сөрә җирдә ничә кавем,
бардыр алар йөзләп, меңләп тә.
Зекер әйтмәс идем: зирәк акыл
күбрәк, диеп, безнең милләттә.

Вакланыша торды алыплары
киртә булып калкыр тау саен.
Татарымның, ахры, тәкъдиренә
тәдбир* салынмаган тәгаен.

Бөек Туран рухын туры тотып,
селкетмичә сыңар кашын да,
көчен туплый алмый төрки кавем
зурдан купкан дошман каршында.

Милләтеңә керсә мин-минләнү,
аннан шуның кадәр мән чыга.
Әверелеп бетте арысланнар
йоклап яткан мәхлук мәчегә.

Күккә сыймас мәгърур бөркет җаны
яши кебек хәзер... тавыкта.
...Безнең халык бер көн тора алмас
туганара ызгыш, дау юкта...

---

* Т ә д б и р — алдан күреп эш йөртү.

Кояш чыккан чакта базмас идем,
җөрьәт итеп әйтәм — кич инде:
кардәшләрең белән көрәшүгә
бирдең, түрк, иң күп көчеңне.

Шан-шәрәфле нәсел шәҗәрәбез
башлангандыр изге ант илә.
Үчләнүне синең угъланнарың
уйлап тапкан, Олуг Аттила!..

Илен һәлак итәр чиккә җитә
туганлыктан туйган вак даучы.
Карымталар кырды кардәшлекне,
онытылды ыру вәгъдәсе...

Ярославна

Кардәшләрен ашар каракошка
каргыш төшми бугай, ханбикәм.
Ярославның соңгы васыятен
искә алсам, күпме кан йотам.

Әйткән кенәз: туган белән туган
сугышмаска тиеш моннан соң!..

Сөембикә

Үзең генә йотма гарьлек утын,
вәгъдә бозган ир дә моңлансын.

Ыру анты, беләм, түгел әле
эчеп исәрләнер эчемлек...
Ярыслауна, бүлмә ярсуымны —
бүген минем синдә эшем юк.

Кан-яшьләрем сауган кардәшлекне
аңлый алмый канча ел барам.
Айдалалы нугай агайларым,
еглый-еглый сезгә ялварам!

Нәгъррә ормый гына сорыйм әле,
ишетмәсен аны кай кеше:
берәр вакыт булды микән сездә
нәселдәшлек, ден-дин кайгысы?

Сезнең өчен, ахры, ашы кыйммәт,
баштан ашканда да ил эше.
Туемсызлык йоткач туганлыкны,
ауган, әнә, Җучи олысы.

Гарьсезләрең дала горурлыгын
сатты юк-бар бүләк хакына;
мескенләнеп сорау мисалында
Мәскәүләргә китте хат кына.

Ияр юлла, имеш, быргы җибәр —
теләндегез даулап һәммәсен:
кәгазь, буяу, кургаш, көбә, акча,
зәгъфран, бүрек, кадак һәм лачын...

Алтын чире йоккан кылтык ханың
ашамаган... бакыр казаннан.
Шундый җимнәр белән дәҗҗал үзе
сезнең ышанычны казанган.

Яманатлы Мәсих ямаулыгын
ташып торган җасус ямчылар.
Шуның өчен бит ул һәрбер заттан,
Газраилне узып, җан сорар!..

Сарык булә алмас ике туган,
сезме милләт өчен янучы?
Кардәшлекнең канын корытадыр
карымтага сыймас кан үче.

Илаһыннан куркыр иләмәнне
таба алмый йөри ил гаме.
Ә мин җавап эзлим: бездә илхан
үз үлеме белән үләме?

Агуласа берсен агалары,
икенчесен... углы үтерә.
Бердәмләшер иде бөрадәрләр —
киртә булып зәһәр үт тора.

Канлы дауга сылтау булсын әле
дала буйлап чапкан бер дүдәк!..
Унөч туган суеп кигән таҗның
бәрәкәте кайда, Бирдебәк?

Бакчасарай ханы*, ваксынмыйча,
кыйган, әнә, газиз ун җанны.
Ыру каны сеңгән тетрек җиргә
нигез корып алар уңганмы?

Тәсбихеңнең асыл мәрҗәннәре
нигә, каумем, һәрчак ким торган?
Идегәйнең башын игелексез
Барын кисеп, Ширин китергән...

* Мөхәммәт Гәрәй күздә тотыла.

Кисәтүчән була кисекбашлар,
зирәкләнеп сабак бирүчән...
Безнекеләр һаман бугазлаша
кечтек кенә иске бер үчтән.

Мордарлыкка баткан мирзаларым,
нәрсә җене сезгә кагылган?
Аллаһыны сөю тәһарәте
кылынмыйдыр алай кан белән.

Кыландыгыз сыйлы келәмнәрдә,
дошман сигез, диеп, без тугыз.
Ә кылмышта баскын кулындагы
айбалтаның сабы булдыгыз.

Бүрек сорап, шулай бүре чакыр,
һәрбер монафыйкъның үз җиме.
Ерак чорга барып җитәр әле
кысыр Шаһгалинең... үрчеме.

Әгәр түккән яшем дәлил икән,
хасил булыр күктә бер диңгез...
Дилбегәсен чиксез далаларның
җиде ятка ничек бирдегез?

Безнең өммәт бөтен яктан камил:
һәм гакыллы, имеш, һәм ипле;
һәлакәтле язмыш хәлләренә
унбиш яшьлек* Иван гаепле...

---

* Явыз Иван үзенең гаскәре белән Казанга шушы яшьтә һөҗүм итә башлаган.

Дәүләтеңнең черү сәбәбе дә
төенләнгән шушы баскында.
Каныгуы татар каныннандыр —
аударыгыз аңа барсын да.

Искәртмиме безнең өстебезгә
ябырылып торган яу үзе?
Үткапчыкта гына утырадыр
дошманыңның үтә явызы.

Аңлый күрче, каумем: шуннан гына
кылә, димим, безгә бар афәт;
уйла әле тәсбих өзгән мәлдә —
башсыз илдә булмый бәрәкәт...

Шушы хәтәр чакта берәр ир-ат
күрсәтсәме тәҗел эш кылып?! —
Зәүҗә башым белән йөрмәс идем
тәхет тирәсендә ышкылып.

Һиҗрәт кылу гына пакьли алмас,
намусымда барыбер тап булыр.
Шелтәләгән чакта Шаһгалине,
миннән шигәюче табылыр.

Дәгъваларын гамәл дәфтәремә
язып куяр кара кавырсын.
Илдә сату итеш барган чакта,
кем фәрештә булып калыр соң?!

Аңа кадак, имеш, моңа Казан —
мәхшәргәчә тынмас ул сәүдә.
Тамчы яшем шундый авыр булып
ятса икән гарше үлчәүдә...

## Бетем

Даулы җиргә тамып торган ачы яшьләр
саркып чыга әремдәге чык булып.
Кыйтгалардан тонык тавыш кайтарыла —
тагын кемнәр еглый анда сыгылып?

Кавемнәрнең көяләнгән күңеленә
моң-зар өстәп, исмә әле, исмә, җил!..
Җырлауларны ялгагандай еглауларга,
аять укый Муса, Идрис, Исмәгыйль.

Кавышырга өмет итеп кыяматтә,
карурманда Сак белән Сок яшь сыга.
Иконалар «еглый» башлый чиркәүләрдә,
и Ходаем, була күрсен яхшыга!..

Кардәшләрнең яше сыймый каберенә —
гаҗизлектән үкси Аксак Тимер дә.
Әтрәк ханмы, җәмшән иснәп, сыктый һаман
гариб башын сыендырган чит җирдә?

Тагын кемнәр бузлый анда? Зөһрә кызмы
чиләк белән Айга ташый... күз яшен?
Нәүхәчеләр юа хәсрәт дәрьясында
яугирләрнең канга баткан көбәсен.

Фәрештәләр мышык-мышык сулкылдаша,
Рамазанның соңгы көне батканда.
Хәтерләтеп Бакчасарай ханбикәсен,
яшен түгә моңлы күздәй фонтан да.

Күздән язар хәлгә җитеп ярсый Ягъкуб —
тама Йосыф күлмәгенә канлы яшь.

Якыннарын югалтудан ахылдаша
Миңлесылу, Даныбикә, Карлыгаш.

Ибраһимның ялгыз калган хатыннары
еглашадыр: «Хур буламыз,— дип,— Ходай!»
Ә кулларын угалаучы угъланнары
сөенешә: «Хан буламыз,— дип,— Ходай!..»

Янмас кызның үксез җаны очып йөри —
аглый Казан, Җылантауда ут күреп.
Сабый төсле сыктый һаман Явыз Иван,
ауган ханлык тәхетенә утырып...

Җиде икълим чиген иңләп иңрәү йөри,
иңрәү кайта, кайта ничә ел аша.
Дөньядагы барлык, барлык фөрьядларны
күмә төшеп, мәликәләр еглаша.

Йөрәгеңнән гамьнәр савып йөдәгәндә
килми калмый, килми калмый кан исе.
Бәгырьләрдә Вакыт... Хәтер бәрелешә,
хаклы итеп тоя үзен кайсысы?

Исәннәргә нинди аһлар ишетәсе,
алгы көндә тагын ниләр күрәсе?!
Ике бикәч көн-төн еглый ике ярда,
яраларга тамып тора күз яше...



# II БҮЛЕК



* * *

Хәтер — уяу.
Бәлки, бу халәттә
күзләремне йомып йоклыймдыр.
...Инеш тулып ак болытлар ага —
кулларыңны суга тыкмый тор!

Бәреп кермә татлы төшләремә,
ә син, хәтер, барсын отып кал.
...Инеш тулып ап-ак керләр ага,
кемдер дәшә миңа:
«Тотып ка-ал!..»

Җуелганны инде даулап булмый,
башыбызны җиргә орсак та.
Яныбыздан шулай китеп бара
кулдан ычкындырган форсат та.

Кемдер тотар аны,
кыргый ат күк,
йолкып алса да ул кулбашын!
Бу тормышта югалтуларың да
дошманыңа табыш булмасын.

Кулдан ычкындырган алтын вакыт
үкендереп куя хәзер дә.
Көзге ташудагы алмадай ул
ымсындырып ага хәтердән.

...Инеш тулып ак болытлар ага...

# Сөт

Башка тукып тора бер кисәтү:
«Каләм язып саклар, бел, бәндә!
Каләм белән язылганны инде
бозалмассың кылыч белән дә...»
Аңлашыла. Фикер җебе буйлап
барам да мин шуңа төртеләм:
ә болгарлар күнгә язылганны
бетергәннәр ничек сөт белән?!
Пергаментлар белән кешелекнең
хәтере дә аз-маз юылган.
Үткәннәрнең күпме хат-хәбәре
шулай сөткә китеп юк булган.
Язылганның яхшысымы,
юк, юк,
яманыдыр күбрәк өтелгән.
Үзәкләргә үткән пычрак сүз дә
юыладыр әле сөт белән.
Ничек итеп?
Гаеп-гөнаһларын
юа алган кеше беләдер.
Сөт анасы, тарих битләреннән
ниләр җуйдың, әйдә, сөйлә бер!..
Мәңгелеге хәтта кылыч белән
кыелмаслык итеп уелган;
онытылырга тиешлесе, димәк,
әнә шулай сөттә юылган?!

Шулаймы?
Ә ул дәшми...

## *Сызлаулы хәтерне яңарту*

Күтәрелеп Кече манарага,
тарих төпкеленә төшкән бар.
...Эскәнҗәдәй кысып язмышларны,
идән булып иңгән түшәмнәр.

Хакимият илаһ кыяфәтле
ташваткычның үзен он иткән!
Болгарымның көле
борынгыда
гөл булганын әллә оныткан?!

Чәрдәкләнеп беткән таштабакның
китегендә тере нур калган!
Оешмасмы җырлы тәлинкәгә?! —
Ярчыкларның
кайсы янган, кайсы урланган...

Вәхшилекне күрдем —
культуралы
катлам читен бераз ачтым да.

...Каендагы карга оялары
һаман тора кояш астында...

## *Иске Казан*

(Манзара)

Кальгаларны вакыт-яу да җимерешә —
хәрабәсе һаман тора биектә.
Бүген моннан дельтапланнар күтәрелә
(оча кеше шундый канат киеп тә).

Тарихтан да картрак лачын күзләрендә
чагылмыйдыр нинди видеоязмалар!..
Тере шаһит булганнары өчендерме,
хәтта шушы аулакта да аз алар.

Ә шулай да җимерелгән кирмәннәрне
канатлылар ни өчендер үз итә.
Крепостьның «КП»сыннан торымтайлар
горур гына кеше-кошны күзәтә.

Югарыдан күзләр шәбрәк күрәләрдер
тарихтагы килгән-киткән эзләрне.
...Таш баскычтан бер күч казлар менеп килә,
хәтерләтеп су ташучы кызларны.

Биек тавы, болынлыгы, Казансуы —
җирдән кубып очар өчен бик көйле.
«Мулла-хаҗи», «Гайшә-бикә» каберләре
картаялмый интегәләр шикелле.

Ук очлары төртеп торган чирәмлектә
имчәгеннән сөт чәчрәтеп ат ауный.

Безнең чордаш кабаннар да актарыша
туфрактагы культуралы катламны.

Әйтәләр бит: изге-газиз нигезләрдә
тарту көче куәтлерәк була, дип.
Ә биредә дельтапланны нинди кодрәт
күтәрешә һәм очырта дулатып?!

Төшләрендә әле һаман очканлыгын
күреп яткан сынык сөңге очымы?
Вакытның да холкына хас «Очты-очты»
уенының тылсымлы бер көчеме?
Икар рухлы һәм җир җанлы Алыпларның
дөньялыктан киткән күңел кошымы?..

Иске Казан.
Дельтапланнар күтәрелә...

# *Савыт-саба ватыклары*

Бу тормышта савыт-саба
шалтырамый торамы?..
Гасырлардан ишетелә:
«Бәр чүлмәген, ор җамын!..»

Савыт-саба каршы тормый —
ул берсүзсез җиңелә.
Халыкара низагларда
көл булмаган ни генә?!

Кеше гүя гомер буе
чүлмәк ваткан бар көчкә.
Касәләрнең, йә, күпмесе
ватылган соң бәхеткә?..

Төшенерсең: җир катламын
ачып, аска төш кенә.

...Болгар...
Савыт ватыкларын
тезәм чирәм өстенә...

## *Беренче киселгән ярымай*

Үз-үземне эзәрлекләп,
гасырларны кичкән бар:
«Җәберләнер ярымайны
әүвәл кайчан кискәннәр,
әүвәл кайчан кискәннәр?»
Күңелемнән, күрәзәдәй,
үткәзәмен бар-югын...
Сөбханалла, сөбханалла:
күрәм... Казан бүреген!
Татарлыкны тотып торган
ханлык таҗы — ганимәт...
Җәрәхәтле йөрәгемне
йомарлатты кан кинәт.
Ачындырды: очындагы
алтын ае... киселгән!
Бәгырькәем, бүрегеңне
салдырганнар көч белән.
Серле сорау сыман борчый
юкка чыккан ярымай.
Күңелләрдә күмелергә
аңа һич тә ярамый!
Мәсҗетләрне мәсхәрәләү
башы шулдыр, мөгаен.
Киек казлы күктә күрәм
Казанымның мең аен!..
Бүректәге беренчесе
әсир киткән ят йортка.
...Төшләремдә, тәшвишләнеп,
кысам шуны йодрыкка...

## *Татар бугазы*

Идел-йорттан татар ятимедер —
аз-маз чамалыйсың ич мине.
Нәрсә әйтим, «туган», нәрсә әйтим
йөрткән өчен хәтәр исемне.

Биләмәләр чиген билгеләргә
килмим сиңа, Татар бугазы.
Томырылып торган тамырларның
киселмичә калган бик азы.

Кальгаларның тере кылганнары
ничек котылгандыр көч-яудан?!
Урдадагы алтын ырудашлар
тәгәрәшкән затлы кысадан.

Кыйнашларның кара кан-яшьләре
ага сиңа шу-ундый еракган!..
Борынгыда бәгъзе берәүләрең
безне кысып-кысып «яраткан».

Сөембикә затын сәмруг-коштыр
кочагында кысып үтергән.
Тикмәгәме: кемдер тамагына
кемдер төер булып утырган...

Безнекеләр диңгез бугазына
милләт атын кушкан, янәсе.
Йотылулар белән йотуларның
татарлыкка хасрак, йә, кайсы?

Ыңгырашып кыен ашаганда,
йотса йоткан бары яшь кенә.
Тамырларны көн-төн томалыйдыр
эчкә яшерелгән үч-кинә.

Кавемнәрне тәмле кабымлыктай
йотучылар әле ач һаман.
Татымлырак икән татарларым —
үзен-үзе генә ашаган...

Бездәйләргә Татар бугазында
беләм инде, беләм сан югын.
Йөрәксенеп, «туган», йотмадыңмы
Таһир белән Зөһрә сандыгын?

Суларыңның сизмим сулкылдавын,
өнең дә юк — телең йоттыңмы?
Чишмәләре буйлап чакырттырыр
Иделдәге туган йорт мине...

Шәрыкчәрәк исем шәрифләрең —
шуңа бераз яшем агыза.
Денсезләнмик әле дөньялыкта,
сиңа таба ярым ай йөзә...

## *Җыр тәлинкәсен юу*

Җыр тәлинкәсендәге тузанны 0,5 өлеш балалар шампуне яки 10-15 микъдар этил спирты өстәлгән су белән югалап торырга кирәк.

*Киңәшләр китабыннан*

...Тузанына, сеңлем, кагылмачы —
өермәләр кубар «Уел»дан.
Татар җыры инде болай да бит
кан-яшь белән кат-кат юылган.
Нинди генә зәһәр ысул белән
юылмаган хәтер сырлары!..
Тәлинкәңдә Кубрат егетләре
көйләп йөргән берәр җыр бармы?
Җырлар үлми, имеш...
Күпме җырлар
җырчылары белән югалган.
Кешелекнең аңы тирәнәйми,
алтын чыкмый хәтер юганнан.
Коенганда шәфәкъ суларында,
шундый үзәк өзгеч чак була:
үләлмичә йөргән кайтаваздай,
үксез моңнар җанга кагыла...
Мөлдерәмә моңы түгелмәсен —
кулларыңа саграк ал аны.
Хәтереңә тамыр җибәрерме
кат-кат юылганнан калганы?!
«Уел»ларның азы уелгандыр
уттан чыккан хәтер ташында.
...Җырлы ташлар юган суда, сеңлем,
юып була бала башын да...

## *Венера планетасының топонимиясенә кереш*

Мондагы һәртөрле түмгәккә
кешеләр исеме кушылган.
Әйтерсең имзасын калдырып
төшүче адәмнәр еш булган...

Күпмебез хәтердән җуела,
гомерләр кичсәк тә бер өйдә.
Онтылган җирдәшләр исеме
күченеп яши күк биредә.

Ничаклы янартау тамгасы
«колонист исемнәр» иләндә!..
Мөбарәк шәҗәрәм анасын
табармын шикелле мин монда.

Исемнәр... Бушлыкта очканда
руханә тотынып өченме?
Ә бәлки, алар да, җан сорап,
галәмгә тартадыр кешене.

# Борынгы хәрабәләр янында

Вакытлар табылмыйдыр
якут белән...
*Г. Кандалый*

Һавадан кош моңы иңсә дә,
тузганак тоталмый үз таҗын.
Ап-ачык күрдем мин бу илдә
көннәрнең таҗ кебек тузганын.

Йөрәккә давыллар кагылган,
чәчләрне агартып узган моң...
Вакытны узсак та, бер күмәр
безне дә вакытлар тузаны.

Күмә дә актара...
Вакытлар
елларны күмә дә актара.
Җәүһәрләр йөзендә нур һаман,
гасырлар төбендә ятса да.

Дәверләр катламы астыннан
яктыра кояшлы алкалар...
Ярый ла, безне дә бер шулай
вакытлар актарып алсалар.

## *Бульдозерга һәйкәл*

Кайсындадыр дөнья каласының
кыяташка аны куйганнар.
Хәйран калдым — юкса һәйкәлләрнең
әллә ниндиләрен күргән бар.
Бульдозерга ничек биргәннәрдер
данлау баскычының түр башын?!
Кешеләргә таулар күчерешеп,
каһарманлык кылган, күрәсең.
Шанлылыгы мине шикләндерми —
хәләл хезмәтенчә хөрмәте.
Әмма...
Иҗтиһатны кайчак илаһлыкта
күрә башлый корыч чор аты.
Ясиннары күпме ясаттырды
пәри туен — соңгы өй туен!
Такташыбыз торган ташпулатны
вәхшиләрчә вәйран итүен
хәтерлимсең, хаким, хәтерлимсең
мәчетләрнең... мордар китүен?..
Бульдозердай мәгълүм булдыклыга
өлгер генә, өлгер эш биреп.
Башбаштаклык белән башыбызны
төшермәсен җирдән эшереп.
Хөрмәтләүгә лаек хезмәтләрен
танымавым түгел һич кенә.
Тик утыртмыйк аны узындырып
хәтер хәрабәсе өстенә.

## *Бер сөйләшүдән соң уйлану*

«Быел тагын сипләтәсе бар»,— дип,
сүз кузгаттың йортың хакында.
Бу дөньяда искермичә тормый
аксакаллар биргән акыл да.

«Кич сөйләгән —
иртән ярамый»,— дип
әйтәсеңдер әле үзең дә.
Үткәннәрдән хәтта канатлы сүз
килеп җитми кайчак бу көнгә.

Киләчәккә очкан хатларга да
куя, сынап, Вакыт йөз җәтмә.
Заманалар
мирас булып килгән
мәкальгә дә кертә төзәтмә.

«Нигезенә таза имән салып,
өйне сиплим,— дисең,—
яздан соң...»

...Иманымны шулай, кайта-кайта,
кабат төзәтергә язмасын.

## *Иске арба*

...Юлда җуелган
күпме ат башы.
Ә ул узган бит
чорлар арасын.

Чыккан әйтерсең
тәмуг аша да.
...Агач күчәрен
еллар ашаган...

Үткән юлларын
ничек үлчәргә?..
Дөнья кадәр йөк
төшкән күчәргә!

Түзми бастырык,
камыт баулары...
Ә ул күтәргән
нужа тауларын.

Алга күчергән
Җирнең бар ямен.
...Мин шул арбада
китеп барамын,
юк, юк, Кадирем,
кайтып барамын...

# *Билгесез рәссам*

Кемнәрдер — вакытлар корбаны,
(буяуга кушса да үз канын)!
Нигә соң Билгесез рәссамны
күммәгән гасырлар тузаны?!

Хакмы шул: исемсез җаннарны
танымый, янәсе, халык та?!
Ә ул бит намәгълүм килеш тә
дәверләр төбеннән калыккан!

Еллардан сорама: кемнәр, дип,
билгесез исемнәр артында?
Кайвакыт үз атын оныта
дөньяның аксакал карты да.

Исемен җуйса да, гамәлен
саклаган шәхесләр азмы соң!
Теләмәс идеңме үзеңә
Билгесез рәссамның язмышын?!

## *Тәмамланмаган сын*

Үз асылын ташка күчерергә
өлгердеме икән карт сынчы?!
Өзелгән җыр...
Җиргә киткән, димә —
исәннәрдә җырның яртысы!..

Шулай да ул яралгандыр төсле
ташка сыя алмас уй булып.
Әллә соңгы сүзме,
әманәтме
калган икән ташка уелып?!

Ә бәлки, ул яшәү хакыйкатен
чагылдырган акыл ташыдыр?!
Соң сулышта сыннар остасының
уй-хисләре шулай ташыйдыр...

Бәхетсез таш, диеп уйлый күрмә,
шушы ташка күзең төшкәндә.
Вакыт кайчак үлемсезлек бирә
тәмамланмый калган эшкә дә.

# *Шулай да уйлап куясың...*

«Сүз иясе белән йөрми...»

Җавап эзлим:
нигә шулай
сүз иясен җуя соң?

Һәм Билгесез шагыйрьләрне
шундук уйлап куясың...

# *Сүз*

*Шагыйрь дуска*

Каршы килмә:
авызыңнан
сүзеңне җилләр алсын,
тик ул халык җанынача
тукталмый җилә алсын.

Вакыт җиле авызыңнан
сүзеңне алсын гына!
Тик ул аны салып барсын
хәтере сандыгына.

# *Хөкемдар*

Курай моңнар чәчсен өчен
кирәк түгел зур әфсен:
бары... артык тишекләрне
каплап кына торасың.

Халык өнсез торсын өчен
нигә уку кү-үп ясин?!
Шагыйрьләрнең авызларын
каплап кына куясың.

Туфрак белән...

# *Күңел гамәле*

**Буш вакытларында Каюм Насыйри — көзге ясау, Хәсән Туфан сәгать төзәтү белән шөгыльләнгәннәр.**

**1**

Венеция остакуллары да,
Насыйри да көзге ясаган.
Ясаган ул — үзен-үзе күреп,
бер уйлансын өчен барча җан.

Чит шөгыльме?
Бәлки, уйлап баксаң,
шул булгандыр аның төп эше.
Чынны чагылдырган Насыйриның
могҗизалы раушан көзгесе.

...Каюм эшли.
Әнә — «Кырык бакча»,
менә — «Фәвакиһелҗөләса»...
Һәрберсенә исем куша-куша,
кешеләргә көзге өләшә.

Ә берсен ул, серле тамга салып,
бүләк итәр Гөлнар ханым*га...
Һич тутыкмый торган бу көзгеләр
көнләштерер Пти-Жан**ны да.

---

* К.Насыйрины якын күргән урыс галиме О.Лебедеваның псевдонимы.
** Яңа төрдәге көзге ясаган француз уйлап табучысы.

Насыйрииыкылар, рентген сыман,
күрсәтәдер рухны үтәли.
Каюм һаман ясый:
чын йөзләрен
белмәүчеләр җирдә күп әле...

Көзге беркайчан да алдаламый,
һәм ул тиңдер туры сүзлегә.
Шуңадыр да кыек авызлылар
кайчак үпкәлиләр көзгегә.

Менә шулар күпме көзге ваткан,
ә китаплар әллә аз янган?..
Насыйридай бөек көзгече дә
куылмакчы иде Казаннан.

Реакцион «бәгъзе адәмнәр»не
«урыс» Каюм үзе хур итә.
Унөч батыр, дию юлын бүлеп,
гүя көзге-дәрья ыргыта...

Рәхмәтеннән күбрәк кыйналулар,
үч-тиргәүле хатлар алса да,
гомере буе, күз нурларын түгеп,
сукыр Каюм көзге ясаган.

**2**

Резедалар быел тагын
чәчәкләнгән көз якта.
Көн күзендә, онытылып,
Туфан сәгать төзәтә.

Вакыт хәтеренә Җәлил
кайтып керә буз атта.
Ап-ак чәче яктысында
Туфан сәгать төзәтә.

Галилейны инквизитор
аклап бүген сүз әйтә...
Угын кире бора-бора,
Туфан сәгать төзәтә.

Сөембикә* тамырына
вакыт балта йөзләтә.
Йөрәк тибешенә көйләп,
Туфан сәгать төзәтә.

Энҗе чәчәк токымына
үлем-афәт күз ата.
Бакый җанга әйләнсә дә,
Туфан сәгать төзәтә.

Туфан сәгать төзәтә...

---

* Сөембикә манарасы күздә тотыла.

## *Туңу. Тукай*

Куырыла дөнья салкыныннан
яңа гына туган бала да.
...Уйлап куям бөек Туңучыны —
җылы эзләп кайта салага...
Бәби туңа!..
Тукай номерыдай
ягылмаган мәллә дөньясы?
Суык бабай!
Бозлык чоры үткән —
мондый салкынлыкны кем ясый?
Салкын йөзләр,
боз күңелләр,
туң йөрәкләр
салкынайта, ахры, дөньяны.
Җир кичергән салкын сугышлардан
җылыналган икән кем җаны?
«Җылылык юк җирдә»,— дия-дия,
хәтта сентябрьдә күшеккән
Тукайҗанга бары кыш кынамы,
бизгәк кенә, димсең, үч иткән?!
Кешелекнең әллә күңеленә
бик үк тиз эремәс кар төшкән.
Җылы җаны чыгар мәлгә кадәр
Шагыйрь суык белән көрәшкән.
«Җир суына»,— дибез,—
«Җир җылына...»,
ә нарасый һаман күшегә.
Бу дөньяда үзебезгә дә бит
каз тәннәре шактый еш чыга.

# *XX гасырның унөч елы*

Мин сыялмыйм... фани дөнья вакътына...

*Г.Тукай*

...Ана җаны очып йөри күктә,
ятим улы өчен түр эзләп.
Кыска гына гомер шәме яна,
йолдыз җилләрендә дерелдәп...

Җәрәхәтле үҗәт йөрәгенә
иблис груһ тора «көч» биреп.
Өлгерергә кирәк Аллаһының
вәхиләрен акка күчереп.

Унөч (!) кенә елын биргән гасыр
тупса аша аяк басканда.
Шундый кыска гомер шәме яна,
яна, яна ике баштан да!..

## *Шагыйрь янәшәсендәге урын*

Апрель ахыры. Кырлай. Шагыйрь туе.
Тәхетендә Тукай утыра.
Арысландай затлар арасында
күрәсеңме, тәкъсир, Ул тора.

Менә Давыт, Салих, әнә Исхак*...
Санап китсәң, барсы пәйгамбәр.
Ходабызның мондый хадимнәрен
кайчан әле бергә җыйган бар!

Җыелмаган халык җеназага —
китте шигырь, җыр-моң, уеннар...
Шаярткандай итте шаһ-шагыйрьләр:
«Тукай кырыенда... урын бар...»

Туең бара, Тукай, уен кара:
биючеләр читек кыздыра.
Чү!
Кыенсынмый утырт көрсиеңә —
Зәйтүнәдәй анда... кыз тора...

---

* Шагыйрьләр Д.Көгелтинов, С.Баттал, И.Машбаш.

# *Бурыч*

*Тукай үлгән хастаханәдә*
*дөньяга килгән сабыема*

Түбенәчә янган шәмдәл...
Сорыйсың күк: «Бу — кайдан?»
Тукайдан ул, Тукайдан...

Беләсеңме: теләсә кем
кабызалмый ул шәмне.
Ә син ут ал,
нур көлтәсе
чөеп чыксын түшәмне!

Мөкатдәс саз...
Бәгыреңә
бәйлә өзек кыл очын.
Сынган, димә —
кулыңа ал
фидаи җан кылычын!

...Төш аралаш, кулың сузып,
сорыйсың күк: «Бу — кайдан?»
Хөрлек сөйгән күңел кошы —
Тукайдан ул, Тукайдан!..

Үз җаныңа кабул итеп
алырсыңмы бу кошны?
Тукай үлемсезлеген син
озайтырга бурычлы!

# Сәйдәш ялгышы

(Баллада)

Әллә нинди шомлы буран чыкты —
бүтән хисләр, бүтән тоем да.
Фәрештәләр, дәррәү котырышып,
бии төсле пәри туенда.

Тазарткандай һәрбер тәрәзәне,
тиеп китә ап-ак канатлар.
...Авыл йорты. Хушлык. Бүген монда
куна калган олуг кунак бар.

Хәйям белми киткән чүнник сыен
җибәрәләр «бәлеш асты»на.
Сәйдәш кенә һаман тыныч түгел:
«Кызган саен нигә җан туңа?..»

Фәрештәләр бии фанфарага —
туктар микән бу туй өч көннән?!
Композитор гына ишетерлек
тавыш килә... буран эченнән...

Адашкандыр берәү... авылына
кайткан чакта кара буранда.
Кайтаваздай иңри «Коткарыгыз!»
камертоннан сизгер бу җанда.

Гарасатта йөрәк гаҗизләнсә,
ала иң югары нотаны...

Бәргәләнеп буран ятьмәсендә,
әллә бәгырь... Кәрим* ятамы?!

Фәрештәләр бии фанфарага,
өзгәләнә Сәйдәш ят моңнан:
«Халык чыксын, әйдә, эзләп табыйк —
тавыш килә амбар ягыннан!..»

Эзләделәр өмет өзелгәнче,
иләделәр карны он итеп...
Әүлиядай затның ялгышуын
мөмкин булса икән онытып!

Мәэюсләнеп калды маэстро:
«Якны бутаганмын... карт юләр!..»
Мәрхүмкәйне мәгърип тарафыннан
буран тынгач табып кайттылар.

Авылдашлар аңлый алдылармы
җаны көйгән сабый ир хәлен?!

...Ап-ак кардан Сәйдәш бара төсле,
тартып бара кара роялен...

---

* Кәрим Тинчурин күздә тотыла.

# *Соңгы сәхнәгә бару*

*1954 ел, май*

Каеннарны ләйсән коендырган,
калмагандыр җирдә кер-кинә!..
Җәяүлисе иткән җилкәнмени —
Сәйдәш бара Арча кырына.

Күренмидер хәтта күләгәсе,
аксөяктәй актан киенгән.
Күңелкәе генә көяләнә —
көтмәгәндә көзчә көй иңгән.

Күпмеләре, кәгазь күрмиенчә,
күңеленә кире күмелгән...
Сәйдәшемне соңгы сәхнәсенә
алып бара язмыш кем белән?!

Көязләнгән язны көнләштереп,
Көлбикәдәй кыз да ияргән...
Салаватын әйтеп сәламләшә
кырмыскага башын ияр җан.

Кочаклашкан саен, кәчтүменең
иңбашында аз-маз тап кала.
Урамнарны урап буранлаган
чия чәчәкләре... таптала!..

Ышандырмый: шушы кешеләрдән
Сәйдәш дусты күргән күп әләк?!

Кәпрәймичә бара композитор,
якасында... кара күбәләк.

Кочегарга кадәр кочаклыйдыр,
кардәшләрчә ихлас үз күреп.
Сыланучан салкын сәламнәрне
нигә җибәрмәскә уздырып?!

Исемлесе, исәр, исерәге
исәнләшеп китә көр генә.
Җәяүлисе иткән җилкәнмени —
Сәйдәш бара Арча кырына.

Саладагы сыман сәламләшә
Бәгырь белән бөтен башкала.
Кочаклашкан саен, кәчтүменең
иңбашында аз-маз тап кала.

Фаразлыймын: ап-ак фәрештәнең
канатына кемдер... кул сөртә.
«Череккүл»нең кара чорларында
сөттә коенганнар куркыта...

Күбәләккә ашкан күңелдәше
күтәрмәгән нинди кер генә!..
Белми кызый, Бәгырь, болай озак
баруыңны Арча кырына.

Пычранмаган соңгы пәйгамбәрдәй,
килә Сәйдәш кара еллардан.

Чайкалдыра, чак-чак чайкалдыра
байтак чаяларны егар дан.

Сәйранлыкка чыккан «сыйлаучылар»
сәламләшеп китә чатларда.
Кочаклашкан саен, кәчтүменең
иңбашында арта таплар да.

Чәчәкләрен койган чиялекнең
итәгендә әллә кар ята?!
Самимилек халык сөеклесен
шулай сөя-сөя каралта.

...Каберстанның кара каргалары
каркылдашып куя көр генә.
Җәяүлисе иткән җилкәнмени —
Сәйдәш бара Арча кырына...

## *Оркестр чокыры*

*Дирижер (һәм альпинист)*
*Фуат Мансуровка*

Бөеклекнең бары биеклектә
яшәгәнен белә чогыр* да.
Моңҗаннарга нинди могҗизалар
күрсәтмәдең шушы... чокырда!..

Ирегүче күпме йөрәкләрне
күтәрәсең рәхмәт юлына.
Чокырыңа оҗмах чәчәкләре
явып тора ничә ел менә.

Зөһрә кызлы Айдан чиләк-чиләк
илаһият нуры түгелә.
Чиксезлекнең шушы чокырыннан
Эверестлар биек түгел лә.

Мәэюсләнмә әле, маэстро,
моң-көй тулы «тормыш төбе»ндә, —
чокырыңа күкләр якыная,
кояш балкып тора төнен дә.

Янартаулар гайрәт яңарткандай,
хушавазлар ургый чокырдан.
...Кыялардан күпме кыюларны
упкыннарга атты сукыр дан...

---

* Чогыр — тау халыкларының кыллы уен коралы.

Чокырыңа яшен чакырдыңмы —
ишарәңне бары Ул аңлар.
Фанилыкта да бит фәрештәләр
төшеп йөри торган урлар бар.

Көйләреңнең якты кайтавазы
урап кайта бугай... тегеннән.
Язмышларга өстәп язылганнар
күренәдер чокыр төбеннән.

Теркәлгәндер нота дәфтәреңә
хәтта сурның кайчан уйнавы.

...Чокырыңа карый чекерәеп
гомереңнең мәгъру ун тавы...

## *Толстой үлгән станциядә*

> Мин күп күрдем филдәй
> кешеләрне...
>
> *М. Җәлил*

«Башка дөнья эзләп китәр өчен
каян алган икән көч?!» — диләр.
«...Шушы китү аны үз-үзенә
алып кайткан»,— дип тә өстиләр.

Юлдашларны тыңлыйм,
ә үземнең
ни дип әйтергә дә тел бармый.

...Астапово.
Никтер искә алам
читкә китеп үлгән филләрне...

## *Сәер карт*

Гасыр карты, иртән торгач,
мыгырдап бер сан әйтте...
Бераз артка калган икән
иске дивар сәгате.

Ничек инде гомер бакый
төгәл йөр дә аксап ал?!
Угын борып, дөресләргә
ашыкмады аксакал.

Соңгы патша сәгатенең
күтәрмәде телен дә...
Ясаучысы әйләнгәләп
ятсын, әйдә, тегендә.

Төпченүче карчыгына
кычкырды ир: «Бар, кортка!
Кыяматтә куып җитәр —
вакыт кирәк вакытка...»

## *Аксакал*

Дөнья йөген күтәрүдән
бетәр, бәлки, хәле дә.

Ул, сынуын уйламыйча,
җимешләрен авырайткан
карт алмагач хәлендә...

* * *

Бу фасылда кемгә көз килгәндер,
кемнең йөрәгендә яз тора.
Күрше карты каен төпләрендә
өеп-өеп яфрак яндыра.

Канатлары утта көйсәләр дә,
озатасы килми көз кошын...
Хәтер сандыгыннан бушатып, карт
яндыра күк иске-москысын.

Тапкан байлыкларын барлый кебек,
саргаймаган шәен калдыра.

Күрше карты каен төпләрендә
өеп-өеп яфрак яндыра...

## *Йолдызларны йолдыз яктырта*

Бәхәсләшмим:
кара янында ак
күзгә аграк булып күренә.
Ә бит әле аксакалларга да
бер-берсеннән якты нур иңә.

Дөньядагы барлык аклыкларны
йөз аклыгы гына ак тота.
Маякларга маяк уты илтә,
йолдызларны... йолдыз яктырта.

# Маяклар да адаша

*Маякчы карт турында уйлап*

Син Иделне яттан беләсеңдер:
кай урында — тирән,
кайда — сай.
Ә ялгышың йөзгә тапкырланыр,
хәтереңне язлар алдаса...

Син Иделне яттан беләсеңдер:
кай урында — тирән,
кайда — сай.
Каргыш кемгә?
Давыл кочагында
янар маяклар да адаша.

Син Иделне яттан беләсеңдер:
кай урында — тирән,
кайда — сай.

Идел — гомер...
Тирәнрәк ачыла барган саен,
ул бит хәйләкәррәк алдаша...

## *Иске тегермән: ат, таш...*

Җирнең үзен әйләндерә алыр
горур кыяфәтле ат кайда?
Сине мәңгелек дип танучылар
ялгышкан бит:
таш та картая!..

Ә хуҗа карт дөрес кабатлаган,
«Вакыт-тегермән,— дип,—
баш сиңа...»
...Яңгыр тамчылары бодаймыни —
чиләк-чиләк коя ташыңа!..

Ташың гына калган,
ә хикмәтен
күтәралмас алтмыш Алып та!
Хәтта үзеңә дә калдырмыйча,
яшәү өләшкәнсең халыкка.

# *Ат егу*

Авып китәр төсле үзе —
бармак белән төрт кенә.
Менә шушы карт кагылса,
ат булып ат сөртенә.

Сөртенә дә гөрс итеп
ава чирәм өстенә.
Кемдер уйлый: ат егарга
кирәк бары көч кенә.

Көч кенә дип кырт кисterү
бер уйласаң, хатадыр.
Әйтерсең карт — Севильядан
килеп чыккан матадор.

Матадор да, ай-һай, беләк
белән генә җиңәрме?
Дүрт аяклы атны, йә, әйт,
егып салды җегәрме?

Җегәрме соң? Әллә баумы?..
Шул карт җиңде ат көчен!

...Сөйрәп кенә йөри үзе
кулындагы артышын.

## *Ефәк тасма*

Картлар йорты. Тынлык. Олпат агай
робагыйлар укып утыра.
Биләмәдәй күргән бүлмәсендә
таңга кадәр якты ут тора.

Дәртләндерә Хәйям дуртьюллыгы,
шәраб итеп аны эч кенә.
Картны йокы алгач, ефәк тасма
кереп ята китап эченә.

Иртәгесен кирәк сәхифәне
эзләп табу булмас мең нужа...
Кәнәфигә сеңгән иләмәннең
куенында затлы мәҗмуга.

Парчаланган якты пәрдәләргә
ачык тәрәзәдән җил бәрә, —
фанилыкта... әллә фәрештәме
канатларын җилпеп җибәрә?!

Аксакалның җанын саклагандай,
урындыкта тора таш мәче.
...Тәкъдирнамә ничек тәгаенләр,
кайсы биттә калыр тасмасы...

## *Картлык галәмәте*

Авырайдым... Еллар тозы
утырадыр җилкәдә.
Әүвәл шушы аякларым
тими иде җиргә дә!

Искә төшә ике гасыр
чигендәге бусага...
Алысларда абынмадым,
дөнья баскан булса да.

Җилле егет булган чакта
җиңел иде... акыл да.
Сызланучы сөякләрең
авырая ахырда.

Һәм тоела башлый хәтта
тәндә җаның йөк булып.
Авырайдым... Гаҗәп түгел
төшеп китсәң убылып.

## *Игезәкләр*

Әниләре пардан киендерде,
икесенә һәрчак тиң тегеп.
Сырхау, имеш, күзе төшкән кызын
таба алмый йөрсен, интегеп...
Балачакның мондый күлмәкләрен
күреп була бары курчакта.
Игезләргә пардан киенүләр,
ай-һай, авыр икән зур чакта.
Күрәчәгең күптән әзерләгән
төрле-төрле язмыш күлмәген.
Берәвенә туйда киячәкнең
әйләндереп бирә сул ягын.
Алмаштыра кайгы сеңгәненә
күлмәгеңнең җете аклысын.
Игезлекнең тормыш тарафыннан
танылмавы инде хакмы соң?!
Үртәүчеләр хәзер буташтырмый:
пәри кайсы, диеп, җен кайсы?..
Бишекләре бишкә төрләндерсә,
йөзгә төрләндерде дөньясы.
Өлешеңә тигән көбәләрдә
игез булып калу мөмкинме?!
...Балачакның парлы күлмәкләрен
соң кат искә алыр көн килде.
Алмаштырып кигән чакларына
кайталмаслар инде барыбер.
Хушлашканда, чуар дөньялыкның
соңгы күлмәкләре пар булыр...

## *Чәч алу*

Сөйләмәскә иде исәпләрем,
искә төште менә тагын да.
Әти картның, кайтып, чәчен алдым,
үлем көтеп яткан чагында.
Никрутларча тели алдырырга —
үзе, элеккечә, җор тагы.
«Менә шулай,— ди ул,— менә шулай
тузып бетә гомер йомгагы...»
Бүген язмыш хет бер генә тапкыр
сыйпап алса иде чал баштан!
Чуалышып беткән чәчләренә
еллар җиле кереп адашкан.
Белештерми торган чәчтараштай,
ике учма кистем як-яктан.
Беренчесен — бабам үтерелү,
икенчесен сугыш агарткан.
Чәчләренең тоныкъ яктысында
күрәм кара еллар шәүләсен...
Минем иңнәр тотып тора алмас
дөнья белән тулы чал башын.
...Ачылышып китте тәрәзәләр —
зәһәрләнеп, ахры, җил бәргән.
Соңгы тапкыр чәчен сыйпар өчен
әллә аны язмыш җибәргән?!
Дөньядагы бөтен бәйләнешен
инде өзә барган чагында...
Сөйләмәскә иде исәпләрем,
искә төште менә тагын да.

# Тәкрарлау

*Әхмәт Рәшиткә*

«Пәри, тап, тап!
Биш балаңны суярмын,
алтынчысын буармын...
Пәри, тап, тап, тап!

Юк, юк, бумам,
суймам да...»

Үксегәнсең,
әтиеңнең
башын сугыш җуйганда...

Җаныңдагы балалыгың
һаман сыктый такмаклап:
«...Тап, тап, тап!..»

## *Сугышта үлгән диңгезчене юксыну*

Баш өстеңдә ташың да юк,
агач та үсми, гөл дә.
Кырыс канун: җирдә яшәп,
калмасын синнән көл дә...

Мәрмәр исемлекләрдә дә,
диварларда да юк син.
Әйт, акчарлак, чал анага —
күз яшен кайда түксен?

...Ә бәлки, ул әбелхәят
суына әйләнгәндер?!

Ничәнче кат тәрәз шакый
диңгездән килгән яңгыр...

## *Яптылар һәм ачтылар*

Пушка лафетына
сузып салдылар да
япь-яшь йөзен
байрак белән яптылар...
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Һәйкәл әзер!..
Ак җәймәне тартып,
йөзен ачтылар!

# Фидаилык

*Җәүдәткә*

Сират кичкән затлар кебек,
чыдам булганнар:
әтиләр — яуда, әниләр — авылда...

Җиңү кавыштырган.
Бер-берсенең кочагына атылганнар!
Таштай салкын протезлар
әниләрнең тезләренә бәрелгән...

Әтиләр дә, әниләр дә,
сират кичкән затлар кебек,
сабыр була белгән.

## *Кызыл балчык*

Вакыт учагының көледер син —
иңәсеңдер кызыл көз булып...
(Әллә җиргә шәфәкъ кызыллыгы
сеңә микән шулай сөзелеп?!)

Җиргә күчкән яшен-йөрәк булсаң,
учка алам —
яле, балкып ян!

Көрәшчеләр каны чәчрәр төсле
йодрыктагы кызыл балчыктан...

## *Чаң какмагыз әле!..*

Чаң какмагыз әле каланчада —
ут-күз түгел, кичке шәфәкъ яна.

Чаң какмагыз әле каланчада —
мираж төсле Болгар кузы яна.

Чаң какмагыз әле каланчада —
колгаларда бурлат сөлге яна.

Чаң какмагыз әле каланчада —
җирне ялмап, мәк басуы яна.

Чаң какмагыз әле каланчада —
Ослантауда баланлыклар яна.

Чаң какмагыз әле каланчада —
Череккүлдә... убыр уты яна.

Чаң какмагыз әле каланчада —
хәтер уты булып йөрәк яна.

Чаң какмагыз әле!..

## *Иң кыены...*

Иң кыены — кая язу?

Пергаментлар,
ташбилгеләр,
чөй язмалар!
Моны гына беләдер бит
сезгә хәреф тезгән җаннар?

Кыяташка кул куярга өлгермичә,
вакыт упкынына очкан
«кыргый стенографист»,
«Җырлар язам тауның күкрәгенә», —
дип белдергән Бабич,
Моабитта
«Ләкин кая языйм? —
Үзем белән бергә
үләләр»,— дип өзгәләнгән Җәлил...
Шәт, аларга билгеледер:
иң кыены — кая язу?

Суга сәнәк белән язучыдан
сорап тормыйм —
белмәслеге маңгаена язылган ич.

Намуслыга язар өчен
ак кәгазьдер, бәлки, иң кыены?!

...Гасырлардан өн ишетәм:
«Иң кыены — кая язу? —
Халык хәтеренә,
ха-лык хә-те-ре-нә...»

# *Балкыш, яки Хәйретдин Мөҗәйнең сугыш язмаларыннан юллар*

(Поэма-рулада)

## Автордан

Рулада... Җырның бик тиз башкарыла торган өлеше музыкантлар телендә шулай атала. Көй агышының тизәюе күбесенчә азактарак була. Гомер җырының руладасы кешедә кайчан башлана? Язмыш юллары ахырына табамы? Шулайдыр... Төпкә кадәр янган шәм дә якты балкыш ясап сүнә. Вакыт тарафыннан билгеләнгән соңгы гомер чиге ягасында, имеш, һәркем хыялый тизлектә балачак сукмакларыннан йөгереп кайтыр...

Сугыш фаҗигасе күпләрнең гомер агышын тизләтте һәм яшен яшәмәгән яшьләрнең дә чәчен агартты. Кырык чиген узып киткәч, гадәттә, еллар болай да ашыга башлый. Ниндидер катализатор вакыт агышын тизләтә шикелле. «Минем җилкәдәге кырык яшь...» Данлыклы полк командиры полковник Мөҗаһит Хәйретдиновка да гомеренең соңгы өч елында аеруча тыгызга килгәндер. Соңгы чиккәчә кысылган шушы вакыт аралыгында ул үзе бер гомергә торырлык еллар кичкән. Бөтен гомер буена янучы йөрәге Дахау миченә дөрләгән хәлдә кергән!..

Гомер җыры руладасы. Яшьнәп үткән еллар. Рәхимсез сынау вакыты. Цейтнот эзәрлекләве. Йөрәкнең бөтен барлыгына янып балкуы!.. Кыскасы, әлеге әсәр Ватан солдаты, шагыйрь Хәйретдин Мөҗәй турында.

Һәм башкалар хакында да.

**1.** *«Монда, нәкъ безнең Ык елгасы буендагы кебек, кара бөрлегән уңган. Бүген көн буе куаклар арасында бөрлегән ашап йөрдек. Бармакларым да, иреннәрем дә бөрлегән төсле күм-күк булды».*

«Сугыш язмалары», 27.8.41

*Монда җиләк күп икән,*
*Аю-бүре юк икән...*

Әгәр төштә йөрсәм ашап
бөрлегәннең карасын,
әнкәй мәрхүм сыгар иде
күзендәге бар яшен...

«И Ходаем! Хәтәр-хәвеф
килмәгәе илләргә...» —
Улларымның каралуын
юрар әллә ниләргә!..

«Нишләтмәкче кара язмыш
кара җиләк йоттырып?
Юкка гына алар шулай
уңмагандыр котырып...»

Үзе булса, «Кагылма!» — дип
сугар иде кулыма...
...Төштә түгел, өндә ашыйм —
аермасы шул менә.

Нигә юрап торуларың,
килгән инде киләсе...

Ачыттыра кара җиләк —
тамган мәллә ил яше?!

Соңгылары күңелемә
ятышмады бигрәк тә.
Шундый тойгы: җиләк каптым
үзем яткан зиратта (?!)

Әллә сугыш сыйламакчы
мине шундый сый белән?!
...Куакларга җиләк түгел,
кара күмер сибелгән...

Мондый хәлне ни дип юрыйм —
бәлки, йөрәк сизәдер?!
Җиргә кара җиләк булып
кайтырга да без әзер...

Куйчы әле — ватандарның
буламыни үз гаме;
бөрлегәнгә кунган бары
олы юлның тузаны.

Безне күмер хәлендә дә
танучылар табылыр.
Бөек җиңү табынында...
кара җиләк тә булыр.

...Соңгылары күңелемә
ятышмады бигрәк тә.
Шундый тойгы: җиләк каптым
үзем яткан зиратта...

**2.** *«Минем блиндаж янында бертуктаусыз снарядлар ярыла. Башны күтәреп-күтәреп карыйм. Менә окопта аягы өзелгән ак әтәч тыпырчына...»*

**19.9.41**

...Әллә ниләр хәтерләтеп,
әйләнде дә тулганды.

Бакчасарай тарихында
шундый бер хәл булган, ди...

Дошман явы якынлашкан
шушы гүзәл мәркәзгә.
Килеп җиткәч, кем әйтмешли,
очраган, ди, бер тазга...

Сукранганнар:
«Җенле урын!
Әйләндереп йөретте...
Килгәчтен дә табып булмый,
әллә үзен җир йотты?!»

Хан сарае табылмаган,
кайнап ташкан яу үче,
һәм шул вакыт ишетелгән
«сатлык» әтәч тавышы...

Манаралы түбәләрен
бакчаларга күмгән дә,
утыра, ди, Бакчасарай,
оеп, тирән үзәндә...

Туган йортны искәрмәстән
була икән сатып та.
...Яраланган әтәчебез
тыпырчына окопта.

Ярый әле баш өстендә
канат җилпеп очынмый;
дошман күзе ак әләмгә
охшатмасын өченме?!

Җәрәхәтле гаярь кошкай
кызганыч та, кызык та,
гыйбрәтле дә:
                                        әтәчләнеп
булмый алгы сызыкта!

Әле сугыш башы гына —
көрәш инде кисәтте.

Теге чакта әтәчләргә
самурай да төз атты...

Бөркетләрем!
Әтәчлектән —
куркаклыкка бер адым...
...Сугыш коштан корбан чалды —
исәнлеккә юрадым.

**3.** *«...Басудагы эскертләргә ут төртеп, төтен каплавы астында Журовкага кадәр китәргә булдык».*

**19.9.41**

Ничек инде ышанмыйсың
сезләрдә дә җан барга.

Рәнҗемәгез, эскертләрем —
кемдер тиеш янарга!

Тәрәккыят паровозы
алга бармый һич кенә,
Лазо төсле фидакярләр
ташланмаса миченә.

«...Атсаң, яндырсаң да...»

Немчурага җавабымны
шулай әйттем шигырьдә.
Вөҗдан кушып яздырганда
алдаламыйм мин бер дә.

Кирәк икән, утка каршы
кабынырмын ут булып.
Төтен очар, көлем калыр
Җир шарына йотылып.

Эскертләрем, менә шулай
утырыгыз җай янып.
(Илеңдәге төтенгә дә
була икән таянып!)

...Төрекмәнем*. Урта басу.
Шулкадәрле үз инде...

Авылыма чигендереп,
каралтсагыз йөземне?!
Кара мунча төтененә
качырмагыз сез мине!

---

* Төрекмән — Хәйретдин Мөҗәйнең туган авылы.

Мәсләгемнән тайпылмыйча,
кичтем күпме төн-көнне.
Исерталмас теге яктан
кергән ладан төтене!

Гүрдән атам-анам каргар:
«Ватанга да син үксез!»
Адашмаска!
Туган йортка
кайта алмыйм җиңүсез.

...Тотынырга сыңар салам
калдырмыйча үзенә,
төтенеңнең очкынлысын
җибәр фашист күзенә!

Мәңгелеккә томалансын —
уртак максат шушы ла.
Сезнең төтен Жанна д'Арк
һәм дә... Болгар тәрәккые
төтененә кушыла...

Әнкәй яккан коймак миче
төтенен дә табарсыз.
Ә хәзергә озатыгыз
Журовкага кадәр сез.

**4.** *«Таң ата. Аз гына ятып аласы килә. Ятам, ләкин күзләр йомылмый, баш һаман уйлавын дәвам итә. Кайчагында бөтен гәүдә кисәк-кисәк сикереп куйган төсле була».*

**20.9.41**

Тәүлек буе башым уйда —
татым беткән йокларга.

Вакыт әрәм
черем итү
кебек җыен юк-барга.

Инде менә ничә атна
итекләрне салган юк.
Сәгатемдә минут угы
гына йөри әйләнеп.

Салмак аккан вакыт хәзер
шарлавыктай ишелә!
Сәер халәт: уяу килеш
әллә нинди төш күрә...

Күкрәгемдә йөрәк типми,
ә сәгатьле шартлаткыч!..
Мандолинам кыска көйләр
генә уйный — шакылдаткыч...

Янар көчкә ашыктыра —
башка вакыт үлчәве.
Арттан дулап килгән чалгы
кыеп ала үкчәне.

Вакыт белән санашмаган
чак та булды югыйсә.
Ә сәгатең шартлаткычта
гомереңә чик куйса?!

Үкенечле салмаклыкта
башкарылган көй башы.

Көндәлеккә әллә нокта,
әллә өтер куясы?!

Мәрьямемә «Исән!» сүзен
язарга дип мең кыздым.
Хатың килсә
нуры төсле
инде сүнгән йолдызның?!

Булсын шундый тизлегендә
гомер атлы көй-агыш!
Куса да ул, үзебезнең
тегермәнгә коя ич.

Җилкәдәге кырык яшем
җитәр әле, хуш, әйдә,
ахыр чиктә газиз халкым
гомеренә кушарга.

**5.** ***«...Күзәтү урыны өчен җил тегермәненең эчен һәм эшләнүен карадым. Мин ул тегермәннәрне бик күп очраткан булсам да, эченә кереп караганым юк иде әле. Онга буялып чыктым».***

**6.10.41**

Яшәү утын көчәйтергә
ташы күпме ут биргән.
Нигезенә көнләп-еллап
он тузаны утырган...

Онта белән ныгытылган —
кальгаларга торырлык!

...Ничек күзләү торбасына
керә алган бер орлык?!

Карап туймыйм — шуннан гына
тора, имеш, бар эшем.
Олуг икмәк күзе аша
күзлим сугыш барышын.

Ачлык явы тылдан бәрсә?! —
җиңү авыр монысын...

Тегермәндә дары исе
баса төште он исен.

Миндәй авыл баласына
иң авыры шул хәзер.
Безнең өчен сугыш исе,
бәлки, шундый буладыр.

Бутамаска иде бергә
дары белән он исен!
Тегермәннең канатына
Дон-Кихотның сөңгесен
кадап, җиргә егылудан
файда килә кем өчен?

Икмәк атлы хакыйкатькә
кадый, җыеп бар көчен...
...Дурбиндагы бөртек аша
күзлим һөҗүм барышын.

Бәлки, алар сугыш ачкан
синең өчен җир даулап?! —

Авыр сорау төсле орлык
тора мием бораулап...

...Туган йортта мине көткән
икмәк хәзер таш инде...
Ризык — булыр, әгәр сугыш
ашамаса башымны.

Ятып калсам, шытып чыгар
кесәмдәге арышым.

...Яуга икмәк аша карыйм,
шуннан тора бар эшем...

**6.** ***«Эчтем, бераз үзем дә кыздым...»***

**24.11.41**

Йоттым шул,
тахилгә генә
эчкән, ди, бит тавык та.
Яшәү өчен күтәрдем мин,
утырсам да табут*та.

Юк, әҗәлгә каршы дару
салып эчмим касәмә...
Сугышта син көн дә үләр
куркак булсаң —
яшәмә!

Халыкларның канын эчеп,
исергәндә паразит,
көн да үлем исереклеге
белән йөрү — хәрам бит!

* Җор күңелле сугышчылар землянканы шулай атаганнар.

Эчми исерек булырлар, ди,
мәхшәр-үлем күзендә.
Ә мин аеклыктан гаҗиз —
нигә? —
Белмим үзем дә.

Шәраб сорап тилмерттеме
җанымдагы хәйямлык?!
Бераз кыздым, әмма җебеп
мәлҗерәргә чамам юк!

Юк, кыюлык өчен түгел —
кыз катына ашкынмыйм;
шулай ук җан сызлавын да
хәмер белән басмыйм мин.

Тиредән үк чыга-чыга,
бер сөйләшер өчен дә
эчмәдем мин. Болай да сүз
тоткын түгел эчемдә.

Шундый афәт вакытында
түгел күңел ачуым.
Бу башыма йөз ләззәттән
өстен бер уй баш бүген.

Риза: янып үләргә дә,
булсын хәерхаһ кына.
Эчтем гомер шәрабымны
Ватанымның
исәнлеге хакына!

## 7. *«Бүген мунча кердем...»*

28.11.41

Юындырды каен кызы! —
әйләндем күк сабыйга.
Карт тәнемә төште бугай
себеркенең сабы да.

Без бит сөттә коенмаган —
ник яшерим мин аны?!
Юк, үзең дә керләнмичә
пакьләп булмый дөньяны.

Ләйсән, үзе пычранмыйча,
Җирне ничек агартсын?!
Дөлдел түгел, тапсыз тотып
булмый мирнең ак атын.

Кызу сугыш үзе үк, дим,
кара мунча түгелме?
Йокса йоксын тәнгә корым —
каралтмасын күңелне!

...Ә мин, бәлки, үз мәетен
үзе юган үлемдар?!

Җирне мунча кертешергә
әле гомер түлем бар!

Пычрануга түзалырмын
ант пакьлеге хакына.
Тик төшмәсен ил алдында
йөзгә нахак тап кына.

Җанга — мунча?!
Сафланунының
бардыр башка юлы да.
Халкың өчен фида булсаң,
барысы да юыла.

**8.** ***«Ат бер юрта, бер атлый. Кучер — 39 яшендәге бер кызылармеец, аның үзе дә, тавышы да акрын, бер дә минем гадәткә дә, минем әтәйнең гадәтенә дә охшамый. Акрын хәрәкәтенә эч кенә поша...»***

**7.12.41**

Атның салмак атлавыннан
җаным өшеп, кан катты.
Бәгыремнән өстерәлә
салпы чана канаты.

Әгәр өйсәм алашага
иңемдәге бар йөкне!..

— Дошман угы каршысына
коштай очып барыйкмы?!

Эчпошыргыч үшән кучер
әнә шулай «ду» килә.
Ә мин ярсыйм: «Соңарырга
ярамый,— дип,— дуэльгә!»

— Бүлдерергә теләмисең
йоклап барган ат төшен...
— Ашыктырмыйк, Хәйретдиныч,
алгыр вакыт агышын.

Әллә сәгать туктап калган —
салып карыйм учка да.
Кыймылдамый утырамдыр
сыман кара мушкада...

Әллә инде тибрәткәләп,
саташтырды ат мине?!
Шушы мыштыр кучерымда
күрәм Сапый абзыйны.

Ябык чана зинданында
Апуш бара Җаекка!
Үрсәләнә янәшәдән
йөгерерлек җай юкка...

Шулай урап чыгуымы
тәкъдирендә язганны?
Әллә ясый маневрлар,
алыр өчен Казанны?

Атышырга ашыгамы
Кара елга катына?
Шул ук канлы чана бугай,
башка, ахры, ат кына...

Кемгә икән, кемгә икән
артка таккан чанасы?!

Бөтен илгә яный бүген
бароннарның яңасы.

Буран булып сукты оран:
«Патроннарны не жалеть!..»

Юк, җәяүле йокы, җитте —
бишегеңдә син ял ит!

Яный барлык шагыйрьләргә
бәрелешнең яңасы.
Ватан исән калсын өчен,
кемнәргәдер — атыласы,
кемнәргәдер — асыласы,
кемнәргәдер — янасы...

...Әкренлектән йөрәк сызлый,
кучерымның — янбашы...
Төштәй кыска гомеренә
гасырларны сыйдыралган
Тукайҗанның чанасы
алсачы!..

**9.** ***«Бүген бер фотокорреспондент мине, ак халат киертеп, фотога төшерде».***

**15.2.42**

Гасырлардан: «Төш, төш! — диеп,
киңәш бирә Кол Гали. —
Сүздән сурәт ясаучылар
сурәтсез дә калгалый...»

Канкай углы Бәхтиярдан
ишетмәдем хаклау ник?
«Дастан булып калучыга
сурәт нигә, полковник?..»

Мәгълүм инглиз китапчысы
сорап язгач фотосын,

Шиһабетдин Мәрҗанидән
галим ник бер хат алсын...

Мондый ядкарь таратуны,
бәлки, чүпкә саныйдыр:
«Хәтердәге сурәтеңнән
гайреләре фанидыр!..»

Сукыр Каюм: «Минем кебек
сурәт-сынсыз калма, дим!..
Һич югында, охранкадан
төшерттерә алмадым...»

Шаярткандай итте шулай
«академик» Насыйри.
Фанатиклар кычкырышты:
«Сурәт — хәрам — җан сорый!
Җан сорый!!
Җан сорый!!!»

...Фото-маһир Ксенофонтов
биләп алды бар гамем.
Бреслауда төшермәкче
булган фашист мәргәнен...

«Истәлеккә» калдырырга
ниятләгән ул аны.
Һәм төшергән... йөрәгенә
очып килгән пуляны...

Сурәтчене аткан фашист,
аткан, димәк, үзен дә.

Кара шәүләң катып калса
үлмәс халык күзендә?!
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Аермачык күзаллана
Кол Галидәй зур затлар.

«Мәңгелекнең суларында
агып китте сурәтләр,
агып китте сурәтләр...»

...Ә фотокорр ашыктыра,
алдырмыйча сулыш та:
«Моңланмагыз — Сезне ташка
басыйк әле шук төстә...»

Юк, рәсемгә уйсыз гына
төшеп булмый сугышта.

**10.** *«Сугыш башланганчы хатын-кызга минем караш бик ялгыш булган. Мин хатыннарны сугышта паника күтәрергә генә ярый торган кешеләр дип саный идем».*

**9.11.41**

*«Бүген Настя белән (без торган квартирада торучы 21 яшьлек кыз, кара чәчле, мөлаем йөзле, аның белән ни сөйләсәң дә, хәтере калмый) «Мин бу Скородноеда үлсәм, минем исемгә бер колхоз төзергә» сүз бирештек».*

**21.11.41**

*«Көн матур, кояшлы. Яз. Кызлар да матуррак та, дәртлерәк тә кебек күренәләр».*

**21.4.42**

*...Әтәч менгән читәнгә,*
*«Кик-ри-күк!» итәргә.*
*Әтәчкә хәбәр килгән*
*армиягә китәргә.*
*Әтәч әйтә: «Бармыйм»,— ди,*
*Тавык әйтә: «Калмыйм,— ди, —*
*син армиягә китсәң,*
*бер күкәй дә салмыйм»,— ди.*
*Әтәч армиягә китте,*
*чабатага утырып.*
*Тавык мескен карап калды,*
*күзкәйләрен тутырып...*

Көйли-көйли киткән идем
шушы никрут җыруын.
Итегемне әле һаман
сала алмый йөрүем.

«Җиңеп» кайткач басмачыны —
әллә ничә бәк явын,
мине күпме үгетләде
Хаҗуафа апаем...

«Кал», дип, кызлар кочагына
кертмәк булды җим белән.
Имеш, гыйшык гашрәтендә
сәргаскәрләр җиңелгән!..

Йотылырсың — әгәр язса
юха кыздай зәһәр яр.
«Китәм,— дидем,— өйдә ятып,
алып булмас шәһәрләр...»

Ымсындыргыч «Калчы!..» сүзе —
агып тора баллары...
Сугышта да очраштырды
арзан ишек баулары.

Әсир фашист кесәләрен
әйләндергән чагында,
туры килде күргәләргә
«шикле резин» кабын да...

Гыйбрәтләрнең төрләләрен
күрдем сугыш юлында:
Мәхәббәттән нәфрәткәчә
төшкән гаурәт колын да,
«Илем, анам, ярым!» — диеп
янган йөрәк көлен дә...
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
«Зәгыйфь затлар» аркасында
чыккан кайчак сугыш та...
Юк, юк, мондый нәтиҗәгә
килмәм соңгы сулышта.

...Бүген Настя әйтеп куйды
үзәгемне өзәр сүз...
Ярый, кызлар, исемемне
кушып колхоз төзәрсез.

Ташбилгем дә калмас, бәлки,
ядка алып еларга.
Яратудан янды, диеп,
я-ра-ту-дан ян-ды, диеп
аңлатырсыз елларга.

**11.** *«...Минем үлемем — минем Ватаным, минем сыйныфым үлүе түгел ич. Шулай булгач, без: «Безгә үлем юк!» — дибез».*

«Сугыш язмалары», 6.1.42

Үзен-үзе утка бирер
әкияти феникс —
янә көлдән яралучы
мәңге үлмәс фани кош...

Шушы җанкай әллә ничек
төшкә кереп йөдәтә.
Нигә язмыш катгый сүзен
читләп-читләп йөз әйтә?!

Юраунамә, чегән төсле,
матур алдап, көл миннән.
Без... яңадан яралганнар
мәгъмүр Болгар көленнән!

*...Шәһре Болгар каласында*
*Көлбикәнең*
*коесы тирән, суы юк.*
*Шәһре Болгар каласының*
*исеме калган, үзе юк,*
*исеме калган, үзе юк...*

Хәтта нәсел агачының
көле күккә очса да,
халык рухы, фениксдай,
яңарырга көч таба!

Кат-кат янган Идел-йортын
яңабаштан гөл итә.
Хәрабәдән Мәрьям ана
булып калка Көлбикә...

Утка каршы фидаича
януыңны ил көтә!
Синнән тимер бөти* генә
торып калса көллектә?!

Мәңгелекнең балдакланган
кошы булу язганмы?
Башка уйлар эзәрлекли
әле бүген абзаңны.

Фашизмның каракошы
янар —
тынмас җан һаман.
Әллә ничә башлы булып
терелмәсме яңадан?

Тагын гайрәт иңдерсәләр,
авызына салып кан?!

...Җирдә күпме мәдәният,
янып, кабат калыккан.

Җирең янса, Кояш улы
янган төсле яшендә, —

* Хәрбиләрнең кемлеген ачыклаучы янмый торган тимер билге күздә тотыла.

көлгә җан-рух өрер өчен
ярдәм итмәс әфсен дә...

Миләремне изә вакыт —
тыгызланган бигрәк тә.
Тамырларым, бикфорд кебек,
янып килә йөрәккә!

Утка каршы фидаича
януыңны ил көтә.
Йөрәккәйне күңел кошы
«Үлем юк!» дип җилкетә,
«Үлем юк!» дип җилкетә!..



# III БҮЛЕК



## *Яшьлек кайтавазы*

Кай уемнан ваз кичәрдәй булсам,
йолкып ала мине хыял-ат.
Ятим калган яшьлек кайтавазы:
«Хыялларга итмә хыянәт!..»

Хыялларын барлап,
«Кем булдың?!» — дип
әйтер күк ул бәреп маңгайга.

Ул чак кояш якынрак булган
каен башындагы малайга...

# *И балачак...*

**1**

Дөньяң кысан булса да бит,
ямьлерәк иде бугай.
Елаганда күз яше дә
тәмлерәк иде бугай.

Бүлешәсе малыбыз юк,
юк сиңа барачагым.

Әй, яшел балачагым...

**2**

И балачак...
Каен кызы
ширбәт биреп эчергән чак,
телдә җир һәм кояш тәме —
чык исеннән исергән чак,
җир өстендә кабак кебек
аунап үскән,
уй кергән чак,
и балачак — хөр утрау —
татлы гомер кичергән чак,
хыялларны гына алып,
бирге ярга күченгән чак...

## *Болын чәчәкләре арасында*

Бу болында тик икәү без:
шәүләм дә үзем.
Ни кылсам да —
карап тормый
кешеләр күзе.

Бу болында мин кунак та,
хуҗа да — үзем.

Чү!
Текәлеп бага миңа
Күгәрчен күзе...

## *Җир тәме*

— Җирнең тәме нинди була?
— Җиләктән дә татлы була.
— Җирнең тәме нинди була?
— Әремнән дә әче була.
— Җирнең тәме нинди була?
— Боз-кардан да төче була...

Бу тәмнәрне бердәй татып,
яши алыр кешеме син?
Менә шундый булсаң гына
Җир тәменә төшенерсең...

## *Көнгә шөкер кылу*

Чираттагы төшемме бу?!
Юк, мин, ахры, өнемдә, —
үзгәрде дә куйды кинәт
(халәткә иш) көне дә.

Бу кояшта гөлләр булып
кайтарылыр нур кайда?
Баш өстендә үчекләшеп
әйләнә күк тургай да.

Мондый хәлгә тарыдыммы
берәр яман эш кылып?!
Болытлар да ага сыман,
бәгыремә ышкылып.

Әнекәем, нигә әле
бүген дөньям буталды?
...Оныткамын, шөкер кылып,
каршыларга бу таңны...

## *Хәтернең бер хәтерсезлеге*

Елый-елый көлгән малай чакның
керфегендә кояш тирбәлә!
«Исеңдә тот: күз яшенең тәмен
онытырга тиеш ир бала».

«...онытмаска тиеш...»

Томан сарган хәтер төпкелендә
искәртүе яши әткәйнең.
Онытырга? Әллә онытмаска? —
анык белмим ничек әйткәнен.

## Ияр

(Ата белән малай)

— Тәңкәләре — бизәнүдер,
өзәңгесе нигә соң?
— Ул булганда, аякларны
җирдә итеп сизәсең.

— Нигә ияр? Ат сыртына
куеп була мендәр дә...
— Ияр — егет тәхете ул —
син әзерме менәргә?

## Башка уй төшү

*Малай чак хатирәсе*

Болын юлы. Бер ят әби
җиләкләр бирде безгә.
Санадык та берәмтекләп
бүлештек җидебезгә.

Насыйп булган өлешемме?!
Инде кем белгән аны.
Әллә ничек чыкты миңа
гарибе — имгәнгәне...

Әмма үзе, изелсә дә,
җуймаган җиләклеген!..

...Нигә соң ул кабат-кабат
хәтергә килә бүген?!

## *Ут-малай ат тышаулый*

Көмеш тәңкәле йөгәнен
тез астына салган да
туп кадәрле генә малай
ат тышаулый яланда.
Яшен төсле уйнаклый ат —
тоталмассың ялын да!
Ташкын туктап калганмыни
шул ут-малай алдында.
Җен атын да буйсындырыр
ирлек бар бу оланда.
Әллә хакмы: балаларны
чакмый, диләр, елан да...
Шулай аңа баш бирерме
ярсу хыял аты да?
Ул да кайчак ташлап китә
йә утырта катыга.
Иркенлеккә җибәрсәң дә,
йөгән калсын куенында.
Тамыр төртер җире була
башка сыймас уйның да.
Кайчак олы нияттән дә
шулай куркып куясың:
януын да белми чапкан
ат күк башны җуймасын.
Яле, күрсәт ирлегеңне —
ярсу ат бит заман да!

...Туп кадәрле генә малай
ат тышаулый яланда...

# Көндәшлек

Атка сыенып тай үсә,
ел үсәсен ай үсә.
Йөгәнсез малкайлар иде
кичә генә югыйсә...

Без күз атып йөргән тайлар,
«Синеке», дип, «Минеке» —
бүген тәртәгә кергәннәр,
ватып чыгып иннек*не.

Кысан утарлардан, дулап,
дөньяга сикергәннәр.
Күз алдында үскән тайлар
буразнага кергәннәр.

Хыялларга кул тимәгән,
без, ахры, һаман бала...
Утарларны ватып чыккан
тайларымнан оялам.

---

* И н н е к — аран-киртә.

## *Ышаныч*

Картлар китә соңгы юлга,
фатихалар кала:
— Хуш, бала...
Сезнең кулда шушы Җир кала...
Бездән арткан үксез хыялларны
үзеңнекеләргә куш, бала...

Хуш, бала!..

## *Ут эчүче ат*

Су эчәргә төшкән ат та,
су да кызыл — тоташтан.
Бу салкын ут ага төсле
баеп барган кояштан.

Шул ат эчеп бетерер күк
инешемнең бар суын.
Әллә шулай басмакчы ул
җанындагы ярсуын?!

Иртән — чабыш!
Кояшлы су,
ат тәненә көч иңдер!..
...Ул үзе дә йөрәгенә,
ут эчеп, ут өстидер.

## *Сабан туенең икенче батыры*

Изелсәң дә Сабан туе
пәһлеваны астында,
халык сине, «Батыр!» диеп,
аягыңа бастыра.

«Киләсе ел баһадиры»н
төшермиләр кулдан да...
Уйландыра
иңбашыңны
картлар сыйпап куйганда.

Алда кемнәр аркан төшәр,
очып синең баш аша?
...Ә җирдәге чын көрәшнең
кануннары башкача.

Барсы хәләл генә булмый
монда хәрәм алышта.
Чиккән сөлге тирең сөртми,
юк көч бирер алкыш та.

Җиңүче дә кулын бирми —
егылгансың —
кал җирдә.

...Арка белән ята микән
Карәхмәтләр... кабердә?!

## *Югалмаска!*

Таудан аска ыргый чишмә —
чишмәгә тау кирәкме?
Биеклеккә күтәрергә
язган миңа йөрәкне.

Җиргә китсә,
кибеп бетсә —
чишмәләрне ни көтә?..

Югалмаска кирәк миңа,
югалмаска ничек тә!

## *Мәтрүшкә*

Малай чагым. Өйдә шау-шу.
Гаҗәп хәбәр —
безгә Коръән җибәргәннәр Себердән.
Шушы изге китап белән сабый җанга
гомер буе ачылмаслык сер иңгән.

Кардәшемнең соңгы ядкаренә
аулак кичтә ничә тапкыр тартылдым.
«Рәсем»нәрен эзләштереп утырганда,
көтелмәгән күренешкә тап булдым.

Сәер табыш, сискәндереп, өнсез итте,
уйнак малай әверелде мәэюскә.
...Инде менә ничә еллар истә тора
иске Коръән эчендәге... мәтрүшкә!..

Сулар акты. Җилләр исте. Комнар күчте.
Янгын чыгып, гаип булды Коръән дә.
Мәтрүшкәләр менә тагын миңгерәтте,
печән чабып, яшел чатыр корганда.

Яманатлы сөргенченең әманәте, —
хәзер инде булмый аны аяп та.
Гаҗизләнәм: кыстырылган мәтрүшкәсе
кибеп ятты икән кайсы аятьтә?!

Күзалларга җөрьәт итәм үземчәрәк:
«Тынычланып, Тәңребезгә кайт, кеше!..»

Коръәндәге нинди битне билгеләгән —
«Тәзәккәрү»? «Тәфәккәрү»?* Кайсысы?

Инде хәзер малай чакның шушы сере
хәтеремне эзәрлекли һәр төштә.
Абзыкаем үзе генә аңлатмасмы,
күрешергә насыйп итсә гарештә?!

Ирексездән мордар киткән ырудашым
язган булса өч кенә сүз, өч кенә!

...Мәтрүшкәнең учымдагы чәчәкләре
ява төсле ләүхелмәхфүз** өстенә...

---

* Коръәннең «Искә алыгыз!», «Уйлагыз!» дип башланган аять-ләре күздә тотыла.
** Л ә ү х е л м ә х ф ү з — язмыш тактасы.

# *Пирамида*

*Классташларым Марсель, Таһир,*
*Фәрит, Нургаян, Раиф истәлегенә*

Сабакташлар, без бит, сөбханалла,
шундый дәртле, сылу, төз идек!
Хәтерлимсез: мәктәп сәхнәсендә
тере пирамида төзедек.

Җилкенешә идек җилеккәчә,
ноябрьнең җиткәч җидесе.
Угъланнарны бергә укмаштырып,
күккә чөйгән нинди җен көче?!

Кайнаткандыр кайнар каныбызны
«бөек корылыш»лар шаукымы...
Йөрәгемнән һаман ерагаймый
мәктәп елларының шул көне.

Күңелемне ничек күнектерим —
эзәрлекләп тора авыр моң.
Мәчетләре әле манарасыз,
айсыз чагы иде авылның.

Сихерләгеч мәктәп сәхнәсендә
пирамида булып калыктык.
(Балавыздай күндәм балаларын
йөзгә әвәләүче халык юк...)

Империя кемне имгәтмәгән,
тере килеш салып нигезгә.

...Башыгызга менеп басуларым
бәгырь-үзәкләрне ник өзә?

Иңдәшеңнең иң-иң имәндәен
югалтудан тагын ни ачы?
Пирамида төзгән пионерлар —
җиргә иңгән инде ничәсе.

Гамәлләрен комнан әмәлләүче
җаһил чорның, имеш, син колы.
Таралышкан салның терәкләрен
йотып тора еллар чоңгылы.

Галстуклы «гөнаһ капчыклары»н
каргадымы берәр фиргавен?!
«Яшәсен!»не дәррәү яшьнәткәндә,
кызлар өнсез калды беркавым.

«Вакбаш»ларга, баксаң, бакыйлыклар
теләгәнбез, узып Алланы.
«Яшәсен!»не әйткән яшьтәшләрем,
ничаклыгыз яши алмады.

Нурланышып торган ниргәләрнең
суырмады язмыш күпмесен?!
Куптарылган айлар күтәрелсә,
кулайрактыр, бәлки, Күк өчен...

Парә-парә килде пирамида,
әллә Җире юлдан язганмы?!

...Шәригатькә сыймас шәрикләрем,
кичердегез тәкъдир язганны.

Ерагаймый мәктәп йөрәгемнән,
мине аңа тагы күз дәште.
...Үкенечле, ай-яй, үкенечле
хәрабәгә тамган күз яше.

«Яшәсен!»нәр белән яшеннәргә
үрелгәндә сылу, төз идек!
...Сүтеләсе мәктәп сәхнәсендә
тере пирамида төзедек...

# *Аламачы*

Кычкыруы ерак балачактан
ишетелә бугай хәзер дә.
«Авызына чүпрәк тыгуыбыз»
кичәгедәй тора хәтердә.

Авылдашлар бер дә кысмырланмый,
иске саклый, диеп, яңаны.
Бакча карачкысын илтеп тапшыр —
аламачы ала — аңа ни?!

Сандыкларсыз калган авылында
кем соң алам-салам мал саклар?!
Чүпрәкченең тирән арбасында
китеп барган иске калфаклар...

Аламачы чүпрәк теләнүдән
исәпләми иде туктарга.
Апушлардан калган кәзәкине
алмашканбыз җыен юк-барга.

Чикмән, хөллә, чапан...
Минем өчен
тарих яши иде чоланда.
Исең китмәс булса, иске белән
китеп барыр әйбәт йолаң да...

Борынгыны мин дә алмашыштым —
яңагамы? —
аны кем белгән.

...Аламачы аты, гаип булып,
мәңгелеккә инде күмелгән.

## *Иделгә карап хәтер яңарту*

Борылып-борылып карый Идел
чишмә булып аккан чагын...

...Итәк җиләннән дә авып,
кабат торып баскан чагым;
колын сыман, үз-үземне
белештерми чапкан чагым;
болыттагы ләйсән яңгыр
тамчысыдай ак-пакь чагым;
боз өстендә учак ягып,
егетлеккә аккан чагым;
мәхәббәтне, беркемне дә
кабатламый, ачкан чагым —
җир бетереп эзләгәнем
күрше йорттан тапкан чагым;
чынлыгыма алып барыр
сукмак башын сапкан чагым...

...Борылып-борылып карый Идел
чишмә булып аккан чагын...

## *Чынлап «качышлы» уйнау*

Уен башлап, дәррәү кача идек
бакчаларга, иске йортларга.
Һәм әнкәйләр безне, тирги-тирги,
эзләп ала иде йокларга.

Ә соңыннан еллар, туктамыйча,
санадылар унга, унбишкә...
Югалыштык чынлап,
бала чаклар
яшеренеп калды ул кичтә.

Кычкырсаң да тавыш бирүче юк,
ник, уендаш, эзләп тапмыйсың?
Берсе җир читендә, икенчесе...
Җир яшергән инде кайсысын.

Кайтып күрешәбез көтмәгәндә —
башыбызга кунган кар төсле.
Күмелешеп еллар офыгына,
уйныйбыз күк һаман качышлы.

## *Күз яшьләре тәссез*

Ярый әле күз яшьләре төссез —
елаганны яшереп була.
Күкрәгеңә башлар орып
еласыннар,
үзең ела бер туйганчы,
ак күлмәгең юылганчы —
яшь тиз кибә,
әйтерсең булмаган берни дә.

Яшеренеп йә бикләнеп,
шашып ела,
ташып...
Күз яшьләре төссез,
тиз югала —
елавыңны ятлар белми кала.

Кара булса күз яшьләре
йә ак булса,
сак һәм кырыс әтиләр дә
яшералмас иде аны.

Ярый әле күз яшьләре төссез —
яшь үтәли күреп була Кояшны!..

## *Елмаюлар*

Елмаюлар әллә йогышлымы? —
көләчлегең күчә бүтәнгә...
Тик эченнән ниләр уйлый икән
ирексездән көлгән бу бәндә?

Кемнең кемлегенә карамыйча,
син нур өләшәсең
Яз сыман!..

Елмаюлар төрле:
кайсы — ихлас,
ә кайсысы — мыек астыннан.

Ә бит мөлаемлык битлегенә
яшеренми нинди уй гына?!

Сабый чакның садә елмаюын
сакласаңчы гомер буена.

* * *

Оя-оя кошлар китә,
түбәләргә орынып.
Кош — ирләр күк —
ярты юлдан
кире кайтмый борылып.

Каурый болыт кошкайлардан
калган кебек ябышып.
Баш өстендә ак кавырсын —
илдән киту сагышы.

## *Йөрәкнең очынуы*

— Нигә шулай,
утыргычның бәен өзәрдәй булып,
чылбырланган Прометейдай алгысынып,
иллюминаторга капландың?

— Авылым өстеннән очтым!
Авылым өстеннән!..

## *Туган йортта*

**1**

Мичтән ипи чыгаргандыр әни,
мендәрләргә тезеп салгандыр.

Чалма-чалма болыт, күк тутырып,
баш өстендә туктап калгандыр.

Көмеш балдак балкып калыккандыр
буй кызларга чишмә төбеннән.

Мәчеттәге айсыз манарага
ай кунгандыр, төшеп күгеннән.

Тургайларым коенадыр күктә,
буразнага йолдыз тамадыр.

Тамырлыдыр илнең нигез ташы,
тәрәзендә таңнар янадыр.

**2**

Чык янамы җиләк яфрагында,
җемелдиме кояш тамчысы?

Арышларны кыйнап үстерәме
аҗаганнар — арыш камчысы?

Исән-саумы минем кендек әби,
чалләләрдә үлән пешәме?

Сабан туе батырлары кемнәр,
игеннәргә сөт мул төшәме?

Әнкәй туфрагында йорт салырга
бармы әле яңа урыннар?

...Бураznaңнан бүз тургайлар итеп
күккә күтәрәсе җырым бар.

**3**

Туган йортка күптән кайтканым юк, —
кыегында ае баткандыр.
Җил капкасын җилләр каергандыр,
ишегалдын чирәм баскандыр.

Сеңелкәем идән себергәндер —
сагындым мин әрем ачысын!
Башка җиргә яшергәндер әни —
таба алмам ишек ачкычын...

Тәрәзәдән чыгып качкан улын
эзләп әнкәй ишек ачар күк.
Ак каеннар, тыйнак кыз шикелле,
кочагымнан чыгып качар күк...

Туган йортка күптән кайтканым юк, —
бүтән урындадыр ачкыч та...
Юк!
Камырлы кулы белән әнкәй
кочып алыр мине баскычта.

# *Түшәм*

Тартылганда галәм түрләренә,
башым сиңа ничә бәрелде.
Айга ашкан үги кызга гына
серләр ачар чамам бар иде.

Мине чикли белгән алтын түшәм,
(фәрештәмә, бәлки, идән син)?!
Ике яктан туфрак кысып торгач,
сикереп булмый, нихәл итәсең.

Тарафыңа бер дә төкермәдем —
күңелемдә тотмыйм кер-кинә.
...Сырларыңда серле чиксезлекнең
төпсез упкыннары күренә!..

Сабый чакта шундый биек идең,
хәзер инде бераз үзгә без.
(Җирнең асты өскә килгән мәлдә (!)
бишек бөҗраларын эзләрбез...)

Синме әллә күкнең аскы каты —
кичә алган вакыт туфанын?
Туган йорттан читтә нәрсә әйтим:
җиңел булсын авыр туфрагың...

## *Кайту*

*Чәнечкеле тимерчыбык белән әйләндереп алынган зират яныннан үткәндә*

Читәннәре — чәнечкеле чыбык,
шомыртларның тора биленнән.
Качып кара, имеш, син дөньяга,
качып кара мазар иленнән.
Эчтә калган чия чәчәкләре,
каралмаган — һаман ак төсе...
Җиләклекләр тора җемелдәшеп,
ташка сеңә каен яктысы.
Сибә генә былбыл, сибә генә —
мәэюскә дә канат куя җыр!
Монда гөләп тышка чыгып үсә,
ә энәсен... эчкә коядыр.
Читән аша каен атлап чыккан,
тамырлары чыккан яктырып;
орлыкларын чәчкән дөньясына,
сөендереп туган як кырын.
Кош баласы, канатларын язып,
очып китә моннан пырылдап.
...Урамнарга кереп бара каен,
тормыш моңын тыңлап, җыр тыңлап.
Үрмә гөлләр авыл тарафына
үрелеп-үрелеп карап торалар.
Бакый җаннар, ак каеннар кайта,
ил-бакчага кайта куралар.
Читәннәре — чәнечкеле чыбык,
шомыртларның тора биленнән.
Качып кара, имеш, син дөньяга,
качып кара мазар иленнән...

## *Мөһаҗирләр*

Без бит мең тамырлы нигез җирен
алыштырыр өчен тумаган.
Язмыш читкә куып җибәрсә дә,
туган йорткай безне кумаган.

Гомер чишмәләре адаштымы —
язмышыбыз булды болганчык.
Ил чирәмен кочып елар идек,
ак күлмәкләр яшел булганчы!

Ватандагы гүр дә яктырактыр...
Чит туфракта ничек каласың?
Үги итмәс микән туган илкәй
кабер сорап кайткан баласын?!

## *Күченеп кайт, диючеләргә*

Мең борылыш артында син,
чишмәм башы...

Тик кайда да газиз икән
нигез ташы.

Җибәрмичә тота башлый
корган оя.

Туган җир дә, торган җир дә
җанга сыя.

Баш өстеннән кояш тып-тын
очып бара.

Агач кебек тамырлангач,
күчеп кара!..

## *Авыл карчыклары чәй эчә*

Чәй эчәләр,
тәм-том белән бергә,
эч серләрен салып уртага.
Кешелекнең кадим эчемлеге
җаннарына гүя ут яга.

Күңелләре чәй шикелле ташый,
һәм яктырып китә йөзләре.
...Җир читенә ишетелә кебек
көмеш самавырның гөжләве.

Чәйләренә кояш канат тыккан,
җәйләү читләрендә чык яна...
Хуҗа карчык сөенечкә юрый,
чәй бөртеге өскә чыкса да.

Кемне җилкендерми, чәй эчкәндә,
тәнгә илаһи бер көч керү?
Карт-корыны, кочагына алып,
тирбәтә күк татлы исерү...

# Баз

Каралтыда казыр урын
калмаганмы аршын да?
Бу яктагы күп өйләрнең
базы авыл башында.
Ә кайсысы — ихатада —
керә алмый яшен дә.
Үзендә ул, сандык кебек,
әллә ниләр яшергән.
Авыл читендәге базлар,
кое сыман, биксездер.
Кызыксынсаң, сикереп төш тә,
ниләр барын тикшер бер.
Һәм көндезге йолдызларны
күзәтеп ал аз гына...
Монда иркен — охшамаган
комсыз йомран базына.
Мамонт аулау чокырлары
түгел болар — күр менә...
Халык рухы катламнары
базларда да күренә.
Бөтенесен алдан күреп,
үттем авыл тупсасын:
ачык йөзле, киң күңелле
затлар монда күп тә соң!
Кыркапкадан кергәнче үк
белеп була барсын да.
...Бу яктагы күп өйләрнең
базы авыл башында...

## *Чалгы*

Печәнгә чыгасы авылның
чүкелеп куелган чалгысы.
...Болында төн буе йөренде
Хозырга охшаган чал кеше.

Ямь-яшел таягын селтәүгә,
сайраудан тукталыр сандугач.
Ниндидер илаһи тамырга
чалгылар төртелер таң тугач.

Соңгы төн. Андызның шифасы
тамырга төшәсе иткән чак.
Пәйгамбәр чәчәге, сәҗдәгә
киткәндәй, егылыр иртәнчәк.

Күренеп югалды томанда
Хозырга охшаган чал кеше.
...Йөзенә салкын тир чыгарып,
уянды авылның чалгысы.

## *Өй күтәргәндә*

«Мәчет хәтле булды бу!» — дип
куанып, өй күтәрдек.
«Бүрәнәсе — сагыз,— диләр, —
гомереңә җитәрлек».

«Гомереңә җитәрлек...»

Шул соңгы сүз күңелемә
китте кебек ут салып.
Нигеземнең иңәр чагын
уйлап куйдым уфтанып...

## *Көшел өстендәге көрәк*

Таш дәвере,
бронза,
тимер...

Чордан чорга, көрәп-өеп,
ул үзенчә юл саба.
Баштанаяк агач кына,
агач кына булса да...

# Мичче

Туган йортның миченә бер
аркамны терәп торыйм,—
җаным аша ага башлый
Гольфстрим!..

«Кояш батареен ясаучы бар,
мичче табып булмый авылда.
Өйрәнмиләр — борча дагалау күк
катлаулы да түгел, авыр да...»

Тимербае кая, Әхмәтшасы?..
Чынлап, бер очта да юк алар.
Барысы да, кайтмас җиргә китеп,
кем әйтмешли, кирпеч сугалар.

Һөнәрләрен алып калмаганбыз —
«китаплары» белән күмелгән.
...Мичче китә...
Һәм бер җылы нурын
югалтадыр төсле күңел-җан.

## *Сандал*

*Атаклы тимерче Фатыйх абыйга*

Кызган тимер, кызыл сут балчыктай,
әллә ничә төргә үзгәрә.
Сандал гына кала элеккечә,
типчесә дә үзен йөз яра.

Зәһәр елан сыман бөгәрләнеп,
богау... беләзеккә әйләнә.
Ә югыйсә сандал шундый гади —
юк тылсым да, сер дә, хәйлә дә.

Тимерченең кайчак каны кайный,
сандал кызмый, ипле эш итә.
Тавышы да үзгәрүне белми —
гел бертөрле чыңын ишетәм.

Әкияттәге бүре тавышын ул
үзе әнә ничек нечкәртә...
Чүкеч эштән чыга, ә сандалда
күп кыйналган саен көч арта.

Кайтавазын яңа гасырларга
ташый-ташый хәтта җил арган.
...Тимер сандал имән түмәр аша
җиргә, ахры, тамыр җибәргән...

# *Көтүчесез авылда*

Сорап тормый чират:
бармы теләк-дәртең —
авыл көтүчесе
булып ала һәркем...

Кибетче дә,
бригадир да,
тире җыючы да,
мөгаллим дә,
склад мөдире дә,
хаким-башлык хатыны да,
ялга кайткан профессор да...

Чыбыркы һәм курай
өйдән өйгә йөри.
...Көне буе өстә
«чүл кояшы» көйри.

Ваклык, гайбәт, үчтән
монда һәркем өстен, —
бәлзәм итеп сулый
сөтле тузан исен.

Тансык җиргә янә
яланаяк баса.
Телисеңме: суга
ипи манып аша.

Комга борын төртә
хәтта кәгазь кораб, —
күлләр кибеп бара...
Кайта барсын карап.

Акрын йөри сәгать —
кала төсле артка.
Дөрес яшисеңме? —
уйлан шушы хакта...

Чират җиткәч, Феокрит*
булып ала һәркем.
Көтүчесез калу
яхшыгадыр, бәлкем...

* Феокрит — «Көтүчеләр поэзиясе» вәкиле буларак танылган борынгы грек шагыйре.

## Өзелгән әңгәмә

— Авылда да туу кими:
бер класста — бер бала...
— Бәби кайдан алып кайтыйк? —
саекты бит елгалар.

— Бүген шулай, ә иртәгә
ябылмасмы мәктәпләр?
— Күп баланы кем китерсен? —
азайды бит ләкләкләр...

— Яле, уйнап сөйләшмим ич,
борма әле уенга!
— Уенга?..

## *Балачак эзләреннән йөргәндә*

Үз елгамны танымадым:
юлын борган, саеккан;
ерагайган,
мин киткәндә,
бәйдә калган каектан...

Каек-көймәм!
Дулкынына
мәңге кайтмас ак балык.
Хәтер яңартырга куркам —
китәр кебек таралып.

## *Керәшәле ярлар янынннан үткәндә...*

...Ояга кул сузу теләгеннән
мин тыелып калам чак кына.
Күпме үрелсәм дә, буем җитмәс
е-рак-та-гы малай чагыма...

## *Авыл урыны*

Әле кайчан үзәнеңдә
утыра идең балкып.
Күз алдында, күз алдында
яндыра, күмә вакыт.

Кемнәр сине, кемнәр шулай
еллар төбенә салган?
...Арыш кыры уртасында
зиратың гына калган...

## Ауган арыш

Егылгансың.
Нигә юрыйм моны?
Әллә Җирме сиңа елышкан?!
Иелгән баш, димим —
синдәй затлар
куркамыни вакыт-кылычтан!

Иренгәчә күтәрерләр сине —
ярларыңнан, әйдә, түгел бер!
Җир хикмәтен җыеп авырайгач,
егылу да гөнаһ түгелдер.

## *Фанилык*

Абагалар арасында
корган имән ботагы...
Тузган инде, узган инде
язларына байрак кебек
җилфердәп чапкан чагы.

Иелеп баксам, ни күзем! —
болан мөгезе...

## *Бер төнлек күбәләкне юату*

Гомерне ник азсынырга?! —
Оптимист җан бул, әйдә.

Күз алдында Җирдән картрак
йолдыз мөмкин үләргә.

Эз калдырыр өчен кайчак
җитми йөз ел вакыт та.

Ә син, бәлки, төн яшәп тә,
уелырсың якутка!..

## *Яшәүчәнлек*

Төн кунагы күбәләк тә,
черки дә гомер кичә.
Көзге учак —
үләннәрдән
чәчрәп орлык оча.

Зираттан гөлләр күчә...

Өрәңгедән кар өстенә,
җир эзләп, орлык төшә.

Кабер ташы да үсә...

## *Күңелдәге тартышу*

**1**

Кибеттә бер хатын зары
килеп керде колакка:
«Ак буяу,— ди,— таба алмыйм —
әллә кая олаккан...»

Уйлап куйдым: яктылыкка
туйган күңел сирәктер.
Ак буяуның җитмәвенә
сөенергә кирәктер.

**2**

Хәтта кояш йөзендә дә
кара таплар булгандай,
аккошлар да ап-ак түгел
икән борынлаганда.
Акмы каен үрентесе
җирдән башын сузганда?..

Аккошлар да, каеннар да
яши-яши агара.
Тик бүтәнчә тартышадыр
калебтәге ак-кара.

Һәрбер кеше күңеле дә
ак-пакь була туганда.
Кайберләре карала шул
үсеп дөнья куганда.

Аккошлар да, каеннар да
яши-яши агара...

# *Шаһитлык*

Аккош күле. Төнге бакча.
Йокы алмый бөртек тә...
Кинәт чүгеп, биһуш калдым —
ис иңгән бит бөтнеккә!

Бәрәкалла, шушы төндә,
бәлки, шушы сәгатьтә...
Җирме күккә тынын өргән?!
Бераз гына сагайта.

Нигә әле шаһит булдым
туган чакта могҗиза?
«Бөтнек исе! Бөтнек исе...» —
эчтән кылдым мең нида.

Җанда шөбһә, җанда шатлык,
җанда сагыш — бар да бар.

...Мондый төндә яшәп калу
мәңгелеккә бәрабәр.

# *Исерек бал кортлары*

Татлы чәчкә суты гына түгел,
чып-чын зәмзәм суы исерткән.
Очыналар: «Бөтен гомеркәйне
шундый кәеф белән кич икән!»

Аракыдан авыз итүчеләр
айный, диләр, кырык көннән соң.
Кырык көнләп кенә яшәр мәхлук...
гомер буе, әйдә, кинәнсен.

Карганадыр төсле аналары:
«Түбәнлектә шулай буталчы!»
Болай булмас иде,
«чаршын» итеп
хәмер бирми калса мут балчы.

Корткайларны карак күбәләккә
әйләндергән хуҗа алдавы.
Күршенекен урлап юаналар,
яуган чакта күктән бал җавы*.

Гайрәтлесе җанны җылытканда,
үлә-үлә нигә бал җыйсын!..
Хәшәрәти кортка әйләндерә —
аракыны алдый алмыйсың...

---

* Бал җавы — бал чыгы, баллы сыекча.

Исерешкән кортлар кайнашуын
читтән күзәткәндә көл-ела.
Балавыздан койган тәңкәләре
шайтан таягына коела...

Сәҗдә кылыр затта әллә нинди,
кырга сыймый торган кыланыш.
Фаҗигале хәлләр күзаллана,
төшеп китә тәмам кулдан эш.

Эшлеклелек белән чисталыкны
күрә идек алар йөзендә...
Телкәйләре әллә көрмәкләнгән —
юньләп әйтә алмый «Без-з»ен дә.

Умартаның көчле икәнлеген
аңлатмыйдыр эчү шау-шуы.
Файдагамы булыр махмырлыктан
котыручы кортның чагуы?

Йөрәгеңә дәррәү батырсалар
илләренең җыеп бар угын?!
...Нәҗесләтә «Рәсәй аракысы»
җитмеш төрле чирнең даруын...

Керләнмәгән чәчәк тузанына
коя мирнең бөтен пычрагын.
...Умартачы чүнник уртасында
ялап тора баллы пычагын...

# Идел төбендәге чишмә

Офтанасың:
«Үзем, диеп,
ай агасын көн агам,
ә шулай да барлыгымны
белүче аз дөньяда...»
Анысы хак:
кушуч сузып,
тезләнмиләр алдыңда;
онытылдың —
болын белән
су астында калдың да.
Ә бит сине борынгыда
атаганнар «изге» дип.
...Билгесезлек хәлендә дә
кылып була игелек!
«Яшәвемне белүче юк,
кемгә кирәк мин хәзер?..»
Барлыгыңны-юклыгыңны
Идел үзе сизәдер...
Куәтеңне Иделгә куш,
дулкыныңны бәр ярга!..
Без дә шулай кушылырбыз
Вакыт атлы дәрьяга.
Шул ук сорау:
аның өчен
әллә — юк без,
әллә — бар?!
Хәер, моны тора-бара
Вакыт үзе чамалар.

## *Искәртү*

Көз — алтын бизгәге...

Шулай ул
кешене ел саен искәртә:
«Үтелгән вакытның кыйммәтен
алтынга күчереп исәплә!..»

Көз — алтын сарае...

Бар анда
хикмәт тә,
акыл да,
исәп тә...
«Син кылган эшеңнең зурлыгын
алтынга күчереп исәплә!..» —

Көз безне ел да бер искәртә...

## *Күзге кичтә*

Чү! Тирәкнең яфраклары
дәррәү очып китте дисәм...
Кошлар икән!
Бер гаилә...

Чү! Тирәктән, дәррәү кубып,
кошлар очып китте дисәм...
Яфрак икән...
Бер гаилә...

## *О я*

Күк җанланган.
Күктә кошлар моңы.
Төннәре ак. Янып тора
Киек Казлар Юлы.

«Оям калды туган илдә,
агач башында — җилдә...»

Күк гөмбәзен сыйпап-сыйпап,
карт тупыллар шаулый.
Ялгыз калмас иде оя,
очып китә алмый.

Канатлары сынган кош күк,
талпынып куя җилдә,—
тирәкләр белән бергә
берегеп үскән җиргә...

Баш өстендә аваз тора,
тирбәлеп тора җилдә:

«...оям калды туган илдә...»

## *Оча алмыйча калу*

Кызгандыра казкайларым,
тәмам чумдым моң-зарга:
мамыкларын йолыккалап,
тутыралар мендәргә.

Йолдызларга омтылгандай,
канат җилпи башлагач,
киек кошлар кәрванына
карый-карый баш талгач...

Оча алмый калган канат
авырайта моң-зарны.
...Каз мамыгы көн дә иртән
тишеп чыга мендәрне...

## *Казлар авазы*

«Канат төртмәгән җирләрем
калды микән күгемдә?!
Җылы канатым астында
Туган ил бар бүгенгә...»
        Күктә тавыш, авазлар...
        Таныдым:
        былтыр озаткан казлар!

«Болытларга кагылыймчы,
зәңгәрлеккә манылыймчы;
сине күрми миңа читен —
нинди микән син, күк чите?..»
        Күктә тавыш, авазлар...
        Таныдым...
        Быелгы
        бала казлар...

# *Соңгы акчарлакны озату*

Канатларың — күккә ашкан
ярсу дулкын теледәй.
Сыйган аңа Иделемнең
давылы да, җиле дә.

Төш, акчарлак, кочагыма,
канатыңны, кил, сыйпыйм.
Кызыл тәлгәш-тәпиеңне
куенымда җылытыйм.

Зәңгәр төшләр күрер Идел:
давыл алда, яз алда.
Бир, акчарлак, каурыеңны
сагынып җыр язарга.

Дулкын сине, үксеп-үксеп,
юксынып елар менә.
Алып киттең Иделемнең
давылын йөрәгеңдә.

## *Юану*

Урамга туллалмадык,
буран да буталмадык.

Өймәдек эскертләр дә,
чык булдык керфекләрдә...

Язларга юл алмадык,
барыбер югалмадык:
«Тәүге кар!..» без хәзер дә —
кешеләр хәтерендә.

## *Ак буран*

Ак аттай уйный буран!
Кар белән тулган бура...
Яшьләр салып керәсе өй —
теләсә нигә юра.

Буранның ак байталы,
чуалган ап-ак ялы.
Кызларны урлап китәр күк,
ак чанасына салып...

Ак бураннар, акбүз атлар
бездәнме качып йөргән?!
Ак өермә безгә үзе
капканы ачып кергән!

Теләсә нигә юра —
авылда ап-ак буран...

## *Алатаудагы кар бөртекләре*

Шундый җиңел, абау,
шундый җиңел —
авырлыгын тоймый керфек тә.
Гаҗәпсенәм: тау-тау гөнаһсызлык
яшәп ята бәллүр бөртектә.

Алатауда карлар Алиһәнең
таңгы сулышыннан яралган.
Төшүендә җир дә төшенмәслек
җиңеллекләр бардыр, йа Аллам!

Тазалаучы галәм тузганагы —
җиңеллекнең соңгы чигедер!
Мамыклары, өф-өф, мамыклары...
сытар, диеп, ничек шик килер?!

...Ишетелә карлар ишелгәне,
балпан*нарның тонык «кар-кар»ы.
Алатауда иңрәп үлгәннәрнең
җиңел булсын авыр карлары,
җиңел булсын
авыр карлары...

---

* Балпан — тау кошы.

* * *

Ыргый ташкын, тышауларын
өзеп чапкан ат сыман.
Давылланып күтәрелә
курпы табан астыннан.

Җылы яфрак чәчрәп чыккан
биләү-биләү бөредән.
Сагышны да яшәртә яз —
йөрәккә кояш кергән!..

## *Бөреләр ачылганда уйлану*

Бу башымда күпме уйлар янган,
очкын чагылдырып күзләрдә.
Кайчак ирек бирмәгәнмен икән
канат сорап торган сүзгә дә.

Аңлаталмам, әйтә белмәм, диеп,
ничаклы уй тоттым эчемдә!..

...Үз-үземне гаеплегә саныйм
ачылмаган бөре өчен дә.

## Аклык

Шомыртларның чәчәк аткан чагы —
булса булыр икән салкынлык!
Әллә инде язның учагында
җирне җылытырлык ялкын юк...

Кар шикелле сарган бу аклыкта
котып суыклары бар мәллә?!

Туй күлмәгең кигәч, син дә шулай
салкынаеп куйдың бер мәлгә.

Битеңне куй —
баксаң, челләдә дә
салкынчарак икән ак кылган.
Без дә, ахры, чәч агарткач кына
ирешербез салкын акылга.

Тик аксакал кызмый сөйләсә дә —
хискә салкын, диеп уйлама.

...Май төненең Аен күшектереп,
шомыртларда салкын ут яна...

## *Тау астындагы чишмә югалгач*

Әллә сине иңдердеме
таудан авыр таш моңы?
...Җир куенына мәңгелеккә
яшергәнсең башыңны...

Бәлки, сине без, кешеләр,
куркыткандыр, нарасый?!
Кайчан үз ярабыз итеп
тоярбыз Җир ярасын?..

## Меңьяфрак

Яфраклары меңгә тулып җитми,
һәр санаган саен ким чыга.
Кем кагыла
                        Кеше исәнлеген
саклашучы яшел илчегә?

Бәхет юраучылар өзгәлиме,
заман тәгәрмәче изәме?
Кемнәрнедер тилерткәнме әллә
ак мәтрүшкәнең ис-тәме?

Кабат торалмассың —
аягыңа
бер уралып җиргә егар да...

«Кыз чакта,— ди әби,—
                                        сан җитмәгән
шул чукларын санап чыгарга...»

Күз алдымда гербарийга бала
бер яфрагын өзеп алгач та,
күңелемнән нидер җуям сыман,
көн кими күк гомер-агачта.

«Соңгы яфрак!
Дөнья кыл өстендә!!» —

Төшкә керә шулай ярмабаш*...
Өндә булмаса да, тетрәндерә,
мең уй уеп ала,
ярыла баш!..

Саныйм, саныйм —
меңгә тулып җитми,
алда күпме гомер кичәсе!..

Ә бездән соң шушы яфракларның
кимеп калыр тагын ничәсе?

---

* Меңьяфрак үләнен ак мәтрүшкә яки ярмабаш дип тә атыйлар.

## *Нишләрбез?..*

Йөткерсәң дә — үлән бар,
хәл бетсә дә — үлән бар,
тәм китсә дә — үлән бар...

Җирдә тагын туксан тугыз
авыруга үлән бар!

Ә беркөнне үзләре дә
чирләп ауса үләннәр —

нишләрбез?

## *Эт җиләге. Ат кузгалагы...*

Шул җиләкне өзгән көнне
этләр керә төшемә.
Бер кузгалак күреп алсам,
атны искә төшерәм.

Нигә шулай!
Җанга иңә
әллә нинди авыр моң...
Җирдә безне хәтерләтер
берәр үлән калырмы?

## *Илен сагынучы дөя*

Көрсенмичә, кимсенмичә,
ничек итеп тор монда?
Кешеләре кабатлыйдыр
уйлап минем турыда:
«Дөя дә бүләк,
төймә дә...»

Күрүләре җитмәгәнме
мине энә күзеннән?!
Тиңләшмәсне тигезлиләр
тузга язмас сүз белән:
«Дөя дә,— дип, —
төймә дә...»

Әллә хурлау, әллә зурлау —
үзем анык белмим дә.
Мондый сүзләр яши микән
минем туган илемдә (?!):

«Дөя дә бүләк,
төймә дә...»

## *Балык кычкыруы*

Яр комыннан алтын юар дулкын
үрә-сүтә иде ат ялын!..
Хәзер инде төшкә генә керер
суның чәчәк аткан чаклары...

Бер әкият итеп сөйли халык
шушы суда мәрҗән булганын!..
Бар, кайтарып кара хәзер аның
борынгыда калган шул данын.

...Чү!
Җан өзгеч тавыш ишетелде
үлеп барган кара таллыкта.
Хәтәр чакта,
нәгъръә орган кебек,
бер кычкырып куя балык та!..

# Ат ату

*Фәниягә*

Улларыңны үсендереп,
әйдә, татар, әйтә тор:
«Ир-егетнең эчендә,— дип, —
иярләнгән ат ятыр».

Кайчак гамьсез күзләреңә
читтән карап ал, татар!
Үзәгеңне эзләгәндәй,
кемдер төби алтатар...

## *Чалымлау*

Әллә инде катьле нәфеслек*не
дәвам итә торган затмы без?
Агулыйбыз барсын ашыкмыйча —
салаватлар укып ятмыйбыз.

Кизәнгәндә тургай җитене**нә,
агулыйбыз үзен тургайның.
Кешеләрне чынлап көнләштерер
даһилыгы, димәк, зур анын.

Агротехник агай агулыйдыр
хәтта чаяннарның үзләрен...
Белмибезме дәшмәс балыкларның
бугазында ләгънәт сүз барын?!

Агулыйбыз шулай акыртынлап
дөнья йортын тоткан ананы!..
Чалымладым катьле нәфеслекне —
биләп алган безнең аң-җанны.

---

* Катьле нәфес — үзеңне-үзең үтерү.
** Тургай җитене — агулы чүп үләне.

## *Тары чәчәге*

...Аучы төштә төлке күрә,
төлке төштә тавык күрә,
тавык төштә тары күрә,
тары төштә нәрсә күрсен —
Үги кызлы Айга ашып,
чәчәк аткан чагын күрә...

## *Табигатькә бер үпкә*

Үзе булып калыр һәрнәрсәгә
сайлап бирәсең син үз төсен.
Күзем — шаһит:
быел бер сыерчык
нигә аксыл булып үстең соң?!

Үлем-күздән яшерә алырсыңмы
шул канатлы, тере яраңны?

Син дә кайчак ялгышасың бугай,
ак, дип әйткән сыман караны...

## *Ромашкино ромашкасы*

Ромашкино ягы ромашкасын
юрар өчен өзеп алды да
дегетләнә төшкән таҗларына
карап әйтте: «Шундый фал монда...»

Сөендерсен, җөпләп теләкләрен,
сөендерә күрсен яшьләрне!

...Ромашкалар җилдә тирбәлмәсә,
Җиребездә сөю яшәрме?..

## *Кайтавазсыз урманда*

Кабатлыйбыз уйламыйча:
«Урман булмый киексез...»
Киексезгә әйләнмиме —
карагызчы килеп сез.

— Ур-ман бул-мый ки-ек-сез!..

Урман җавап бирә иде,
берне түгел — йөз, меңне...
Хәзер инде кайтавазы
җөпләмәстер сүземне.

Шүрәлеле урманнарда
бүген киек аз нигә?

Мәкальләрне үтерәбез —
менә шундый фаҗига...

## *Ятим Су анасы*

Күпме күлләр, кибеп-корып,
болытларга сый булган.
Сусыз калган Су анасы
кая барып сыенган?

Күлнең ләмле чокырында
мыжгып тора корт кына.
Су анасы китеп барган,
ахры, картлар йортына...

## *Җиләк бердән җыела*

Кемнәр болын ашъяулыгын
төйнәп алыр җай белә?
Җиләк бердән җыела шул,
җиләк бердән җыела.

Тырышсам да тырысымның
төбе һаман күмелми.
Яхшы әйбер күп булмый шул,
яхшы әйбер күп булмый.

Матурлыкны шулай бердән
туплагандыр мир кулы.
Ә мыскаллап җыелганны
җуеп була берьюлы,
җуеп була берьюлы...

## ...белән...

Җиләкләр белән җелекләр кибә,
колыннар белән оланнар кими,
күлләр белән күңелләр саега,
имәннәр белән иләмәннәр ава,
чишмәләр белән фәрештәләр кача,
тургайлар белән
Тукайлар килүе сирәгәя...

## *Җир җимертеп яшәү*

Дөнья йортын азлап-күпләп
ничә буын җимерттек!
Күңел кошы кардәшләрен
җиргә күпме җим иттек.

(Кысылганнан кычкыручы
Шүрәлене кем яклар?)
Кисеп оҗмах агачларын,
бастык Кызыл китаплар.

Һәм салават күпереннән
агулыйбыз... зиратны.
Халык түккән кан-яшь үчен
кайтарырга Җир хаклы!

Шапырынмыйк, шагыйрькәем —
чыктан куркыр чак җиткән.
Мескен кошлар оя кора
үреп тимерчыбыктан.

Язып кына файда килмәс,
язган чакта җир-көннән.
Ниргәләрне суырабыз
фани дөнья йортыннан.

Яэҗүҗ-мәэҗүҗ безнең кулдан
тора һаман җим көтеп.

— Хәлләр ничек, җирдәш туган?
— Яшәп яту җимертеп!..
Әлегә...

## *Ярымшарлар*

Ибне Сина варислары
аңлатадыр: «Бел, кеше!
Сөенергә әмер бирә
миеңнең сул өлеше...»

Менә кайчан, елмаешып,
дөнья ал да гөл, дибез.
Ә уң ягы белән, димәк,
көенәбез, елыйбыз.

Кешелекнең табиблары
шул хакта да уйлыйдыр:
кайсы ярымшары белән
елмая һәм елый Җир?..



# IV БҮЛЕК



## *Иртәләү*

Шашкын иде тамчысы да —
тамды мартка җитәрәк.
Сөю безнең йөрәкләргә
керде бугай иртәрәк.

Иртәләде ләйсәне дә,
узды яшен иртәрәк.
Мәхәббәттән яра алдык
унсигезгә җитәрәк...

Болай да иртә язларга
кердек бугай иртәрәк.

* * *

Карабодай басулары —
ак болыт.
Болан аунаган җир ята
тап булып.

Ак күлмәкле кыздай уйный
пакь җиле;
кочагымнан чыгып кача —
аһ, тиле!..

Ак кырларның аклыкларын
күз ала.
Кинәнгәнче йөгереп кал,
кыз бала!..

# *Август төне*

Йолдыз — кояшка охшаган
күк җисеме.

*Укытучы сөйләгәннәрдән*

Каеннарга йолдыз куна,
тула кошлар оясы!
Теләкләргә күк «Амин», ди,
Җиргә биреп кояшын.

Кояшын да кызганмыйча,
күк «Амин», ди буй кызга.
Ә кызыкай учын суза
койрыклы йолдызга.

Кояш биреп, күк «Амин», ди,
һәм нур бөрки каенга.
Бүген Ае китек икән —
бирер иде Аен да...

## *Кич. Дәрья*

(Рәсем)

Агып барган ак яулык күк
дулкындагы ярты Ай.
Яр буенда — сынган ишкәк —
җирдә яткан балыктай...

Шомлы дулкын йолдызларны
комга кагып чыгара.
Бәен өзгән хөр көймәгә
аваз салдым:
«Чы-ык ярга!..»

Текәлгәнмен:
әллә сулар,
әллә комлы яр ага?!

Ак күлмәкле бер кызыкай
керәп бара дәрьяга...

## *Төнге диңгез ярында*

Сынык ишкәк, балык күзе...
Ярга чыкмый ни генә?!
Шушы дәрвиш дулкыннардан
нидер көтәм мин менә.

Һәм кайвакыт, өлешем, дип,
кабул итәм югын да.
...Чекерәеп йолдыз яна
буш кабырчык суында...

## *Тынычлану*

Вакыт —чиксез.
Тик ул алдыбызга
үз чикләрен куя һаман да.
«Бүген ир бул!» — диеп,
егетлектән
дәшеп ала безне замана.

Беркатлылык, мутлык, дуамаллык
җитми кала бугай яшь җанга.
...Аллаһ, бәлки, күбрәк еллар бирер
акыллырак булып яшәргә.

## *Ерак сәяхәткә чыгу*

Җиде диңгез кичеп кайткан чакта
авырая, диләр, энә дә.
Ышаныч — бар,
көч җитәрлек бугай,
тагын ниләр алыйм көймәгә?

Артык йөкне ташлап калдыр, диеп,
бер әйттерер, бәлки, юл-газап.
Гамьнәремне үзем белән алам,
барысыннан авыр булса да...

# *Йөгән күзлеге*

(Юрамалый җаваплау)

...Имештер, мин як-ягыма
баш боргалап барам ди.
Ә күз каплагычлы атлар
уңга-сулга каранмый...

Һич сүзем юк, бер ноктага
җыю кирәк күз нурын.
Тик мин болай күрми калам
көндәшләрнең узуын.

* * *

Бәйләнчек җил төсле,
җил сыйпый җилкәмнән:
«Мин синең күренмәс
канатың, бел, бәндәм...»

Шулай да аркан җил
юлдашы түгел мин.
Сөрелмим җилкәндәй,
дәрья күк түгелмим.

Кылгандай йөгермим,
җилләргә сарылып.
Тегермән шикелле
җил көтмим зар булып...

Ә бәлки, миңа да
әйтерләр, кем белә:
«Бу якка юлыктың
син нинди җил белән?..»

## *Илаһи күк дәфтәре*

...Алда — кәгазь,
кулда — каләм,
җитеп бетми дәрт бары.
Айлы битен ачып куйды
илаһи күк дәфтәре.

Сүрә итеп ятлар шигырь
чыкты, имеш — афәрин!..
Яшен сызып үтте шулчак
илаһи күк дәфтәрен.

Язган чакта җаным аша
үтә, чү, кем әфкаре*?
...Бүген шундый якын иде
илаһи күк дәфтәре...

---

* Уй-фикер мәгънәсендә.

# *Суга салынган уйлар*

Уйларымны суга салам —
калыкмасмы җыр булып.
Бөркет оясына менә
ярсу дулкын ыргылып.

Уйларымны суга салам —
таш ярларны су кисә.
Тамырлыдыр мәрмәр кыя,
авар иде югыйсә...

Безнең уй-гамь кузгатамы
дәрьяларның сил-җырын?!
...Дулкын чәйнәп өзәр кебек
каегымның чылбырын...

## *«Хәзергә...»*

«Хәзергә...» —
дип, кул бирәбез
кич күрешер ярга да.
Җир читенә олагабыз,
биштәр асып аркага:
«Хәзергә...»

«Хәзергә...» —
дип, кулын изи
йөз яшәгән картлар да.
Бүтән мәңге күрешалмас
дуслар кала чатларда:
«Хәзергә...»

«Хәзергә...» —
дип, саубуллашып,
күмеләбез елларга.
Җирдә кабат күрешмәсәк,
очрашырбыз җырларда...

— Хә-зер-гә!..

## *Кояш чыгышы*

Саумы, янар таулар иле,
саумы, кояш чыгышы!
Юктыр бүтән — мондагыдай
төшкә кергән чык исе.

Ярым белән китәргә дип
вәгъдәләшкән җир чите...
Синдер хәтер китабымның
иң кызыклы бер бите.

Җир ачылып бетмәс кебек,
җирдә мәңге яшәп тә.
Исемеңне куштым, әнкәй,
миңа ят бер чәчәккә.

Монда хыял кошларымның
кунаклаган кыясы.
...Күрдем Татар бугазыннан
күтәрелгән кояшны...

* * *

Өз, гитара! Өз үзәкне!
Җанны кыйсын кыл-камчың.
Бирче, уйныйм, чегән кызы,
ирләрне елатканчы.

Шагыйрь кебек өзелә кыл...
Җыр өзелеп карасын!
Бирче миңа, чегән кызы,
Лорканың гитарасын!..

## *Әйтешү*

(Трамвайда егет кызны ирештерә)

— Әллә соң син минем өчен
тамгаланган елакмы?
— Суык бабай элегерәк
тешләп куйган колакны...

— Минме мәнсез? Кызга урын
бирәм хәтта... ләүкәдә...
— ...Балдакларга теләвеңне
кабул итмәс чәүкә дә.

— Әйтче? Кайда торганлыгын
яшермидер качкын да.
— Мыегыңа чорна, егет:
яшим... күпер астында...

Салават
күпере
астында...

## *Чигү*

Тулы Айдай киергегә
сыймагандыр ни генә!
Ихлас әйтәм: уйларымның
чыга алмыйм чигенә.

Чын табышмак!..
Чигелешен
юрап карыйм төрлегә, —
ташлардагы бик борынгы
язу күк, ул серле дә.

Хикмәтле дә — Фест дисбесе
сурәтләре шикелле.
Аңламассың, нидер сөйли
йөз төсмерле җеп теле...

Чигүдәге сер-төеннең
яшерен җебен бер тотсам,
мин бу кызның вөҗүден дә
ачармын күк берочтан.

* * *

Бик дуамал тай да тора-бара
басыларак төшә түгелме?!
Чү, Яз кызы!
Минем белән кал, дип,
ымсындырма әле күңелне.

Хисем тыеп, салкын акыл белән
яшәп карыйм бермәл —
ялгызым.
Аллы-гөлле кулмәк итәгенә
утыртмачы мине, Яз кызы!..

# Үксезлек

Җәйге урман аланында
нигә мине очраттың?
Нигә мине әкияти
Үги кызга охшаттың?..

...Нигә үзен ялгыз итеп
тоя һаман бу башым?
Миңа тиеш мәхәббәттә
килми үксез буласым...

## Сер

*Р.-гә*

Серне ташка язалармы,
серне җилгә кем чәчә?!
Кар өстенә язып куйдым
исемнәрне янәшә.

Серне ташка язалармы,
серләрен кем җилгәрә?!
Исемеңне ташкындагы
бозга язып җибәрәм.

Күңел түрендәге серен
ташка язар кем генә?!
«Яратам!» дип язып куйдым
Сөннең сары комына.

Гел сер килеш калырсыңмы —
син сер әле хәзергә.
Ә барыбер исемеңне
уеп яздым бәгырьгә.

## *Күзләреңә карап уйланганда*

Яшь йотса да, уй корса да,
эчендәге — тышында.
Эчтә тота алмый кеше
яхшы-яман төшен дә.

Рия,
мәкер,
юхалык та
күренә күз-көзгедә.
Үзен-үзе яшералмый
туксан тугыз йөзле дә.

Яшь йотса да, уй корса да,
күңелендәге — күзендә.
Мин генәме күзләреңдә? —
күренәсең үзең дә.

## *Үземә дә кадерле*

«Уеңны гел эчтә тотма,
сөйлә,— диләр,— ышанып...»
Бу сагышны күңел теле —
булмый аннан бушанып.

«Сүзен алып булмый,— диләр, —
моңлы җан шулкадәрле...»
Ничек бүлим ул сагышны —
үземә дә кадерле...

* * *

Күзләреңнең тирәнлеген
тик мин генә беләм.
Чәчләреңдә — бөтнек исе —
тик мин генә беләм.
Күкрәгеңдә миң барлыгын
тик мин генә беләм.
Иреннәрең тәме нинди —
тик мин генә беләм...

Сине әнкәң дә белмидер,
тик мин генә беләм!

## *Сердәшлек*

Талыбыз яфракта утыра —
бөреләр ямь-яшел ут алган!
Ә берсе һаман да ачылмый —
әйтерсең көннәрне бутаган.

Йокысы тирәнме? Ни өчен?..
Сәбәбен чамалап беләм мин:
ул бергә бүлешкән серләрне
дөньяга ачарга теләми...

## *Берлекне тою мизгеле*

Комлыкларны бизәп кызынучы
күпме кызга күзем аткан бар.
Икәвенә бүген мөкиббәнмен —
билдән суга кереп ятканнар!

Кыбырсынып диңгез кочагында
ятуларын ничек күрмә ди.
Өсләренә серле пышылдашкан
дулкын чиратлары үрмәли.

Табигатьнең чып-чын иркәләрен
күрдем шушы кызлар йөзендә.
Тәнкәйләре назга тиенгәндер,
рәхәтләнде бугай диңгез дә.

## *Диңгез буендагы кыз*

Кочагыңа тартып алмак булып,
давылланган чагың исемдә...
Тезләремне кочып үптең бүген —
үзгәрәсең бер көн эчендә.

Аягыма егыласың, диңгез,
мин бит бары зәңгәр хыялчы.
Синең давылыңны шашып сөйгән
акчарлактан бераз оялчы!..

## *Соңлаган фәрештә*

«Кыз куу»да куып тоткан
минем балдаклы кошым,
болыт менмәс биеклеккә
кабатланмас очышым.

Соңлап кына иңнәремне
килеп кочкан фәрештәм.
Кымыз тулы касәбезгә
йолдызлы күк, Ай төшкән.

Шарлавыктай агып тора
синең кырык толымың.
Икебезгә карап калды
мәрмәр сыннар, борылып...

Үрелеп, Тянь-Шань түбәсенең
алып бирдем ак карын.
Аһ, салават күперенә
кадәр менгән чакларым!

## *«Кыз куу»*

(Урта Азия хатирәсе)

*Алиягә*

«Бу — җебегән егет икән,
аты атмы? Ишәктер...»
Менә шулай уйлый-уйлый,
әйдә, мине кисәт бер.

Кисәтәсең... Мин бит синнән
баш тартырга теләмим.
Арага ят кералмасын
яхшы сизеп киләм мин!..

Хиссиятем шикелле үк,
атым бераз тыюлы.
«Нигә?» дисәң, сине юри
тотмыйм әле бу юлы.

Үзем сиңа томырылам,
үзем тартам тезгенне.
Әллә нигә озайтасым
килә шушы мизгелне...

## *Төнлә су кергәндә*

Саргылт чәчең суүсемдәй яна,
күкрәкләрең суда тирбәлә.
Син... оялчан тәнгә тәүге баккан
мин бердәнбер, бәлки, ир бала?!

Гүзәллегең күреп бетералмам
шушы җирдә хәтта мең яшәп.
Сине күрергә дип күзен ачкан
төнбоеклардан да көнләшәм...

## *Үзебез булып калыйк*

Е г е т .
Юлымда очрарга
тиешле язмы син?
Синнәнме башларга
мәхәббәт язмышын?
Җантаһир булып
килеп чыкмам
барыр юлыңа.
Шулай ук син дә
Зөһрә түгел,
үзең бул миңа.

К ы з .
Игездәй янәшә
баруын барырбыз...
Чынлыкта җандашлар
булырлык пармы без?
Җанзөһрә булып
килеп чыкмам
барыр юлыңа.
Шулай ук син дә
Таһир түгел,
үзең бул миңа.

Б е р г ә .
Йөрәкләр юлының
газабын күп татыйк.
Сөюнең өр-яңа
үрнәген күрсәтик!

Е г е т .
Җантаһир булып,

К ы з .
Җанзөһрә булып

Б е р г ә .
Килеп чыкмам
барыр юлыңа.
Шулай ук син дә

Е г е т .
Зөһрә түгел,

К ы з .
Таһир түгел,

Б е р г ә .
Үзең бул миңа,
үзең бул миңа.

* * *

Болын көтә сине,
әнкәемдәй,
мендәр салып табан астыңа.
Монда үз булырсың:
төп йортыма
бәхет теләп аяк бас кына.

Онытылып, әйдә, адашыйк бер —
эзләп табар әле замана.
Күк-чыбылдык бүген безнең өчен —
гөмбәзендә күпме шәм яна!

Юрыйк әле,
йомык төнбоеклар
безгә әйтеләчәк сүздер, дип.

...Бу бәхетле төннең соң йолдызын
таң алдыннан өреп сүндердек...

## *Табышу*

Учак-учак йолдызлары,
кочак-кочак кызлары...
Минем куенга кергәне
син — бердәнбер кыз бары.

Кычкырасым килә күккә:
— Гомерлегем, яктым! — дип, —
Мәхәббәттә ятим чагым,
сау бул, инде таптым!..— дип.

Сөю сукмаклары озын —
барасы да барасы.
Ничек кулга ияләштең,
аһ, син, болан баласы!..

## *Җиңел сөю сорама*

Әйлән-бәйлән уйный кырпак,
Айны алып уртага.
Төшләреңә керә карлар —
керфегеңнән нур тама.

Җиргә аклык иңә күктән,
Ай нурына сарылып.
Сиңа сөю килә, сеңлем,
алкыш-алкыш кар булып.

Пар-пар төшкән ак таҗлардан
җиңел сөю сорама.
...Чү, бәсләнгән керфегеңнән
әллә яшьле нур тама?!

* * *

Кар илендә каеннар да
яктырак яна сыман.
Кер тимәсме җиргә кунган
кыш-аккош канатына?!

Юлыбызга төши буран
күңелгә тулыр төсне!..
Аңа шәүлә төшерсәк тә,
җинаять булыр төсле.

## *Илаһи яшен язуы*

Күккә яшен язып куйсын
исемнәрне янәшә, —
яраштырып ярәшмиләр,
кушылулар — җан аша.

Минем сөннәт каным белән
гыйффәт каның кушылсын, —
яшеннәрнең ялгышуын
ике җан да хуш кылсын...

## *Синең авылыңа кайту*

Үрдән карап, хәйран калдым:
«Синме шушы туфрактан!»
Гаҗәп авыл — алма төшә
тәгәрәшеп дүрт яктан.

Исем китә, күзем белән
урамнарны урыйм да.
Чишмә бәреп чыксын әле
алма төшкән урында!

«Мине әнкәм көтеп тора,
ә-әнә безнең йорт»,— диден.
Үрдә калдым — алма булып,
чишмә булып йөгердең...

## *Килен булып төшкәч*

«...Тартынмыйча бас мендәргә,
авыз ит шушы балдан!..»
Өйгә узгач, пышылдадың:
«Күзем,— дип,— тышта калган...»

Дөньямның иң түренә үк
уздырдым сине алдан.
Нишлим — әйтсәң: «Берни күрмим —
күзем,— дип,— тышта калган...»

## Үтәли караш

Миңа сөзеп карамачы,
бакма шулай инәлеп.
Кыенсынам: күз нурларың
җаныма ук иңә бит.

Барлы-юклы байлыгымның
күрәсеңдер барсын да...
Шыр ялангач калам күк мин
шул күзләрең алдында.

Бакма шулай!..
Бу күңелнең
бар яшерен төше дә;
үзе белән җиргә китәр
сер дә була кешедә...

# *Халәт*

Өзми әйткән чак та була —
тотлыгасың сүзеңдә.
Кайчак башның ни уйлавын
аңламыйсың үзең дә.

Бик үтенәм: мондый хәлдә
миннән тартып сүз алма.
Уй йомгагын дәвам иттер,
фал ач,
юра,
күзалла.

Мәрҗән эзләүчеләр сыман
тирәнгәрәк төш, әйдә.
Гамьле җанны уйландыра
чыктай сүнгән төшләр дә.

Шулай мине яхшырак та
аңларсың күк, кем белә?!

Кайчак йөрәк кушуын да
әйтә алмыйм тел белән.

* * *

Каты күзлесеннән сакланам, дип,
күлмәгеңне юдың туйдан соң...
Хәзер менә ап-ак шомыртыңа
кызыл яулык бәйләп куйгансың.

Күз тимәсен, имеш,
шомыртыңа
һәр язда да шулай ак сарсын.

Ә син үзең күңел пакьлегеңне
яман күздән ничек сакларсың?..

## *Шигърият алиһәсе*

*Розага*

Аның белән ярәшүле идем,
син — Җир кызын эзләп тапканда.
Ачуланма,
өйдән чыгып китсәм,
таң нурлары тәрәз какканда.

Бу дөньяга шагыйранә карап
яши алмам, сине сөймәсәм.
Ә ул төшкә ешрак керә бугай,
аның белән күбрәк сөйләшәм.

Сулышымны кысып, сарыла ул —
күңел кочагыңны җәй генә...
Минем хакта начар уйлама син,
соңлап кайтсам кичке чәеңә.

Бу сөюдән аралармын, димә,
зынҗырлары аның тап-таза!
Юк, көндәшең түгел ул алиһә —
уртабызга кереп ятса да.

Бер тамырдан үскән кушкаен сез,
икегез дә — минем язмышым.
Тик өчәүләп яши алмый торган
шагыйрь хатыннары азмы соң?!

# *Вакыт агышы*

**1**

Ком сәгате...
Тавыш-тынсыз
ага Дәвер тузаны.
Сизелмиме? Бик сизелә
гомереңнең узганы.

Саранланып бирә Вакыт:
булмады бер онтылып —
акты-бетте малай чагым,
кушучтагы ком кебек.

Чүлләр күчә...
Чорлар ага...
— Таныйсызмы?
Без — сездә!..

Бөртекләргә тиң гомеркәй
югалырмы эзсез дә?!

Яшәлгәннең бер өлеше
очты бугай җилгә дә...
«Вакытыңа сыеш!» — диеп,
йөгем баса җилкәгә.

Хәзер менә көннәр җитми,
бишкә бүләм бер төнен.

Вакыт ага...
Баш түбәмә
коела ком бөртеге...

...Өстәлемдә — ком сәгате...

**2**

— ...Төнбоеклар кыш алдыннан җылы якка очып китәләрме?
— Юк, балам... Төнбоеклар, боз-юрган ябынып, зәңгәр төшләр күрә-күрә, кыш буе йоклыйлар...

*Бала чакта әнкәй белән сөйләшүдән*

Битне бозга куям —
пешерә күк
төнбоекның кайнар сулышы!
Әллә өн ул, әллә эчке аваз:
«Бигрәк озын булды бу кышы...»

Үзалдыма сөйләнәмме, дисәм,
бу халәттә әйтер сүзем юк.

«Саплам гомеремнең күпме төнен
үткәргәнмен шулай күз йомып...»

«Ачылырга көннәр җитми иде,
бик кадерле хәзер төне дә...»
Су гөлеме?!
Юк, бу — үз уйларым
чыңлый бугай колак төбендә.

**3**

Сиңа карап, кыш үткәнен белдем —
сипкелләрең тагын калыккан...
Гамьсез димә!
Кайчак йөрәккә яз
керә икән соңга калып та.

Җәй дә, көз дә, никтер, җитми калды,
җитми калды быел кышы да.
Ел вакытларына охшамаган
фасыллар да була кешедә.

Ә кайвакыт аю өнендә дә
яз сәгате төгәл сукмыйдыр...

Йөрәгемне язга иртәрәк тә
алып кергән чаклар күп иде.

Көнгә туймас үз вакытым кайчак
язга чыга соңга калып та.

...Сиңа карап, кар киткәнен белдем —
сипкелләрең тагын калыккан...

## *Кайчак*

Үч-кинәсез күңелеңдә
сөю дә сөелү.
Каян килгән сүз-хәнҗәрсез
ачулана белү?!

Иреннәрең — татлы балан,
күз карашың — учак,
толымнарың елан кебек...

Куркып куям кайчак.

## *Ачы тәҗрибә ачышы*

Еламсырап миңа елышканда,
юаткандай, әйттем көр генә:
«Яшьле күзләр, җаным, яшьле күзләр
күпкә тирән булып күренә».

Пышылдадың артык пошынмыйча:
«Җәрәхәтле йөрәк... җылырак...»

Елаккаем, аһ, шул җылылыкка
ирешергә ничә ел кирәк?!

* * *

Арабызда тау булса да,
күреп торам үзеңне.
Тәрәзәгә текәлгәнсең,
алалмыйча күзеңне.

Үрмә гөлләр үрелеп карый —
елмай, йә, бер дәш инде!
Шатлык җиле кагылса да,
тоталмыйсың яшеңне.

Тәрәзәңә кояш кунган,
ә син һаман борчулы.
Тамчы гөлең, сабый кебек,
елый үзеңә кушылып.

Арабызда тау булса да,
ни булды, әйт яшерми.
Оныт, дип калган идең бит,
нигә юрыйм яшеңне?..

# Сиңа җибәрелмәгән хатлар

## 1

Миңа да бер йолдыз бардыр —
өлешемә тигәне,
күкнең кайсыдыр төшендә:
«Оялчаным!..» — дигәне.

Миңа да бер кыймый гына
ташлар әле карашын.
Мин бәхетле итмәммени
Җирнең бер кыз баласын!

## 2

— Каеннар гел парлап очрый.
Нигә шулай? Әйт әле!
— Пар каен да, кушкаен да —
чын тугрылык һәйкәле...

«Сөюебез сынланышы!
Үссен,— дидек,— куш булып...»
Бүген алар бер булганнар,
җанга иш җан кушылып.

Тамырлары — бер йомгактыр,
тәндә бер үк кан ага.
...Ә без аңа, җитәкләшеп,
килалмадык яңадан...

**3**

Шундый кайнар булып янды
җан өшеткеч шул хат та!..
Баксаң, мине ярам гына
җылыткан бит ул чакта.

Янган гөслә кебек, нидер
чыңлап куйды учакта.
...Җаныбызны бәйләүче кыл
өзелгән нәкъ шул чакта...

**4**

Йолдызыма табынучы
мин генә түгел икән.
Мин генәме син сылуны
үз фәрештәсе иткән?..

Сынына сәҗдә кылучы
Җирдә бар икән тагын.
Тик шулай да сагындыра
сиңа табынган чагым.

**5**

Йөрәгеңә, бәлки, җылы керер —
хатларымны яндыр учакта.
Тәү шигырьнең утка ягылуын
белми идем әле ул чакта.

Сүзләремне еллар саргайтмасын —
мәхәббәтнең яндыр бүз чорын.
Вөҗданына каршы килгән чакта,
утка сала шагыйрь үз җырын.

**6**

Синең яшьлегеңә дәшәм:
«Басып торчы таш сындай,
ак тасмалы кызый булып,
мәңге минем каршымда!..»

Син кемнеке булдың хәзер,
син кемнең кочагында?
Ак тасмалы кызый булып
калчы малай чагымда!..

**7**

Рәхмәт яусын:
син кайчандыр
атладың янәшәмдә.
Мин бәхетле, үткәнемне
сагынып яшәсәм дә.

Шул көннәргә табынырмын
гомернең алгысында.
Рәхмәт сиңа, кемнәрнеңдер
юк әле анысы да.

## *Каен арасыннан эзлим*

Каен арасыннан тапкан идем
син оялчан каен җиләген.
Белмим:
нигә минем өчен генә
шулай ачылырга теләдең?!

Кайсы яшел язда калды икән
болын кочагында кунган чак?
Икәүләшеп күлмәк итәгеңне
чык бөртекләрендә юган чак...

Кайсы язда калды —
синең белән
чыклар коеп йөргән бер төнем...
Эзлим, каен арасыннан эзлим
шул кояшлы энҗе бөртеген.

# *Сихерләнү*

Beләсеңдер Нократ болынының
хәтерендә шундый җәй барын:
җәннәт сые итеп эчкән идек
җанга тансык үлән чәйләрен.

Төклетура безнең төнәтмәне
киткән иде таңда әфсенләп...
Сөйләшкәнсең үлән телләрендә —
аңлаганмын шуны, аһ, соңлап!

Сине туган иткән сихри дәрья
минем өчен йөзеп чыкмалы.
Учактагы кара чиләкләргә
ява иде төнлә чык балы.

Онытылдык антлар әйтешмичә,
көнләшкәндер күктән Ай кызы.
...Йолдыз кебек сүнде безнең учак,
төнәтмәләр инде айныды...

Сөю катыш сихер генә үтми —
әфсен кайтарырдай җай бармы?
Үзем һаман дисбе тартып саныйм
синсез үтеп киткән җәйләрне.

## *Җиләк кагы*

Җырның моңы гына калды:
«Җиләк җыям, как коям...»
Әллә сөю рухы өчен
агып китте такыяң?!

Адаштырып калдырмакчы
идем сине йөрәктә...
...Бергә койган җиләк кагы
ачы булды бигрәк тә.

# *Нәрсә булды безгә?*

Егет. Сөю язы безне таный микән? —
көнләп, айлап, еллап үзгәрдек.
Җанга җылы өстәп торыр өчен
телдә инде назлы сүзләр юк.

Кыз. Ләйлә-Мәҗнүн, Таһир-Зөһрә
һаман сорый мәрхәмәт.
Әллә бездән шулар үчен
ала микән мәхәббәт?!

Егет. Гыйшык утын изге иткән затның
улы-кызы түгел... Кайдан без?
Сөю язы безне таный микән —
серсез, сөмсез, гамьсез калганбыз.

Кыз. Ләйлә-Мәҗнүн, Таһир-Зөһрә
һаман сорый мәрхәмәт.
Әллә бездән шулар үчен
ала микән мәхәббәт?!

Егет. Сөю язы безне таный микән —
әллә нинди чит-ят парлар без.

Кыз. Хыял итеп күргән ярлар рухын
гомер буе җаннан барларбыз.

Бергә. Ләйлә-Мәҗнүн, Таһир-Зөһрә
һаман сорый мәрхәмәт.
Әллә бездән шулар үчен
ала микән мәхәббәт?!

## *Иртә килгән кыш, яки аккош күләгәсе*

Бу пакьлектә күләгәсен
күрер иде аккош та.
Күзләремне йомып куйдым
көтелмәгән балкыштан.

Ак каеннар көзгә кире
кайтырлар күк — дәш кенә!
Чал шикелле, көтмәгәндә
кунды бу кар чәчемә.

# Хәтер

Суга салдым,
җиргә күмдем,
утка бирдем,
җилгә чәчтем —
калдырмадым көлен дә...
Сине хәтерләтеп торыр
ни бар тагын күңелдә?!

...Соң аңладым:
аң-хәтердә
үтеп булмас чик барын.

Инде сине төшләремнән
ничек куып чыгарыйм?!

## *Энә*

(Бер хаттан юллар)

Шул Яңа ел кичен онытырга
теләп инде ничә көн яшим, —
идән юган саен әллә кайдан
килеп чыга чыршы энәсе...

## *Сөюнең ачы хакыйкате*

Ватылган сөю ярчыгы
йөрәккә кереп поскан...
Җил белән очмый икән шул
беренче үпкән-кочкан.

Бәхиллек сорый йөрәгем
сөйдергеч биргән коштан...
Җил белән очмый икән шул
беренче үпкән-кочкан.

Йөрәктә рәхәт авырту —
сугыша гүя өч кан.
Җил белән очмый икән шул
беренче үпкән-кочкан.

## *Эзәрлекләнү*

Кырга чыгып йөрдем көзге таңда,
чыклы камылларга кагылдым.
...Гөнаһсызга сине елатканмын —
теге чакта, беләм, хак булдың.

Сиңа иңми калган хәләл җанның
газабына ничек түзәсе?
Тамырларым буйлап күтәрелә
камылларга тулган күз яше...

## *Иртә кар яугач*

Әллә нинди сәер фасыл —
үзәкләрне өзешле.
Җир моңая,
туй күлмәген
яшьли кигән кыз төсле...

## *Үлән арасындагы таш*

Чалгы йөзе ташка тиеп китте
онытылып печән чапканда.
Йөрәк шулай тетрәп куя микән
сиздермичә елан чакканда?!
    Төшне өннән бүлеп торган бәллүр
    чалтыр итеп төпкә коелды.
    Чалгы йөзе ташка тиеп киткәч,
    әллә нинди сәер көй туды.
Ерак кышта калган аулак өйнең
тәрәзенә кемдер таш орды.
Чалгы көен бозган тавыш мине
хәтер хөкеменә тапшырды.
    Саксыз ымым өчен чая кызый
    чалтыратып сукты яңакка.
    Чалгы йөзе ташка килеп тигәч,
    чаткы чәчрәп китте як-якка.
Челпәрәмә килгән чәркәдәнме
ишетелеп алды моңлы чың?!
Алда кинәт яшен чартлап куйды —
һич тә көтми идем монысын.
    Чыңгылдады хәтер чоңгылында,
    чылтырт итте тагын әллә ни...
    «Төшләр»емә зиһен төшенәдер,
    кальбем генә менә аңламый.
Юаларны өзеп юанганда,
изми иде башны бер гамь дә.
Чалгы йөзе ташка тиеп китте
чыклы җирне ялмап барганда...

## *Беренче...*

Тәлгәшләнеп төшә беренче кар,
җир өстендә яфрак җылысы.
Кайчакларда, җиткү кызлар кебек,
бер сәбәпсез килә елыйсы.

Күк гөмбәзе тагын шау чәчәктә,
дөнья якты — шат бер көлүдәй.
Кар шикелле янды безнең сөю,
ачылмаган иде теле дә.

Беренче яр...

Яланнарда яна беренче кар...

## *Яшерен сагыну*

Асылда без һаман сагынабыз
мәхәббәтнең сабый мизгелен.
Ул алиһә булып җанда калган,
җәрәхәте аның изгедер.

...Җанашымнан синең йөзне эзлим,
чәчләреннән — синең исеңне...
Хәләлләрдән яшереп, кызыбызга
без кушабыз синең исемне.

## *Әй...*

Әй, мәхәббәт хиссиятем,
бер михнәт син, бер рәхәт.
Хәятемне яшәтерлек,
яшәртерлек хәрәкәт.

Әй, мәхәббәт хиссиятем,
бер михнәт син, бер рәхәт.
Мине читләп үтмәгәнсең,
рәхмәт сиңа, мең рәхмәт.

Әй, мәхәббәт хиссиятем,
бер михнәт син, бер рәхәт.
Әй, мәхәббәт хиссиятем!
Йөрәк тулы җәрәхәт...

## *Күктә очрашу*

Сөяркәдәй булдың сөялергә,
булдың бугай хәтта хатын да.
...Язмышыбыз тагын очраштырды
кичке күкнең аулак катында.
«Ярәштерде» еллар: янәшәңә
туры килде минем утыргыч (!)
Варшавага очып барышыбыз,
истәлекләр сөйләп үтте кич.
Фәрештәләр очкыч дирбиясен
сиздермичә бәйләп куйганнар.
«Биләүләнгән килеш... болытларда
кайчан әле,— димен,— кунган бар?!»
Яшьлектәге хәтер йомгагының
күпме җебен бергә урадык.
Хәзер сүзне сүзгә ялгап булмый,
кушылырдай уртак җыр да юк...
Самолетта безне сыйладылар,
шәраб эчтек туар таң өчен;
каушаттымы Аллаһ якынлыгы —
түшкә тамды өч-дүрт тамчысы.
«Күлмәгеңдә табы калмагае,
табыйк,— дидең,— тизрәк әмәлен».
Йөрәктәге иске җәрәхәткә
син тоз сиптең, үксез хәләлем!..
Варшавага очып барышыбыз,
истәлекләр сөйләп үтте кич.
Фәрештәкәй чиште биләүләрне —
әллә хөрлек, әллә үкенеч...

## *Бер туйда килгән уй*

Ак шомыртлар көнли синнән:
«Гомерлеккә кисәңче ак...»
Тик дөньяда туй күлмәген
киюче бар ничәнче кат?!

Тол калалмас йөрәгеңнең
ничә тапкыр кабынуы?
Бу җыр,
шәраб,
ак теләкләр —
әллә туең, әллә уен?

«Ачы!» — диеп алкышлыйлар
син — ничә туй карлыгачын.
Качып елаганда тамган
күз яшьләрең ачы, ачы...

Туй күлмәген ничәнче кат
киюче бар «кыз яше»ндә?!
Тик язмасын аны юу
гомер буе күз яшендә.

## *Җиләк*

*Л.турында уйлап*

Яшәмим җил адашырлык
карурман ешлыгында, —
тик күрмиләр,
күңелләрен
тартмыймы яшьлегем дә?!

Берчак кемдер үткән иде:
«Әле,— дип,— яшелрәк...»
...Әллә инде барлыгымны
белгертеп дәшү кирәк?!

Тирә-юньдә йөрсәләр дә,
юк миңа тукталучы,
сокланулы күзләреннән
эретер ут салучы...

Кайчак, ахры, Җир баласын
куркыта гүзәллек тә:
кайтышраакка — күзе төшә,
күз атмый күзләрлеккә.

Язмагандыр инде берәр
иренгә куш булырга
һәм үземә тиң йөрәкнең
канына кушылырга...

## *Яшәүнең бер хикмәте*

(Хикәят)

Чулман яры. Бер кыз аулактарак
салып тора кысан күлмәген.
Күтәрелә алмый бәргәләнгән
аккош итеп күрдем шул мәлен...

Дирбиясен җил дә салдырыша,
аяк буйлап төшә — тач тышау!
Еллар аша карыйм: үзебезнең
Алабуга кызы На-дю-ша*!..

Егерме өч тулган көнне, әнә,
толымнарын кисеп ыргыта;
атлы казак булып киенә дә
ирексезләп үзен... ир итә.

Һәм кушылып китә Сарапулдан
яуга сәфәр тоткан чиругә...
Ир-атларга камыт кидерерлек
кызга менә шундый чир йога.

Ирдәүкәлек өчен үртәлүле
җанын телгәләүче уй-гамьнән
йөрәгендә әллә атай каны
галибанә ярсып уянган?!

Күлмәгенә сыймас гыйсъянчыны
миргә алып чыккан хөр уе.
Куркынычтыр язган тәкъдиреңә
күкрәк белән каршы торуы.

---

* *Дурова Н. А. (1783 — 1866)* — Россиядә хатын-кызлардан беренче офицер, язучы.

Кызыкайны ияр ястыгына
Дөнья абзый каты утырткан!
Канкайларын түгеп егетләрчә,
эчкә никадәрле ут йоткан.

Язмышбикә сөйми
итәгенә
зәгыйфь затның зәһәр басуын...
Нинди хикмәт чыга кызлар кулы
кысып сыккан чакта таш суын?

Гомеренең алтмыш әйләнәсе
ирләр өммәтендә узылган.
Ялгызлыкта ниләр кичергәнен
сөйләп бирә алмас сүз белән.

Картлык баскач, хәлсез калгач кына
асылына кайтып егылган.
Хатынлыгын тәмам оныткандa
егетлеге, ахры, юк булган.

...Чулман яры. Буйга җиткән кызый
күлмәк салып тора аулакта...
Әллә, сеңлем, синең эчеңдә дә
иярләнгән ярсу ат ята?!

Теләгәнең гыйффәт туташлыкны
күздән яшерми дә бирелер.
Төшенсәңче бөек хакыйкатькә:
татлы (татлы!) дошман ир булыр.

Иңнәреңдә күтәр яшәешнең
өлешеңә тигән шул гамен.
...Чулман яры. Бер кыз аулактарак
салып тора кысан күлмәген...

# Сатыш кызы Инҗилә

Төшләремне искә төшергәлим:
күрше йортка ак бәз, җеп керттем...
Уйламаган чакта Айбулатның
җирләп куйдык хәләл җефетен.

Хәтерлимен тере хәсрәтләрне —
игез бала калды биләүдә.
Иртәгесен ятим эргәдәшкә
сөтсез кермәгәндер берәү дә.

Нурсызланып калды нарасыйлар —
җанга ятып бетми ят кадер.
...Каенсарда ана күкрәгенең
сөте һаман саркып ятадыр...

Айбулатның җаны айкалгандыр —
тинтерәтте тәкъдир тол башын.
Хатыннарның аһы хәтеремдә:
«Димлик мәллә... шәфкать туташын?!»

Табышмактай авыл табибәсе,
шундый садә, шундый яшь иде!..
Ятсындырмый гына, ятимлекне
шул кыз... йөрәгенә яшерде.

Инҗиләбез күктән иңмәгәндер,
килгән иде бугай Сатыштан.

Сөйләделәр иртән сөенешеп:
«Кызның күкрәгенә... сөт төшкән!
Сөт төшкән!!»

Гаҗәпләнде хәтта гайбәтчеләр:
«Сөбханалла, нинди могҗиза!»
Үксезләрең, дөнья, үкерешеп,
елагандыр шулчак мең өйдә...

...«Кызык хәл»не сөйлим кыз-кыркынга,
кулын гына селти: «Әй, ялган...»
Хәятемнең сәер хатирәсе
әллә... әкияткә әйләнгән?!

## *Могҗиза*

Сөялердәй сердәш сайлаганда,
ишен теләмәгән йөрәк юк.
...Яратышмый яшәп ятканнарны
күзәткәлим — нинди ераклык!..

Чагыштырам күңел чагылышын:
йөзләрендә бердәй эз ничә?
Өйрәнелгән ипле өйдәшенә
эт тә охшый башлый үзенчә...

Йөрәкләре нинди ераклыкта —
уртак җепләр булмау, аһ, яман.
Балалары, Аллам, балалары
икәвенә бердәй охшаган!..

## *Сулкылдау*

Инеш буе. Бер карт туктап калган —
әллә йөрәккәе сикерә?!
Ә өстәрәк — таллык куенында
чыр-чу килеп кызлар су керә.

Кайтарырга алтын вакытларны
алтын балык юктыр шул монда.

Кызкайларның тере сурәтләре
агып төшә инеш суында...

* * *

Таң җиледәй кагыласы килә
әнкәй чәче төсле чал кырга.
Кылганнарым өйгә ашыгадыр
кайту сөенчесен алырга.

«Күчтәнәчем алдан кайтып җитсен —
җибәримче сезгә җыр биреп!»
Ә кылганнар мине узып китә,
март бураны кебек сибереп.

Таң җиледәй кагыласы килә
әнкәй чәче төсле чал кырга.
Кайталмаган җаннар әманәтен
кемнәр йөрәгенә салырга?!

## *Дәвам*

— ...Әкиятнең дәвамы ничек?
— Аны әбиең генә белә иде, кызым...

Ахырына кадәр тыңланмаган
бер әкият яши җанымда.
Шуңа күпме дәвам уйлап таптым —
истә түгел хәтта саны да...

Тик кайсысын чын дип уйларга соң?!
Юк,
ахыры аның бүтәндер.
Ә бәлки, мин әнкәй әкиятен
яши-яши дәвам итәмдер.

Ахырына кадәр тыңланмаган
бер әкият яши җанымда...

## Әнкәй хатларын укыганда

«Капка ачып, көтү каршыларбыз —
малай чагыңа бер кайт!..» — дисең.
...Кулларыңнан үрелеп ашый идем
малга дигән ипи катысын.

«Яулыгымны дулкын алып китте...»
Кер чайкавың мәңге хәтердә.
Туй күлмәгең, сандыгыңнан алып,
юасыңдыр әле хәзер дә.

«Бишегеңә кошлар оялаган...»
Әкиятеңдә яшим һаман да...
Төнбоек та күзен йома иде
күңелеңнән моңнар тамганда.

Нинди сүздән башлыйм җавабымны?! —
Җырбашчым дип сине атыйммы?
Ачуланма, әнкәй, кешеләргә
шигырь итеп укыйм хатыңны.

* * *

Кул астыңа шәфәкъ агып кергән...
(Җөй эшем, дип, күз дә йоммадың.)
Ак энәңнән ай нурлары аккан,
тәгәрәтеп якты йомгагың.

Кул астыңа төннәр агып кергән,
көннәр агып кергән бүз булып.
...Энәңдә дә, әни, гомереңдәй,
кояш нуры калган өзелеп...

## Санау догасы

Малай чакта, йоклап китәр өчен,
саный идем йөзгә, меңгәчә...
Җидегәнгә кадәр җиткәнмендер
фәрештәдән иңгән моң аша.

Йокы белмәс әби, дисбе тартып,
саный иде туксан тугызга...
Йоклаганда күкләр якынайды,
әфсен укыганмы төн безгә?!

Изге җаның, әбекәй, күчте инде
чикләнмәгән саннар ягына.
...Йокы качты. Кулым тисә, куркам —
никтер һаман дисбең ят миңа...

* * *

Адым саен хатирәләр —
җиргә гөлдәй түгелгәнме?!
Йә гөләп күк чәнчеп ала,
йә назлый ул күңелләрне.

Йә күгәрчен күзе булып,
бага кебек яшь чаклары...
Аланнарга сибелешкән
авылымның карчыклары.

Бөтнек эзләп йөриләрме,
онытып барлык гамьнәрен,
әллә эзләп
кыз чагында җиләк арасына
тәгәрәгән мәрҗәннәрен?!

# *Туй күлмәге*

> Атаң-анаңны кабергә салган дөньядан ни мәрхәмәт өмет итмәк кирәк!
>
> *Ризаэддин Фәхреддиневтән*

Кыз чагында күлмәк теккәнсеңдер,
чыгар вакыт җиткәч кияүгә;
теләк теләп,
насыйп булсын, диеп,
тик бер генә тапкыр кияргә,
тик бер генә тапкыр кияргә...

Ник ашыктың, әни,
шул аклыңны
син икенче тапкыр кияргә?
«Туй күлмәгем белән...
Җир асты да
якты була күрсен...» — дияргә...

Ник ашыктың, әни?..

## *Миләш*

Чү! Бер песнәк миләш ашый —
ачы тели күңеле...
Бу бит минем зур кайгымны
уртаклашу түгелме?!

Тыныч кына үтә алмыйм
миләшлекләр яныннан.
Тәлгәшләре — хәтер уты —
шул утта мең янылган.

Яна башлыйм, шуларга гел
күзләремне төбим дә...
Минем әнекәем ята
кызыл миләш төбендә.

...Хәстә әни. Бит алмасы —
йөткерүдән кан качкан...

Шулай тоям: бу тәлгәшләр
укмашкандыр кан-яшьтән.

Эчтән янам! Котылалмыйм
шул гомерлек җәбердән.
Капмасам да — миләш тәме
китми һаман бәгырьдән.

Чү! Бер песнәк миләш ашый —
ачы тели күңеле...

# *Сабан туенда чүлмәк вату*

Җенем белән ордым бугай,
иртән торып сул яктан, —
әллә нинди сихри нурлар
чәчрәп китте чүлмәктән.

Ярчыклары арасыннан
агып торды яктылык;
күзне хәтта яулык аша
авырттырды шактый ук.

Вәйран булды парлакъ* савыт,
аһ, әйләнде ком-ташка...
Әллә соң мин күсәк белән
кизәндемме... кояшка?!

Буыннарым яңгырады,
җан үтәли акты моң.
Түктем төсле газиз әнкәм
гүрендәге яктыны!..

---

* *Парлакъ* — нур чәчеп торучы.

## *Капка*

Чисталыкка табынучы
җан булган ул асылда.
Беләсезме: юган хәтта
капка баганасын да.

Кыра-кыра юар өчен
алган чыра пычагы...
Бер дә кулын селтәмәгән:
«Бетмәс,— дип,— мир пычрагы».

Ә бу сүзне аңа күпләр
әйтеп калган артыннан.
Көндез шундый эшне дә ул
башкарырга тартынган, —

кеше-кара күрмәсен, дип,
төнлә чыккан юарга.
Әнкәй капка чистартуны
санамаган юк-барга.

Ачык йөзле шул капкага
кер-пычракны кем яга?
Ә ул моннан кәвешен дә
сөртеп чыккан дөньяга.

Акбүз атлар, борын төртеп,
ачканда да тап кала...
Тәгәрмәчләр тәгәридер
саз чәчрәтеп капкага.

Онта сыман куна тора
олы юлның тузаны.
Чәче белән җир себергән
капка юмый түзәме?..

Ярый, кайчак җир пычрагын
яңгыр юа, кар ала.
Һәркемгә дә ачык капка,
әйе, тизрәк карала.

Бер уйласаң, бу гап-гади
капка гына түгел лә.
Бәлки, шуннан башланадыр
керү безнең күңелгә...

Фани дөнья пычрагыннан
ник бер генә тап калсын!..

...Каны белән юган кеше
Бранденбург капкасын...

...Кеше-кара күрмәсен, дип,
төнлә чыккан юарга...
Әнкәй капка чистартуны
санамаган юк-барга.

# *Җомга көн күк катында*

...Самолетта рухлар сәламләшә,
сүтә вакыт хәтер йомгагын.
Аныклыйдыр әнкәм онытуына:
«Җидегәннең таҗы — җомга көн...»
Җомгаларда идән юдыртмады,
сугармады хәтта яранын.
«Гыйбадәткә,— диде,— гыйбадәткә
багышлансын көнең, йа Раббым!..»
Әһле ислам намаз укыр чакта
тыеп торды башка гамәлдән.
Вагыйзләрчә әйткән вәгазьдәнме
әллә нинди гайре гамь калган?!
Тәкрар иткән үзе, тәгълим биреп,
үзе тапкан мине... җомга көн.
...Самолетта рухлар сәламләшә,
сүтәм күктә хәтер йомгагын...
Сәламләшкән чакта сулышыңның
тоям никтер авыр булуын...
Калдырткандыр ничә намазыңны
тулгагыңа тормас бу улың.
Ярлыкагыл, диеп ялварганда,
мин Күк белән калам бергә-бер.
Языклыга кемнәр язылганын,
хәер, Аллаһ үзе беләдер.
...Самолетта рухлар сәламләшә,
сүтәм, әни, хәтер йомгагын.
Нәүмизләтә калган намазларың —
туган көнем бүген — җомга көн...

## Үрмә гөл җебе

Әгәр төштә упкын йотса,
өстән сихри өн иңә;
үрмә гөлнең җебе буйлап
күтәреләм өнемә.

Кысылудан, киселүдән
бәгырь өшеп, кан катса,
үрмә гөлнең җебе белән
ямау салам канатка.

Пыран-заран килсә дисбе,
өзде, димен, җен генә.
Тезәм «Аллаһ исемнәре»н
үрмә гөлнең җебенә.

Кайчак тау-тау уйлар изсә,
бушанырга телим мин,
ялгап ... яшен тамырына
җебен үрмә гөлемнең.

...Әнкәй! Рәхмәт юлларында
катлы-катлы үр күрәм.
Кабреңдәге үрмә гөлгә,
килеп, янә үреләм...



# V БҮЛЕК



## *Замана кайтавазы*

Үзгәргәнме җир-күк үзәннәре —
кара күзгә охшап кайта яз.
Бәгыремдә өннәр бәргәләнә,
дөрес яңгырамый кайтаваз.

Карурманга кереп, каруымны
белдергәндәй дәшәм: «Узаман!»
Адаштырып йөрәк авазымны,
ишеттерә шаңдау: «Ул яман!..»

Антлар эчә кемдер: «Газиз халкым,
бары сиңа гына мин гашыйк».
Кыйтгалардан тавыш кайтарыла,
чын-хак җавап төсле: «Мөнафикъ!»

Чукрак кебек китеп барган затка
ялгыш кычкырганмын: «Аксакал!»
Әллә күкме күкрәп була мине,
төзәткәндәй итә: «Аһ, шакал!..»

Үзгәргәнме җир-күк үзәннәре —
кара күзгә охшап кайта яз.
Сәхрәләрдә өннәр сихерләнә,
алдый сыман мине кайтаваз...

* * *

Эш җаваплы, ат канатлы —
туктаталмас берни дә!

Кайчак тотып тора икән
күзгә кергән черки дә...

## Егылу

Имгәнүдән, имеш, котылып калыр,
егылса да сабый һәр төштә;
нарасыйга йомшак булсын өчен,
канат җәеп куяр фәрештә.

Сабый чакта шулай...
Ә олгайгач
егылудан кеше ут йота.
Җирдән түбән төшмәс, диптер, дөнья,
йомшак җәеп, каты утырта.

Юк, бүтәнчә булмый яшәештә,
дүрт аяклы ат та абына.
Җидегәнгә карап егылулар —
җегәр җыю, бәлки, аз гына?!

Сагалыйдыр хәтта елгаларны
шарлавыклар кебек егылу.
Мондый егылулар — түгел әле
түбәнлеккә төшеп юк булу.

Мич башыннан егылып төшүнең дә
рәте бар, диләр бит халыкта.
Кәвешенә тузан кереп тулгач,
сөрлеккәндер әле Алып та.

Егылулар, дөрес, йөз төрледер:
мәтәләсең такыр урында;

сузып сала сине аякларның
бер-берсенә абынуы да...

Егылганга йодрык диеп, кайчак
хәтта егылганны кыйныйлар.
Ә кай дуслар шундый авыр мәлдә
бер сүз әйтергә дә кыймыйлар.

Хәрәмләшкән әрсез көрәшчедәй,
дөнья гел чалырга чамалый.
Сабый — куркып,
ә без егылганда
йөрәк авыртудан җан елый.

Бу заманда тизрәк әйләнә Җир —
егылырга мөмкин һәр төштә.
Каты егылсак та, күтәреп ал,
безгә насыйп изге фәрештә!..

## *«Кем сукты?» уены*

Шаукымланып төрле шоу-шуларда,
яшьләр сине, ахры, онытты.
Өлкәннәрнең исә йөрәкләре
өзгәләнә кайчак: «Кем сукты?»

Уйламыйча хәзер уйнамыйлар,
бераз башкачарак алым да.
Сугучысы сиңа сулагайлап
ора алмый халык алдында.

«Кем сукты?..»

Каһкаһәле ымны кыйналучы
йөрәк үзе генә ишетә.
Сволочьлар сугу сәнгатенең
серен яхшы белеп эш итә.

Сугучылар өрәк сурәтендә
биешәләр, чыгып алдыңа.
Этлекләрен чуар битлекләргә
төрүчене танып кал димә.

Елатырлык итеп елмаялар
мәркәздәге мәшһүр мимнәрчә.
Игезәктәй охшаш йөзләреннән,
күрәм, кешелекле «Мин!» кача.

Кайтаваздай һаман кабатлана
кара донос кебек «Кем сукты?»

Ужҗарланып арттан сугулары
йөрәкләрне, ай-яй, йончытты!

«Кем сукты?»га җавап эзләгәндә,
эзәрлекли авыр уй мине, —
зыялылар күбрәк оештыра
«культурасыз» мондый уенны.

«Кем сукты?»

Уйнасыннар, әйдә, унаулашып,
әмма уйласыннар иң алдан:
яхшылыкның ап-ак фәрештәсен
бәреп төшертмәбез иңнәрдән!..

## *Күңелне тынычландыру*

Йөрәгебез шактый кыен ашый,
анага бер иркә булсак та.
Нишлисең бит, чыбыклаган саен
дөрләбрәк яна учак та.

## *Чиге күренмәгән юану*

. . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Ачлык... Түзәрбез —
ил белән бергә.
Изү... Түзәрбез —
ил белән бергә.
Сугыш... Түзәрбез —
ил белән бергә.
Юклык... Түзәрбез —
ил белән бергә.
Тетрәү... Түзәрбез —
ил белән бергә,
ил белән бергә —
шулай... гомергә?!

## *Балта ашы*

1905 ел, октябрь. Петербург.
Патша хөкүмәтенә каршы күтәрелгән халыкка төбәп ут ачарга әмер бирелә.
«Патронов не жалеть!»

Генерал-губернатор *Д.Трепов*

1993 ел, октябрь. Мәскәү. «Баш күтәргән» парламент тупка тотыла.

Имәндергеч канлы империя
һәйбәт үзләштергән «ур-кис!»не.
Инде хәзер урыс орден ала
үтергәне өчен урысны.

Оныттырып канның ырулыгын,
кургаш белән аны ник җылыт?!
Урыс башы өчен орден биреп,
оран сала Рәсәй: «Не жалеть!»

Тәһарәтсез кыргый тәрәккыят
тора төсле тоташ үч-каннан.
Нәрсә көтеп була гомер бакый
«балта ашы» ашап үскәннән.

## *Сәнәк белән язу*

Сәермени телең сайраганда
суга сәнәк белән язулар.
Ыштансызлар бездә ышанучан:
һәрбер акыллыга — йөз юләр.

Гаҗәпмени тәмуг газаплары,
канга... сәнәк белән язулар*.
Савыкмадык мондый сабаклардан:
һәрбер акыллыга — йөз юләр...

* Казан һәм Уфа губерналарындагы сәнәк сугышы күздә тотыла (1918 — 1920).

## *Энциклопедия актарганда*

«Галилей»дан бераз гына үткәч,
күз терәлеп калды — «Галифе»...
Уйландырды, гәрчә бу исемне
белүем дә болай ярыйсы.

Бу кешелек ниемә соң әле
ятлап алган шушы исемне?
Ыспайланып йөрер сәргаскәргә
чалбар уйлап тапкан өченме?

Минем әни миргә күлмәк теккән,
келәймәсен халык таныган!
Ә нигә соң энциклопедиягә
кертмәгәннәр зурлап аны да?

Авыз ермагызчы: «Тарихта,— дип, —
мондый гаделсезлек булгалый...»
Галифе бар, ә ник теркәлмәгән
шагыйрь Гали, бөек Кол Гали?

Бел: Галифе хәтер китабына
коммунарлар атып юл саба.
Шул генерал һаман яши әле
чалбар исемендә булса да.

Гариплеге «качып» торган, диләр,
тар балаклы чалбар эчендә.
Әйтерсең ул файдаланган аны
ыштыр битен яшерер өчен дә.

И кешелек, яманатны шулай
мәңгеләштерүеңнигә соң?
Хәер, аңлыйм: син бит андыйларны
онытталмый газап чигәсең.

...«Галилей»дан бераз гына үткәч,
күз терәлеп калды — «Галифе»...
Уйландырды, гәрчә бу исемне
белүем дә болай ярыйсы.

Уйландырды...

## *Гадәт*

...Туган көн тортларында,
сыйныф журналларында,
кызыл такталарда,
дивар-коймаларда,
абитуриент исемлекләрендә,
чигүле кулъяулыкларда,
шаһәдәтнамәләрдә,
акча ведомостьларында,
шобага-жирәбәләрдә,
фатир ордерларында,
рөхсәт язуларында,
чакыру кәгазьләрендә,
афиша-игъланнарда,
күзәтү мәкаләләрендә,
белешмә-лөгатьләрдә,
васыятьнамәләрдә,
котлау хатларында,
сайлау бюллетеньнәрендә,
мактау грамоталарында,
бүләкләү карарларында,
указ-фәрманнарда...
һәм башкаларда

үз исемен эзләп табып өйрәнгән ул —
булдыралмый шул гадәтен ташларга.
Хәзер инде комар күздән читтә калмый
мәрмәр такта, кабердәге ташлар да...

## *Коткару*

...Ишетелде күрше ишегеннән —
ирен сүгә хатын кот алып:
«Бишбалтада әтәч кычкырганчы,
инде кайттың... шайтан коткарып*!»

Көләргәме, белмим, еларгамы,
көн дә тыңлап шушы «шат пар»ны.
Мәликләре качкан мәмләкәттә
коткаралар күпме шайтанны!

Бетәрлекме мондый битәрләүләр —
әйтеп булмый әле кырт ярып.
Юлбашчылар илне яшәтмәкче
халык белән... шайтан коткарып...

---

* Хәмер эчү мәгънәсендә.

## *Тәкъдир искәртүе*

*Г. абый турында уйлап*

Син теге гасырның төпчеге икәнсең —
шөкер ит, шөкер ит...

Җир шарын өлешләп, имана биргәннәр —
шөкер ит, шөкер ит...

Микулай патшаның икмәге әләккән —
шөкер ит, шөкер ит...

Аурупа илләрен күрсәткән... өч сугыш —
шөкер ит, шөкер ит...

Инде бит өченче хатынны җирләвең —
шөкер ит, шөкер ит...

Ничә мең күбәләк гомерен яшәдең —
шөкер ит, шөкер ит!..

## Гаҗизләнү

Иләмәннән сорый илдәшләре:
— Ничек анда... китап ни әйткән?
— Борчылмагыз,
хәтта җәһәннәмне
булдырганнар яхшы нияттән...

Гарьлекләргә күнгән гаярьлекнең,
гаҗизлекнең холкы, ай, коры:
— Мондый илне нинди ният белән
бар иткәннәр, шайтан алгыры!..

## *Сыналган шайтан*

(Борынгы хикәяттән)

— Илдә шау-шу — хаким, сине
без ничек тыңлый алыйк?!
Һәйбәт кенә ханны тагын
шайтанга тиңли халык.

— Имеш, кылган һәммә эше
җинаять, язык имди.
Мәдәт бирче, Хакның туры
юлыннан язмыйк инде.

— Таҗга нәфес сузган мәкер
иманга үтеп керә.
Һәрбер «олтан» үзен солтан,
фәрештә итеп күрә...

Бәргәләнгән бәндәләргә
Баш хаким әйткән актык:
«Сыналмаган фәрештәдән
сыналган шайтан артык».

## *Татарлык*

Имсез чирне ачкан Шагыйрь: «Татарлык...»
Сөйли китсәң, телне бизгәк тотарлык.

Сабыеның тырнаклары астыннан
ләззәтләнеп кер эзләве аз сыман.

Әйе, Иисус тәресеннән кан саркый...
Зөһрә кызны кем соң Айга кадаклый?!

Ханбикәсен биреп бөлгән сәүдәгәр...
Татарлыкта «тарлык» дигән сүз дә бар.

Өләшкәндә... дәүләт алган бар кавем.
Бакчы, аның «Җомга көн», дип бармавын!..

«Хәсәд, кинә илән тулган татарлык,
төяб илтеб Мәкәрҗәдә сатарлык»*.

...Менеп татар «җеназасы-аты»на,
әләк белән китә Аллаһ катына...

* Г.Тукайдан.

## *Бүре чакыру*

...Тавыш бирә Шагыйрь еллар аша:
«Карсак япон анда исәнме?»
— Учта туфрак ташып, җирен сипли
һәм китәрә безнең ис-аңны!

Сорый Тәкъсир: «Җайлы яһүд ничек?
Бирмәс идем берсен мең ятка!..»
— Дәүләт саен дәүләт төзеп яши,
холкын сала һәрбер милләткә.

Сорау арты сорау: «Инде хәзер
чәйле кытай хәлен әйт, туган!»
— Көнләштереп кечек кавемнәрне,
иза чигә... халкы артудан...

Белә торып, газиз әһле белән
кызыксына Шагыйрь сак кына.
— Ничек итеп әйтим, татар һаман
Ил-йортына бүре чакыра...

# Аерымлык

Горурланып төшендерә аталар:
«Татар» дигән сүздә, улым, «ат» та бар!

Эшли-эшли «ат казанган» татарга
ат эзеннән су да язган татырга.

Һәм азактан, менеп ап-ак пырак*ка,
парлап очу насыйп булган бер якка...»

Аһ, шул юаш, үтсез малкай янында
йөрәк сызлый, әрни башлый җаным да.

Татар тарткан зәһәр кинә ягына —
көтеп тора үтен сытар җай гына...

---

* Пырак — мөселманнарны күккә очырта торган канатлы ат.

## *Кемчә яши?*

Куян, күсе, тиен, чәшке, бүреме? —
ирнең башын кысып тора бүреге...

*(Мондый затлар кемчә уйлый, Ходаем?)*

Шундый күлмәк — табып булмый каюын,
кигән кызый, ахры, елан кабыгын...

*(Мондый затлар кемчә сөя, Ходаем?)*

...Кышкы юлдан бара, әһлем, бер бәндәң —
баштанаяк сарык толып бөркәнгән.

*(Мондый затлар кемчә яши, Ходаем?..)*

## Карга

Нигә әле Тукай бакчасына
шулай кереп шигырь язаммы?!
Хәерлегә булсын, хәерлегә:
карга басты шәһри Казанны...

Сыннарына күзең төшерсәнә —
әллә нинди тозсыз ялган бар, —
мәшһүр казлар кеби, Римнең үзен
һәлакәттән йолып калганнар!

Канатлылар нәселе булгангамы,
караганмын бары бер яктан;
әрсезләнү, вәкарь, тәкәбберлек
аңкып тора мини фрактан...

Шушыларны биреп алынганмы
шагыйрь кулындагы күгәрчен?
Сандугачның басып бугазына,
укыганнар, ай-яй, күп ясин!..

Җырчыларны гына эзәрлекләп,
ашаганнар йөзнең сиксәнен!
Җирдәгене күктә кабатлауның
белмим нигә кирәк икәнен.

Җир белән күк аермасы, имеш —
күрәсезме берәр үзгәлек?
(Ярый әле безне тутый кошлар
кабатлыйлар коры сүздә тик...)

Үзләренең канлы авызларын
яшермиләр дә бит чак кына;
исәплиләр сине күгәрченнәр
янындагы чәүкә затына.

Яхшылыклар эзләп очынучы
ап-ак фәрештәләр күчендә
суелырга мөмкин Тукайҗанның
безгә күчкән күңел кошы да...

Эндәшмәкче булам «героем»а:
«Буразнада гына чуалсаң...»
Аңлашыла, әйе, аңлашыла —
сайрый белми икән суалчан.

# *Кешеләрдәй төрле күбәләкләр*

— Дөньядагы мондый чуарлыкны
билгеләрдәй төгәл сан бармы?
— Күбәләкләр — төрле кешеләрнең
канатланып очкан җаннары...

— Искәртәдер алар төрлелеген
корамадан торыр дөньяның.
— ...Алай булса, көя күбәләге
асрап йөртә икән кем җанын?..

## *Шайтан шамакае*

Бәрәкалла: бәгъзе берәү
табут... ашап бетергән (?!)
Юылгандыр юләркәйнең
эчендәге бөтен гамь.

Җене килгән, җиңмәк булып,
ахры, үлем куркусын.
Тамагына тыгылмаган —
үҗәтлекнең күр көчен!..

Биләп алды шушы гамәл
көнделемнең түр башын.
Яман нәфес нәҗес итәр
җәсәденең төрбәсен!

Шомлы шайтан шамакае
кызык ясый кем өчен?
...Татымаган тоталитар
алабута күмәчен...

Туя алмый, табут ашый —
тамак түгел, тәмугтыр.
«Бисмилла»ны белмәгәнгә,
авызында тәм юктыр.

Вәкарь белән белдерәдер
иблисчәрәк карашын:

«Шундый аштан,
                    шундый аштан
олы булып кара син!..»

Тамагына тыгылмаган
табуттагы тәре дә...
Кәфен белән авыз сөрткәч,
гамең булмый Тәңредә.

Табут ашау — табу түгел,
биреп булмый... ун камчы.
Фанилыкның фанатигы
гомер итсен үлгәнче!..

## *«Гаип»тән хәбәр бирүче*

Кеше кайчак, шамакайдай, китә тәмам онтылып:
бүре төсле улап тора, өреп куя эт булып.

Әллә шулай аваз салгач, җанга тансык көч керә?!
Айгыр сыман кешни адәм, ишәк кебек кычкыра.

Карурманда кәккүкләнә, тургайлана басуда...
Аңлыйм, йөрәк авазыннан ерак тора барсы да.

...Инсан булып аваз салса тургай, кәккүк...
эт, бүре?!
Хәер, әнә, тутый кошлар кешеләшә отыры:
«Дур-рак!..»

## *Аерымлык билгесе*

(Бер эксперт сөйли)

Бер-берсенә шулкадәрле
тартым да соң кешеләр.
Эзлә генә: охшашлыкта
һәркемнең дәише бар.

Кием-салым, килеш-килбәт,
төс-бит — тәңгәл барсы да.
Бер-берсенең күчермәсе
торадыр күк каршыда.

Игезәкләр әле бер хәл,
двойниклар булгалый.
Бутамыйча әйтеп кара:
«Бу — Вәли,— дип, —
бу — Гали...»

Әллә алар бер үк нәсел
агачыннан өзелгән?!
Кешеләрне аерып була
бары... бармак эзеннән.

Шулаймы?

## *Тавык тәпие*

Пәйгамбәрнең көймәсендә
ашаса да чүп-чарны, —
юк, барыбер чукынчыкка
чыгаралар чучканы.

Гөман кылмыйм: һәммә хадим
үз халкына колдыр, дип.
Йөри, әнә, «милли тавык»,
тәре эзе калдырып...

## *Хуҗасына охшаш бакча карачкысы*

Күрмәгәнмен шундый карачкыны,
киенүе милли — бак кына!
Курыкмаган үзе каргалудан —
чалма урап куйган башына...

Җилкәсеннән җилме җилтерәтте,
шаяннарча ихлас үз күреп.
Каршымдагы милли карачкыдан
агач... тәре калды утырып.

## *Әйләнмә урындык*

Нигә шуны кеше кулы
ясамаган борын ук?!
Сынап сайлый, сынап сайлый
әйләнмәле урындык.

Түмәреңдә тамырланган
иләмәнме? Яшьме син?
Әйләнчеккә әйләндерә
әйләнүчән башлысын.

«Кресло... дөнья...
кендек!..» — диеп
уйлаучылар да була;
әйләнәли әйлән-бәйлән
уйнаучылар табыла.

Мөритләре майлаштыргач,
Җирнең шушы «күчәр»ен,
узаманнар узынадыр,
сизеп илаһ көч барын.

Кыска юлны әйләнечкә
әйләндерә кем диген?
Хәтта халык башын бутый
кечтек кенә кендегең...

Башкайларны әйләндерә
урынбиләр әйдәүче.

Әйле-шәйле яшәүләрнең
хакыйкате, әй, ачы!..

Әйләнчеккә әйләнгәнне
айнытырга ырым юк...
Сынап сайлый, сынап сайлый
әйләнмәле урындык.

...Түнтәрелгән түрәләргә
тәкъдим итмим... төп башын.
Хәер, анда Җирең белән
әйләнгәнне тоясың.

## *Өстәмә сыер*

Канга чаклы савылсаң да,
эшең күзгә күренми.
Хезмәт — уртак, ә хөрмәттән
сиңа өлеш бүленми.

Баш түбәнә бассалар да,
син, янәсе, сабыр ит.
Пьедесталга әнә шулай
күтәрелә фаворит,
башкаларга караганда
күпкә азрак эшләп тә...
Ә син, кирәк җан булсаң да,
түгелсең сан-исәптә.

Синең хәлдә ничә калып,
бәгырь туңды, кан катты.

...Кара җептән тегеп булмый
фәрештәгә канатны...

# *Катыктан акча эзләү*

Хак түгелме:
безнең куллар
эшли авыз өчен дә.
Авызга кул ярдәм итми
бары катык эчендә.

Кирәк чакта сандугачтай
сайрасын һәм кош тотсын, —
әйтү башка — эшләү башка —
авыз шуңа төшенсен.

...Тәлинкәсе бигрәк тирән,
ә катыгы ап-ачы...
Авызыңа керәм, диеп
тормый икән акчасы.

Ачы хаклык шикелле ул,
өскә чыкмый тиз генә.
Ә катыкта акча төмен
авыз шундук сизенә.

Әйдә, авыз бер мәртәбә
үзе эшләп ашасын...

Ни әйтәсең икән, халкым,
шушы уен аша син?..

* * *

«Алыштыргысыз син!»

Ә кайчакта
бу хак сүздән ерак торасың.
Эштә генә түгел,
мәхәббәттә
бер-береңне алыштырасың.

Мин —
тиңнәрсез түгел,
бүтәндә дә
бардыр, бәлки, минем уй-гамьнәр.
Тик әйттермәм:
«Бу мескенне бүген,
ахры, алыштырып куйганнар...»

## *Ялланып елаучы*

Синең өчен дә бер елаучысы
килеп чыга икән — ул генә.
Җирдә япа-ялгыз калганмыни —
шундый оста керә роленә!..

Күз яшенә һаман туймаганмы —
ничек елап була ялланып?!
Әллә соң ул шушы эше өчен
юанамы кыйммәт мал алып?

Ә үзенең, ахры, күз яшьләре
саф кына да түгел, ачы да...
Ничек еласа да, ул барыбер
артист булып кала асылда.

Борынгылар юкка әйтмәгән лә:
үз кайгыңны, диеп, үзең йот;
кырык шырпы дәррәү кадалса да,
йөрәгеңне берүк түзем тот!

Кеше хәлен рольдә уйнап кына
мөмкинме соң белеп бетерү?!
Ә шулай да кайчак җан әрнүен
җиңеләйтә хәтта эт өрү.

Сукыр яңгыр явып үткәндә дә
рәхәт булып китә хастага.

...Елаучыда синең бугазыңны
буып торган шул ук яшь ага.

Нигә әле аңа бәйләнәм мин,
күз яшеннән һаман кер эзләп?
Җиңел түгел ирексездән елау,
үз йөрәгең үзең көйсезләп.

Үз ярасын кем дә сыктап юар,
кеше өчен елый ал икән.
Беләсезме, шушы күз яшьләрен
җыеп килгән бит ул халыктан!..

Нигә әле аңа бәйләнәм мин?..

* * *

Өлкәннәр ямьсез елый...

Онытканнармы —
балачакта,
кояшлы кыска яңгыр төсле,
бит алмасын юып алуларын?!

Өлкәннәр ямьсез елый,
әллә ничек чырай сытып...
Күз яшьләре
авыз читенә сузылып төшкән сырларны,
вакыт-эрозия тирәнәйткән
җыерчыкларны өтеп аламы?!

Өлкәннәр ямьсез елый,
хәтта сөенечтән дә...
Килешми —
теле белән әйтә алмаганны
елап аңлатучы
сабый кыяфәтенә керү...

Өлкәннәр ямьсез елый,
өлкәннәргә елау килешми.

Шуңадыр да, олыгайган саен,
җир астына киткән дәрьядай,
күз яшьләре эчкә йотыла бара,
эчкә —
күңел күзенә...

## *Бәдәл*

Инде бездә күптән бетте бугай
кеше өчен хаҗга барулар.
Башка төрле уйлап баккан чакта,
бәдәлчелек әле бар ул, бар.
Яллаучының була көнлекчесе,
илаһ эшкуарның бар колы.
Фаворитлар данга адарына
бәдәлчедәй бәндә аркылы.
Күңелләрен изге ялганнарга
күнектергән затка аз болар!..
Кеше өчен нотык кына түгел,
булды хәтта китап язулар.
Чүпрәк ашап туймас бозау төсле,
күндәмнәре һаман кул ялый.
Башка кеше кылган гөнаһ өчен
хәтта утырулар булгалый...
Пишкадәмдәй күпме бәдәлчеләр
юлда үлгән бәгъзе зат өчен.
Мәккәсенә болай «баручы»ны
хаҗи диеп ничек атыйсың?!
Яллаучылар... Ихлас йолачыга
бер дә охшамаган шул алар.
Башкаларның басып башларына,
пәйгамбәрлек итмәк булалар.
Канәгатьлек белән куаналар:
«Бирешергә әле исәп юк!..»
Бәдәлчелек бездә бетмәячәк,
күрсәтелгән чакта ишәклек.
...Иңемдәге бер-бер фәрештәме
ирештерде шундый сүз миңа (?!):
«Алла колы, бөтен изге эшне
башкарырга язсын үзеңә...»

# Алай-болай

*Каменный Починок чиркәве.*
*Август, 1959*

...Ташландыкка калган Ташлавылда
авыр мәсьәләгә тарыдык;
«яшәтмәдем» урыс яшьтәшемне:
— Күктә Ай бар, нигә тәре юк?
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Еллар аша безнең тавыш белән —
күкләр катламында, кайдадыр —
сөйләшәләр сыман салмакланып:
— Җирдә тәре дә бар...
— Ай да бар!..

## *Үкенечле ләйсән яңгыр*

Сыенылган иске чиркәү диварына —
юкса анда, йәле, нәрсә җуйган мин?!
...Гөмбәз өсләп шарлавыклар аккан чакта
тәре юган суны... йотып куйганмын...

Эчмәгәнмен Зөһрә кызның чиләгеннән —
кимсенүнең юшкыннары, ай, ачы!
Ай-яй ерак, Хак Тәгаләм, ай-яй якын,
хәрәм-хәләл, хәләл-хәрәм арасы...

# *Дәһрилек*

Көфер сүзләр килсә ялгыш,
авызга... икмәк тула.
Кемнәр анда Алла колын
үз колы итмәк була?..

# *Тагын «урысныкы» турында*

«...Само слово «секс» имеет чисто
русское происхождение!»

*М.Мишин*

Урысныкы иде урманыбыз,
кыш, чәй, мунча — бар да аныкы.
Гайрәтлеләр инде гаурәтеңне
кисеп ала...
Максат аныкмы?

Йомгаклыйлар күз дә йоммаенча:
«Безнең баба сүзе... чип-чиста!»
Аракыбыз булгач урысныкы,
алардандыр, бәлки, «секс» та?!

Раслагандыр азгын Распутины
гомер буе... зөфаф кичендә.
Кыз-хатынга, бахыр, кызганмаган
тәнендәге соңгы көчен дә...

Ышанмыймын «секс эше»гезгә,
китер дәлилләрнең мең төрен.
Гыйш-гашрәттә йөзгән гыйззәтлегез —
Әби патша басса мөһерен,
бәлки...

## *Айга менүчеләргә үпкә*

Ләззәтләнү белән сөйләнәсез:
очрамаган, имеш, Ай кызы.
Әлмисактан килгән ышанычны
сүндерергә бармы хакыгыз?

Серлелеген саклар алъяпкычын
салдырдыгыз бер дә оялмый...
Илбасары булып әкиятнең,
нигә үтердегез хыялны?

Табындыргыч Зөһрә йолдызларны
ялангачлап була Айдан соң...
Аңламыйсыз изге ялганнарның
кешелеккә хаҗәт файдасын.

Үзегезгә генә билгеледер —
күпме тора бөек сер хакы.

...Беләгенә берсе икеләнми
язган: «Айда юк,— дип,— аракы!..»

## *Тамаша*

Карап торам сандугачлы тал аша —
аргы ярда ике хатын талаша...

Әллә ниләр алга килә, йә Аллам —
агу сорый тузбаш... кара еланнан...

Миңа гына шәйләнәме: күр, ләгыйнь —
кимәк була фәрештәнең күлмәген...

Карап торам сандугачлы тал аша —
яшел ярда менә шундый тамаша...

# *Ретро (?!)*

Байбәтчәгә нәрсә кайгы —
«Шамшамиткә» сау булса...

Г.Тукай

Ай-кояшсыз ага бирә көн-төнең...
Тәннәреңә сеңгән кабак төтене.

Сәрхуш сине охшатадыр аккошка...
Иреннәрең — кемнәргәдер закуска.

Калды икән кемнең генә кочагы?!
Кемнең куенында калган кыз чагың?..

Иреннәрең тәре кебек үбелгән,
җырларыңда бар язларың күмелгән...

...«Яңабаштан! Бис-бис!..» —
диләр кабакта.
Мондый җырны буламыни кабатлап...

## *Иртәнге өч кызгану*

Кызгандыра кыз-хатынның
«салып» башлаган көне;
төнгә баккан боек гөлдәй,
сулып башлаган көне;
тартынмыйча гына... тавык
чалып башлаган көне
кызгандыра...

# *Кырым комлыгындагы ханым*

(Җәһәт портрет)

...Абау, әби патшамыни!
Утырамын ут йотып.
Башындагы эшләпәсе —
булыр каз да утыртып.

Ука-чуклы күкрәкчәгә
самавырлык су сыяр.
Кулга төшкән ганимәттәй
булса икән шушы яр!..

Акулалар эләгерлек,
сөзсәң, эчке күлмәге.
Шайтанымны шелтәләдем:
«Шунда туктый күр, яме!»

«Сүгенүем сагындыңмы
әллә ничә кат итеп?!»
Әфсенләнгән нәфесемне
тора һаман котыртып.

...Күзләремне кызыктыра
тыелулы сый төсле.
Әгъвалаучы оегына
бер пот суган сыешлы...

## *Кавын сатучы хатын*

Чарасыздан бастым чиратыма,
белешмичә әйбер хакын да.
Ымсындырды миндәй имансызны —
тылсым бардыр бу яшь хатында.

Нәфсехурлар инҗри нәфислектән:
«...Үкендермәс соңра... үлсәң дә!..»
Кояш сутын эчкән ике кавын —
күкрәк биеклеге үлчәүдә.

Арасында, абау, арасында
күкләр белән тоташ тирәнлек!..
Көтмәгәндә шайтан котырттымы —
базар чиратында торам ник?!

Кавыннары нинди кавемнәндер,
чыкты үзе шундый кыз булып —
үртәгәндәй, күкрәк уртасында
алтын тәре тора кысылып...

Гаурәтенә карап гайрәтләнгән
гайре берәүләрне күзәтәм.
Кармалаучан комсыз карашларда
кабатлана кебек йөз хатам.

Кавын өчен чират алмый бугай
монда ир-атларның күбрәге...

Саташтырды башны сатучының
ташып торган тере күкрәге.

Газәлләргә күчәр гүзәллектер,
ничек инде, имеш, эч янмас...
Тәтәйләргә хирыс татаркаем —
тотып карамыйча ышанмас.

Тыелганы тәмле тоеладыр —
әгъваланган күпме угъланнар.
Әсирләүче күкрәк арасында
башны югалтырлык урлар бар.

Түшендәге «тавык тәпие»нә
ирен тиеп китсә... Йа Хода!
Тартындырмый бугай татарымны
Айдан савылучы якты да...

Чиратымда тәмам чорсызландым,
өммәтемә әллә көч килеп?!
...Үртәләүче күкрәк уртасында
алтын тәре тора кысылып...

# *Җиргә яңадан кайту*

*Ш. абый авызыннан*

...Мин тал булып кайтам. Бүген төштә
мәңгелектән би-ик күп көн алдым.
Чыбыкларым канга чыланмасын —
үзем гомер буе кыйналдым.

Хатын-кызга артык авырлыклар
салмадыммы — шуны кем әйтә?
Әгәр җиргә юкә булып кайтсам,
ясамагыз миннән көянтә.

Тәкъдир мине җикән камыш итсә,
эндәшерләр: «Курай бул, әйдә!..»
Мондый хәлгә түзәр микән җаным —
моңландырды дөнья болай да.

Әгәр җиргә тагын кайта алсам,
була калсам бәбкә үләне...

...Әллә әҗәл әйтте, әллә... хәләл*:
— Ә син, мәхлук, башта үл әле!..

---

* Никахлы хатын мәгънәсендә.

* * *

Мәҗлесләрдә тост әйтәбез:
шигырь,
шәраб,
җыр — бергә.
Ярый, кайчак хәмер була
чишелеп сүз әйтергә.

Кайчак кулга шәраб алгач,
күтелмәгән сүз килә.
Хәйям белән чәкешерлек
фикер бармы —
кем белә?!

## *Мәңгелек бусагасы*

Шагыйрьлекләр белән шөгыльләнмик
Тукай яшен узып барганда.
Тәңребезнең даһи тамгалысы
була алмый әле бер җан да.

Пәйгамбәрнең изге бусагасы
пычранмасын безнең аркада.
Тормышыңда, баксаң, тормыйсыңдыр
Тукай күзендәге акка да...

# *«Төзәтелгән ... нче басма»*

(Рецензия урынына)

Сипләп-ялгап озынайтты,
сызып-бозып кыскартты...
Бер язылган романына
инде менә өч кайтты.

Геройлары бер әйтер күк:
«Бир үзеңә кулялы!..
Йә, гомернең төзәтелгән
варианты буламы?..»

## *Соңгы киңәш*

Шигырь белән шөгыльләнде,
тәнкыйть тетте — уңмады.
Әллә теле, әллә дене,
әллә җене булмады...

Әрәм итте... фәрештәгә
тиеш каләм карасын.
...Җене, килеп, киңәш бирде:
«Хәдис язып кара син!..»

# *Яшәү белән үлем арасы*

*Нәби Дәүли рухына*
*18 май, 1989*

...Соңгы юлын кара мәче кискәч,
авышкандай итте ян-якка.
Зиһененең исән күзәнәге:
«Кереп булмас,— диде,—
жәннәткә...»

Азаматтай зурлап озаталар,
беткән, димәк, җирдә бар эше.
Беркатлыдай нигә борылырга —
җәһәннәмнән китеп барышы...

* * *

Нигә ул каласы казларга?!
Кис, диләр, канатын кызларга!..

Безнең дә кистеләр канатны —
без очтык, кояшка җан атып!

Уклар да кадалды канатка,
туктатмак булдылар санап та...

Күкләре тәбәнәк бәндәләр
янавын алмадык гамьгә дә.

Ук безне бер тишкән, бер кискән —
әманәт буласы җыр исән!

Безнең дә кистеләр канатны —
без очтык, кояшка җан атып!..

# Таш оча...

*Р. абзыйга*

Уйлап та карама: тел-кылыч
юлымда очраган киртә, дип.
Ул сине, үзе дә сизмичә,
ил-халык теленә кертә бит.

Исемеңә битараф булмауның
үз ямен таба бел, үз тәмен.
Син, димәк, хакыйкать тудырыр
бәхәснең сау-таза үзәге.

Сүз төяп килүче җилләргә,
саңгырау булмыйча, ач капка.
Үзең дә беләсең:
таш оча
бары тик алмалы агачка...

# *Ком юу*

Дустың бирсә ком,
Аны да учыңа йом.

*Татар халык мәкале*

Җан дусларны эзләп табу җиңел түгел:
йөз михнәткә — бер рәхәте — түз генә.
Берсе, әнә, кайчандыр мин биргән комны
күтмәгәндә сибеп китте күземә.

Икенчесе әйтерсең лә кызган бакыр
йомдырды да кулым белән ут тотты.
Өченчесе, күз бугандай матур алдап,
үз комыма үземне үк утыртты...

Кайвакытта затлы бөртек юклыгына
ышанса да — һәр биргәнне кул алыр.
Бу дөньяда иң югары хакка төшкән
алтын юу, бәлки, шулай буладыр.

# Бәхәс

«Һади Такташ кышны аеруча яраткан...»

*Н.Юзиев*

— Мәлгуньнәрчә «кыйнап» муллаларны,
каләмеңә кыңгыр эш тап та...
Такташевка урын тәтемәгән,
урын тәтемәгән оҗмахта.

«Мәрсияләр» язып Мирсәет*кә,
ясин чыгуларда ямь тап та...
Такташыңа урын тәтемәгән,
урын тәтемәгән җәннәттә.

Кулакларны сөрү кулланмасы
язылганда... язык эш тап та...
Такташларга урын тәтемәгән,
урын тәтемәгән оҗмахта!

— Сирәкмени күктән сөрелгәннәр,
шуңа күрә тормыйм җәлләп тә.
Такташыбыз үзе теләмәгән —
нишләр иде кышсыз җәннәттә?!

---

* М. Солтангалиев күздә тотыла.

## Дөньядан киту сәбәбе

— Туфан вафат булган...
— Ничек?!

*10.06.81*

Әләкче:
— Үлем ничек алыр булган
сират кичкән эт җанны?!

Фәлсәфә сатучы:
— Акыл җитмәс илаһ серне
аңлау һәлак иткәнме?!

Сабыйлыгын сарыф итеп
бетергәндер карт башы.

Шагыйрь күршесендәге
кызчык:
— Туфан ничек вафат булган —
беткән яшел кара*сы...

* Шагыйрь үзенең әсәрләрен яшел каралы каләм белән яза иде.

# Сурәткә төшү

*Фотохәбәрче туташка*

...Шушы томнар өчен күпме йөрәк
канын сыккан, биргән җанын да!
Юк, сурәткә ала күрмә мине
китап киштәләре янында.

Һич бизәмәс мине бөек затның
эш бүлмәсендәге өстәл дә.
Даһи янына да килеп басмам,
рәсем-истәлеккә төшкәндә.

Мин аларга тәсме?
Моның өчен
юктыр зурдан кылган эшем дә...
Үзем генә булып калыйм әле —
төшер мине, туташ... төшеңдә.

## *Җаваплылык*

*Әдип һәм очучы Салих*
*Баттал хатирәсе*

...Истә әле парашютны
тирләп-пешеп төргәнем.
«Вагон-вагон» уйларымнан
кала иде бер гамем:

«Сәнгатенә төшенмәсәң,
башың белән түләрсең;
ачылмаса, биштәр асып,
сикергән бер юләр син!..»

Парашютын әштер-өштер
төрүчеләр булмыйдыр.
...Һәрбер эшкә башы белән
җавап бирсә, бу — миндер...

# Үкенеч

*И. турында уйлап*

Хәйямнәрдән калган гамәлендә
бармак түгел, башы шешсә дә,
көне-төне, бахыр, көне-төне
шигырь язып салды... шешәгә.

Киләчәккә агып китүләрен
теләгәндер инде бичара.
(Богауланган шампан бөкесенә
ирек бирү кебек буш чара...)

Шешәләргә салып шагыйрьлеген
агызучы синме бер садә?!

Фәрештәбез ап-ак канатыннан
язар өчен каурый бирсә дә...

## *Үлеп булмау халәте*

(Саклык кенәгәсенә язылган шигырь)

*1 гыйнвар, 1992*

Чыр-чуларсыз калган чыршыларда
төне буе җем-җем ут янды.
Яңа елда барча, барча халык
Сираҗетдин* булып уянды:
«Таладылар!»

Иреннәргә кунып эределәр —
тәңкә карлар ачы, аһ, ачы!..
Үлә алмый халык — юкка чыкты
үлемтеккә дигән акчасы:
таладылар,
Сираҗетдин,
чынлап таладылар...

---

* Сираҗетдин — Г.Камалның «Банкрот»ындагы персонаж.

# *Танк һәм танка*

*Совет — Кытай чиге. Танкодром*
*1972*

Чин — урыслар белән чиләнергә
мин бу чиктә, бәлки, ят сакчы?!
Танкларның төкреп «танго»сына,
танка* гына язып ятсаңчы.

Казансуның изге казкайларын
саклый алмагансың сәмруггтан...
Тансыкламый гына танкларны,
танка язып ятчы сау рухтан.

Килешмидер бу чик «килмешәк»кә,
кайтып сакла туган телеңне.
...Танкларда дене тоныкланган
танка язгаларга телиме?!

---

* Т а н к а — биш юллы япон шигыре (кыска җыр).

## *Ишек тоткасы*

*Р.Ш.-гә*

Күләгәдәй кермим күңеленә,
кыяфәтең белән җыйнак син.
Гадәтеңнән генә газапланам:
ишек тоткалары җыясың...

Гыйбрәтләрдән торган гомеремдә
эчтән әйттем күпме төртмә сүз.
Эшмәкәрдәй ачар ишекләрнең
нихәтлесе булды тоткасыз.

Дәрәҗәле генә дарелфөнүн
ишекләрен кагар булсам да,
тоткаларын алып тоткарладың:
буталмасын, диеп, бу бәндә.

Рәсәйдәге татар ристанына
ишек бавы кыйммәт болай да.
(Тоткарларга Аксак Тимерләрне
синдәй бирәү булса Болгарда!..)

Залиманә зәһәр заманнарда
мәсҗет ишегенә тартылдым.
Каракларча капылт каерылган
тотка тишегенә тап булдым.

Каршылаучы, тыштан караганда,
дәшеп тора төсле: «Мәрхабә!»
Эш-йомышым төшкән ишекләрдән
сөрдең мине ничә мәртәбә.

Арттырмыйча әйтәм: арт ишеккә
барсам — тагын миңа киртә син.
Тотлыктыргыч затлы тоткаларны
күпкә алдан каерып китәсең.

Ышкынмыймын бәхет ишегенә —
минем өчен ул да тоткасыз.
Заманында солдат зинданына
кереп чыктым, шөкер, тоткарсыз.

Кардәшедәй күреп каршыламый
дөнья йортындагы ишекләр.
Тәрәзәдән йөрмим тәреләнеп,
(үҗәтләргә андый тишек бар)...

Шагыйрьлектән килер шөгыленңдә,
ай-һай, туган, төштең төпкә син.
Ышанырмын: оҗмах ишегенең
йолкып кайтсаң сигез тоткасын.

## *Циркта туган фикер*

Авыз ачып торабыз да
кул чабабыз гөр итеп.
Нигә әле сокландыра
безне шундый примитив?

Могҗизага исәплибез
гап-гади һәм җай эшне.
Йә, әйт, нигә?
Әллә соң без
шулкадәрле наивмы?

Әйтүче юк: алкышларга
коена, дип, шул җан да...
Шаккатабыз икән аңа,
баксаң, хайван булганга.

## *Кызып киту*

Хаклысыңдыр: авыз ачсам,
әйе, үпкәм күренә.
Ә мин үзем сизмим монда
баш бетәрлек берни дә.

Куркынычның синдәгесе
дөрестән дә зур менә.
Тоймыйсыңмы: күңелеңнең
хәтта... төбе күренә.

## *Кычыткан тиз картая*

Әле каен җиләкләре
юньләп бөре ачмаган.
Ә кычыткан, тумас борын,
картая да башлаган.

Картлык тәмам бөрештерер
аны өч-дүрт атнадан.
Әле җәйнең шундый чагы:
миләш чәчәк атмаган...

Әллә соң ул үзен-үзе
яндырырлык үч йоткан?!

Чага алмый калам, диеп
картаядыр кычыткан.

# *Вакбашлар һәм башкалар*

(Киная)

Җылы сайлык.
ВАК БАЛЫКны моннан
чыгаралмый язгы ташкын да...
ВАК БӘРӘҢГЕ, сары чебеш кебек,
бутала гел аяк астында.

ВАКБАШ*ларны чәчеп үстермиләр —
басып китмәсеннәр җиреңне!..
Юк, алар да кирәк: булышсыннар
вактан аерырга эрене.

* Вакбаш — вак чәчәкле үсемлек.

## *Күңел киңлеге*

(Шифаханәдә никрут гаҗәпләнүе)

...Төгәл итеп үлчәгәчтен,
җорлык белән үртәлиләр:
«О! Буена карганда,
иңе тизрәк үсә»,— диләр.

Килограмм,
сантиметр...
Кан басымы,
күз күреме...

Әле хәтта саныйлардыр,
тәнендә, дип, ничә миң бар?
Ә йөрәкнең олылыгын
һәм киңлеген күңеленнең
нигә икән үлчәмиләр?!

## *Шик*

«Җир биттер син!..»

Шулай дидем бер бәндәгә,
ә соңыннан үкендем.
Юк, үземне битәрләмим:
телең бигрәк үткен, дип.

Хәсис затның йөзен ачкач,
күңелемә шик килде, —
болай әйтеп, Җирнең үзен
үпкәләттем шикелле.

## Умарта

Гелән чәчәк эзләп, имеш,
күз нурлары түгелми...
Тар казанда кайнап яшәү
шушы була түгелме?!

Канәгатьлек, ваемсызлык,
туклык чире йокканмы?!
Түшәмнәрен биегәйтим,
куып сорыкортларны!..

Чүп-чарлардан арындырыйм,
алыштырыйм һавасын...
Тынычлану-һәлакәттән
саклар хезмәт дәвасы.

...Мин аларга менә шулай
кылдым ихлас игелек.
Дөньябызны туздыра, дип,
шом салдылар иң элек...

Минем өчен кыйммәтлесе:
уяндылар!
Гамь белән!

Чаксалар да, агулары
шифа булсын тәнемә.

## *Белмәү бәласе*

Уйный белмәгәннәр уйлый алмый.
Шуыша белмәгәннәр оча алмый.
Көя белмәгәннәр сөя алмый.
Елый белмәгәннәр көлә алмый.
Үлә белмәгәннәр... туа алмый...

## *Көлү*

Гомер бакый тыеп тотты
тәнгә сыймас хөр җанын.
Хәтта аның авыз ачып
көлгән чагын күрмәдем.

Артык җитди, уйчан булды —
коеп куйган чын гарип*.
Әйтә иде: «Көлгән саен,
җитмеш шайтан чыгар»,— дип.

Көлми торсаң, яман көчләр
калыр читлек эчендә (?!)
...Шулчак иблис каршы төште
һәм белгертте үчен дә:
«Гарип затым, гарешеңә
шуны белеп бара бир —
баш сөягең, күккә карап,
көлеп ятыр барыбер...»

* Сирәк очрый торган кеше мәгънәсендә.

## *Татлы һәм ачы*

Ачынмыймын вакыт-вакыт
гомер ачы булганга.
Беләсездер: алма корты
ияләнми суганга...

* * *

Канат куеп үсендерде
һәрбере:
«Гомер итә белер бу,— дип, —
бигрәк тере...»

Канат куеп югалдылар
кайсы кая...

. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Язмыш ханым үзе дә ул,
ай-һай, чая!..

# *Туктап бер уйлану*

Әкрен кирәк, иплəп кирәк
Ишетергə сандугач
сайрауларын...
*Татар халык җырыннан*

«Әкрен кирәк...»
Ә бит дөнья куу —
шундый озын-озак марафон!
Бу заманда кеше бигрәк тә тиз
чабып үтә гомер арасын.

Кайчак хәтта узып китмәк булып
тәкъдир билгеләгән чик-көнне,
ашкынабыз соңгы сулышкача,
юнан сугышчысы шикелле.

Сокланмыйча былбыл сайравына,
дүңгәләк җан кая атлыга?
Менгәнебез, бәлки, карусельдә
ташбаканы узмас ат кына?!

Күзаллыймын... уйнак күләгәсен
куып чапкан садә угылны...
Без соң үз ялганы артыннан ук
йөгереп киткән Хуҗа түгелме?!

Кызулыйбыз — туктап торуларны
тыйган билге тора һәр юлда.
Калмабызмы галәм киңлегендә
дөрләп янган Фаэтон хәлендә?!

Картлар дәшә: «Арбаң тыяр өчен,
тәгәрмәчнең берсен бәйлә!» — дип.
...Үзен-үзе тота алмый торган
тезгенсез бер затка әйләнмик...

«Әкрен кирәк...»
Ә без җәһәтлибез,
алгысынып чаба аксак та.
Матәм маршын тыңлап бетерергә
вакыт табып булмый кайчакта.

«Чишмә башы»н күрә белмәс силдәй,
ыргылабыз нәрсә хакына?
Ашыгыч ярлык, ахры, Ванька Жуков
язган адресатсыз хат кына...

«Әкрен кирәк!..» диеп ялварадыр
бик еракта калган балачак.
Ярый ла без, теге юнан кебек,
җиңү сөенчесе алалсак!..

# *Хозыр галәйһис-сәламне эзләү*

(П о э м а)

«Пәйгамбәребез галәйһис-сәлам әйтте: бу тормыш — бер сәгатьлек, шунлыктан аны изге эшләргә файдалан!»

*Борынгы кабер ташыннан*

Минем җанкәм ялгыз башы —
Хозыр булсын юлдашы...

*Татар халык җырыннан*

## Бисмилла урынына

Беләсеңме, бәндәм, беләсеңме —
кемнән ятим калган бала без?
Арабызда үзен артыксынып,
юкка чыккан Хозыр бабабыз!

Денсезләнеп калган дөньялыкта
күптән күренгәне юк аның.
Юксынырбыз бер чал юлаучының
ярабызны килеп юганын.

Кыркапкадан инде кермәячәк
фәкыйрь кыяфәтле аксакал.
Искәртүләр генә исебездә:
«Букчасына, барып, акча сал...»

«Сәламләми үтмә сәләмәне —
Хозыр Ильяс була күрмәсен!»

Этләренә хәтле әйтелгәндер:
«Хәерчегә,— диеп,— өрмә син...»

...Ялварадыр Хозыр ярдәменә
гаҗиз кеше: «Очрар көннәр бир!..»
Күрмәгәнме изге көтүчене
Байлар Сабасында кемнәрдер?

Кермәгәнме Илбаш сараена? —
хәер, анда «кызыл погон» бар.
Кимсендереп торыр кыяфәтен
үзгәртмәде микән пәйгамбәр?!

Ялгышкандыр: миндәй ябагайга
ярашырлык ярлы юк, дисә.
(Хәерлегә булсын...) Хәерчелек
хәттин ашкан бездә югыйсә.

Кабатлады күпләр кабергәчә
«Иза вакыйгатин» сүрәсен.
Мөхтәрәмнәр хәтта мохтаҗланды —
шагыйрь Дәрдемәндтән сора син...

...Кая киткән, әзлик, кая киткән
Кол Галине күргән картыбыз?..
Борчылуны белмәс бәндәләрнең
бәгырендә бүген каты боз.

Бәлаләргә тарган балаларын
ничә чыгарышкан ак юлга!..
Мәңгелеккә барыр мөсафирның
югалуы сыймый акылга.

Күзебезгә ничек күренмәсен
үлми яши торган изге җан?!
Әбелхәят фани адәмнәргә
аны илче итеп иңдергән.

Яралардан типчеп яратылган
җанны кыйган чакта яманлык,
мәңгелекнең ярлы мөсафиры
япсын иде җылы ямаулык.

Кая киткән, эзлик, кая киткән
иман нуры чәчкән пәйгамбәр?
Сантыйларга кулын селтәгәнме:
«Монда,— диеп,— нинди файдам бар?!»

Кермәгәне өчен колхозына,
тиңләштереп корткыч кулакка,
Хозырыңны Совет хөкүмәте
әллә сөрде микән ГУЛАГка?!

Япканнардыр, бәлки, японнарның
шпионы, диеп, бу мажик?!
«Империя зла» исеменә
юкка гына лаек булмадык...

Яклаганы өчен яхшылыкны
«сары йорт»та башы чермиме?
Читлекләрен аның ачтыралмас
хәтта сабый чакның Сим-Симе.

Черетерләр яисә «Череккүл»дә,
бүтәнчәрәк фикер йөрт кенә.

Пенсиясез калган пәйгамбәрне
тыктылармы картлар йортына?!

Җәрәхәтле җаным җәһәннәмле
җирне инде ничә айкады.
Кешеләрдән бизгән күңелдәшең
күренмиме сиңа, Ай кызы?

Күрәсеңдер, күркем, күрәсеңдер
янындарак торгач Алланың.
Кешелекнең кысан күңеленә
син үзең дә сыя алмадың.

Илкәеңә сине иңдерергә
иртә әле, иртә, и җаным!..
Алыплардан тартып алганнардыр
иманасы белән ... иманын.

Имансызны берни имәндерми,
тотып көчләр иде ... Ай кызын.
Тормышларны күреп торасыңдыр —
сөйлим бугай сиңа артыгын...

Хәлифәләр хәтта хәсисләнде —
кая карый икән бу Алла?!
Партбилетлы «пөхтә» пәйгамбәрләр
бик күп бездә, бәгърем, буталма.

Иләсләрне изге иләмәнгә
әйләндерми калын каш кына...
...Парламенттан сорыйм пәйгамбәрне:
— Килеп чыкмадымы каршыңа?

Юлбарыстай халык югалганны...
Кемне генә борчыр бу маза?!
Сөргендәге Намус сурәтендә
пәйда булмаганмы БМОда?

Серләшергә садә сөргенчене
сыендырган мәллә Кар кеше?!
Куаладык картны... күңелләрдән,
кемгә төшәр аның каргышы?!

Җаныбыздан сөреп җаһилләрчә,
күпме көрәшкәнбез пәрмә-пәр.
Истәлегең булып исәннәргә,
чәчкәң* генә калыр, Пәйгамбәр...

**Беренче баб**

Акчәчәкләр итәгендә
изрәп йоклый иркә җил...
Төшләренә, тәшвишләтеп,
керә микән иргәҗел?

Кәүсәр сулы касәләрдән
ширбәт белән яшь ага.
Әлмисакта элгәрләрем
әверелгән ... чәчкәгә.

---

* Пәйгамбәр чәчәге (ромашка) күздә тотыла.

Каршысында карачкыдай
кеше-кара күренсә,
кяферләрнең карашыннан
күңеленә кер кунса,
иргәҗелем ирексездән,
әйе, гөлгә әйләнгән.
Ярый әле җанын җиргә
иңдерерлек җай калган.

...Ыругдашлар эргәсендә
эргәзембай чәчәге...
Күңелләрнең күләгәдән
күзсенерлек саф чагы!

Гөлстанда нинди генә
хәшәрәтләр яшәми!..
Чәчәкашар чирүенә
чәчәк ни дә, чәчән ни.

Ашамасмы яэҗүҗ-мәэҗүҗ,
хуҗаларча хуш күргәч,
милләтләрең мәңге-мәңге
«чәчәк атып» утыргач?!

Кеше сыман кыяфәттә
кечелекле көч иден;
иргәҗелем, җанкаеңны
нишләп гөлгә күчердең?

Дәверләрнең дәрвишедәй,
чәчәннәрчә дәш әле:
җиңелмени җиребездә
чәчәк булып яшәве?

Гаярьлектән гаҗизләнү
җиңел түгел һичкайчан.
Чәчәгеңне чәнечкеле
итмәгәнсең, ичмасам...

Әйтәсеңдер: «Әрем белән
тәрем булып...» — дип син дә.
Кычыткылы кычытканнар
үсә... чәчәк төбендә.

Иргәҗелгә иркә җилләр
сыенганда кич булып,
кисекбашлар очынгандай
итә, изге киселеп.

Сыртларына сурәтләнгән
адәм башы сөяге...
Иргәҗелем, исләремә
төштең инде син тагы!

Күбенешкән күбәләкләр
йөртә икән кем башын?!
Чалымнардан чамалыймын
кәрлә кавем көндәшен...

Чырайсызлар чирүенә
чыкмагансыз чәчрәп тә!..
Чәчәннәрең чәбәләнә
чәнчә чаклы чәчәктә.

Эргезембай эзәрләнә,
эзәрләнә әле дә.

Чәберчеккә «Чәбә!» диеп
булмый чәчәк хәлендә.

Дөресләнмәс дөньясына
иман нуры чәч, әйдә...
Элгәрләрем әверелә
алмас инде чәчәнгә.

Гөлдән — көлгә, гөлдән — көлгә —
язган шундый юл гына.
Иргәҗелем, ирексездән
калдың кемнәр кулына?

Кеше сыман кыяфәттә
кечелекле көч идең;
җәзаланган җан-тәнеңне
җәһәт гөлгә күчердең.

Күчендеме күңелеңнән
иң мөкатдәс хәзинә?..
Хозурында хыялыйдай
тору үзе хаҗ миңа.

Нәүрүзләрдә, нәүмизләнеп,
синнән саныйм ел башын.
Әлмисактан аерылмас
Хозыр булса юлдашың,
хакимлектән хәкыйрьлек*кә
хәтле төшәр идеңме?
Иргәҗелем, рәнҗетәмдер —
инде гафу ит мине.

---

* Хәкыйрьлек — буйсынучанлык.

Нәсыйхәтче нәбиебез
гаип әле үзе дә.
«Көтүче»не көтәләрдер
юкса хәзер йөз өйдә.

Күрәзәләр күрсәтешсә,
кайтыр идем яшь чакка!..
Юксылларның юлбашчысы,
һиҗрәт кылып чәчәккә,
кешелекнең качкынысыдай,
җанын асрап ятмыймы?

Денсезләнгән дөньясында
ят иде шул, ят иде...

**Икенче баб**

— Хозыр Ильяс камчы селтәр иде дә,
карлар-бозлар китә башлый Иделдә!.. —

Сөйли миңа күпне күргән Ак әби:
Бозлар белән серле саллар ага,— ди. —

Учак яна салмак йөзгән салларда;
берәү, икәү, өчәү — җитми саннар да...

Көн-төн яна Хозыр Ильяс учагы,
кыйбла якка карый салның оч ягы.

Саллар ага, димәк, илдә иминлек,
учак яна — әле илдә иман нык.

Салчы бабай укып кала салават:
«Кала саен, сала саен сәлам әйт!

Әһле ислам исән-имин Иделдә,
үзем генә агып төшәр идем дә...» —

Әби сүзе әзгә генә өзелә —
...Сәлам салын көтә-көтә көз килә.

Нәүмиз итеп, ничә нәүрүз үткәндер?!
Хозыр бабай, салың бәйләп, ут яндыр!

Камчың селтә, көтәм айның бишендә...
Җаным җайсыз, әллә ничек буш шунда.

Карлар-бозлар киткән саен бул ярда,
саллык сөян бардыр әле Болгарда.

Нәгъръә орып, саллар көтеп торганда,
сәлам салыр иде... Саламторхан да.

Салга сәҗдә кыла алмыйм, һай, күптән!
Хәбәр бирер рух бит үзең... гаиптән.

...Гариб затны гареп көтә — аваз юк;
акмый инде изге утлы намазлык.

Иман нурын имдәй эчкән хуш чагым!..
Хозыр Ильяс, җитми җанга учагың.

Инде синнән ничә нәүрүз сал алмыйм.
Хәлләр «изге» — иман бизде — чамалыйм.

## Өченче баб

Көтелмәстән, картлач, көтүеңдә
камчың төшкән, ай-һай, кыйммәткә!
Кыйссаларга кергән «кыланыш»ың —
хакмы-юкмы — хәзер кем әйтә?!

Кыйнагансың, имеш, көтүеңә
килеп кергән колхоз үгезен.
...Асылырга яисә атылырга
хөкем иткән Хозыр үз-үзен.

Җан-фәрманга чабып, җантимерләр
җәһәт килеп җиткән ГПУдан:
«Коммунистик нәсел калдырасы
үгез җәнапларын кем куган?»

...Читләшкәннәр бәет чыгарырга
«моның ише корбан» турында.
Залимнәрчә кыскан заманасы,
эчтән кабатланган ырым да:

*Кызыл болыт киләдер,*
*кызыл болыт астыннан*
*кызыл сыер киләдер;*
*мөгезе күккә терәлгән,*
*җилеме җиргә терәлгән;*
*бер имчәгеннән кан килә,*
*бер имчәгеннән май килә.*
*Шуны аша да шуны эч —*
*көтүчегә тимә,*
*кагылма!..*

Башлануын шулай башлангандыр
контр көтүченең кыйссасы.
«Корткычланган» рәсүл кыйссасының
бихисаптан күбрәк хисса*сы.

...Җыенының закон җыентыгы —
китап белән башын төйгәннәр.
Дәлилләүче
гамәл дәфтәренә
язып куйган фәлән-төгәннәр...

Бигөнаһны белми Бикчәнтәев,
йодрыкларын эшкә җигәдер.
Кушбугазның күпме кушаматы:
«Молотобоец», «Колун», «Живодер»...

Царизмны сагыныр Царевскийдан
күбрәк табадыр ул татымны:
«Беләсеңме, борчый, беләсеңме,
хәтта... кояштагы тап мине!..

Имгәтмичә генә иманыңны
куып чыгаралмам өч төндә.
Үтенечең булса, үтерермен
канлы намазлыгың өстендә...

Коммунаның корткыч көтүчесе
күреп калсын миннән игелек.
Әмма...
Мәслихәтче Себер мәсҗедләре
манарасын кисәр иң элек!..

---

* Язмыштагы башка аерым хәлләр мәгънәсендә.

Әҗәлеңнән әүвәл әҗәтеңне
түләп кую монда йоладыр.
...Үгезеннән гафу үтенмәсә,
Гайсә киткән җиргә юл алыр...»

«Тәңребезне инде тәкъдирләмәү
ихтыярың, илаһ хакимдар.
Инсаннарны хәләл иманыннан
аерырга кемнең хакы бар?!»

Алтатарлы сорау алучылар
алай артык авыз ачтырмый:
«Ачыкларбыз әле ачыкканда,
андый чакта бетләр ач тормый...»

Чиркәүләрдә*, имеш, чирләмәссең,
«Череккүл»дә алсаң чирканчык.
...Җәлладлардан җаның җәфаланса,
җәсәдеңә була җир тансык.

Имләүләрне белмәс имансызлык
имәнечрәк икән мең чирдән.
Алтатарлы сорау алучылар
күпкә мәкерлерәк Мөнкирдән.

Ипи-тозга алдап, иблислеген
чыгар гына — чыга нәҗес тә...

Әверелмәс адәм фәрештәгә,
әрекмәннән үсмәс кәбестә.

---

* Зиндан сыйфатында файдаланылган чиркәүләрне күзаллап әйтелә.

Имгәтелеп килгән иманыннан
иләмәннәр яза, яза ил.
Явызлыкны шулай аздырганда
асылына кайтмас Газазил.

Куркытылган күндәм күңелләргә
илаһ нуры үтми — көбәле.
Ачынулы җаннар ачыкканда,
сиңа, Иблис, ипи күп әле.

**Дүртенче баб**

Имансызлык коммунасы
була икән катилле.
Шәһитләрнең шәһадәте:
намус җаннан кадерле.

Колымада калымлыга
казыйлардыр каберне.
Шәһитләрнең шәһадәте:
намус җаннан кадерле.

Мондый мәхшәр булмагандыр
Октябрьгә кадәрле.
Шәһитләрнең шәһадәте:
намус җаннан кадерле.

Консыз-кансыз катилләрнең
күпме сүзе «контр»лы.
Шәһитләрнең шәһадәте:
намус җаннан кадерле.

Казаматлы каза килә,
Иблис итсә казыйлык.
Шәһитләрнең шәһадәте:
намус җаннан кадерле.

Белә җиһан җанны болай
күпләп кырган кай илне?!
Шәһитләрнең шәһадәте:
намус җаннан кадерле.

Туганнарым — тузаннарым,
Сезгә — Киек Каз Юлы...
Шәһитләрнең шәһадәте:
намус җаннан кадерле.

Сөмсез дөнья, денсез дөнья,
күлмәкләрең, һай, керле.
Шәһитләрнең шәһадәте:
намус җаннан кадерле!..

## Бишенче баб

Күгәрекле сырхау күңелләргә
Өммелхәер* йөри им көйләп.
Бәлаләрдән чыккан балаларын
сайлап ашый тора инкыйлаб.

Көпә-көндез әкият сөйләүчене
тотып ашый икән Ак бүре...

---

* Өммелхәер — изгелек анасы.

Әүлиядай чынын әйтүләрнең
нигә ачы була ахыры?!

Бүтәннәре белән буташтырмыйк —
изге бүре шуңа базамы?
Исәнгерәү итәр имансызлык
ашагандыр җиде бажаны.

Болгатасың, диеп, булмастайны,
килешмичә, кемдер йөз чыта.
Абызкаем, бүре авызына
эләкмәгән «артык» Йосыф та.

Балаларын ашый большевизм —
аңышмыйча тора Ак бүре.
«Кызылларча» яза казаматта
Мөнкирләрнең канлы акбуры...

Кассапчысы һәйбәт кәсепләнә,
кыяфәте шундый җиңүле!..
Алыпларын сайлый халыкларның —
Рәсәеңнең киңдер җен юлы.

Лагерьдагы дегет лагунына
ләгыйньлеккә юлны ач кына...
Сөннәтенчә булми сөякләрне —
барсын уртак тәре астына!

Пайтәхеттә соңгы пәйгамбәрне
фида итәр фәрман язсалар,
өметсезне имләр Өммелхәер
бөтенләйгә безне ят санар.

**Алтынчы баб**

Гасабилан, кассап, гасабилан,
Корбан бәйрәмендә ит төтми.
Тыяргадыр бала төшерүне —
хатын-кызлар бер дә интекми.

Каруланган «кызлар» карыныннан
күпме җаннар китте гарешкә.
Кичекмәстән киртә куелачак
гөнаһ булган мондый гарь эшкә.

Бишьеллыкта тума бирмиенчә,
гыйш-гашрәттә яшәп яталар.
Йөкләмәләр биреп йоклатырга,
тулгаклаудан туймас зат алар.

Корбан кирәк — йола — корбан кирәк,
җиде көнлек балаң булуга.
...Гаиләсенең үтәп гакыйкасын,
атакае барыр бу юлга...

Кысмырланма, кассап, кысмырланма,
киләчәккә карап эшлә син.
Мыскыллама тоткын мөслимәне —
көмәненә кадәм төшмәсен.

Өлешеннән калмас Өммелхәер —
түшәгеннән төшми... түл җыйсын.
Онытмастыр олуг атабызга
балалата ясак түлисен.

## Җиденче баб

Богауларга түзгән болгарларны
сөрдең, гәүр, аттың, астың да...
Күнеккәндер инде көн күрмешкә
культларының култык астында.

Казаныңны Иван казаматка
әйләндергәч, якты көн нигә?
Карышмасаң Рәсәй карынында,
караңгыга күзләр күнегә.

Мәхлуклашып беткән мәхрүмнәргә
күлмәк кебек якын таш капчык.
Түрәләрсез бер көн торалмагач,
ничек инде шуны ташлап чык?!

Әлмисакта әллә алыпларга
җәбер-золым җене кагылган?!
Өзәңгегә күнгән өзгәләнми:
дөнья бара, диеп, кай юлдан!

Коллыгына күнәр колонистның,
түзәр... ирлегендә ир юкка;
ияләләр авыр ияләшә
кисәк кенә килгән иреккә.

Өзәләнеп тормый үзиреккә —
канга сеңеп калган мәхрүмлек.
Төрмәләрдә черетү тәҗрибәсе...
О, бу эштә бездәй маһир юк!

Хаталыктан хали халыкларны
читлекләргә тыгып илә дә...
«Империя зла» исеменең
исе озак яшәр илләрдә.

Инсаният әле интегәчәк
оныталмыйча мондый «зур ат»ны.
Күзләрендә йөртер Хозырыбыз,
мәңге йөртер канлы сурәтне.

Төрле-төрле Рәсәй төрмәләре
туганнарның булсын төрбәсе.
Тәрҗемәи хәлен төрмәләрдә
үткәргәнгә килер түр башы,
килми калмас...

**Сигезенче баб**

Үлә-үлә, үлә-үлә,
үтелгәндер бар этап...
Хозырыбыз хәзергәчә
пәйда булмый —
«Пәри, тап!»

...Кәрәкәшле карьясеннән
күргән аны Нәсихә;
пәйгамбәрне ашамаган
канга туймас ач юха!..

Буташтырган, буташтырган
башны бөек болганыш.
«Танышыбыз» Танайдагы
Шиһабетдин булган ич.

Көтүлеккә «катафалк»
килеп киткән ул көзне...
Үтергәннәр — үгисеткәч
коммунистик үгезне.

Әбелхәят аермасын
мәңге яшәр шаһиттан...
Нәсихәбез пәйгамбәрне
кырда күреп «аһ» иткән!

Әйтәсездер: әкиятне
безгә сөйләп торма да.
Ышанмаган — ышанмасын —
бу хәл булган тырмада.

Нәсихәнең нәрсәдәндер
дулап киткән тайлары.
Буып алган дилбегәне
ычкындырыр җай бармы?!

Бригадирга, боргаланмый,
барган иде эш сорап...
Инде менә «кырыкмыш»ы
китте кырдан өстерәп.

Тиле тайның тарпан* төсле
тыелмастай җен чагы!
Сызландырып сыдырыла
кызның калкым имчәге.

---

* Т а р п а н — кыр аты.

Тырмаларны тыркылдатып
томырыла — түз генә.
Ташлы төштән сөйрәлгәндә,
ай-яй, авыр тезенә!

Кыза кызый, кыза кызый:
«Кулым гына таймасын...»
Кинәт кемдер килеп тота
тыелгысыз тай башын.

Җөрьәтләнеп, җиргә җәһәт
төрткәч яшел таягын,
ошбу дәрвиш, дәшми-тынмый,
сыйпап куя тай ялын.

Нәүмизләнгән Нәсихәбез
шундый изге йөз күрә!
Нәсыйхәте — насыйбыдыр —
күңеленә йөгерә...

«Күрәчәгең күлмәкләрен
күңелеңдә ю, бала!..»

Кырда картлач кинәт калкып,
кинәт күздән югала.

**Тугызынчы баб**

Касыйдәләр ява кассапчыга,
кәфенлеге кызыл бәрхеттән...
Әлмисакта, адәм, Илаһыбыз
сине оеш каннан бар иткән.

Октябрьнең таңын аттырганнар,
бастырылып, озы-ын төн чыкты.
Хак Тәгаләм, каннан яратылган
күпме кешең канда тончыкты!

Җантимерләр итлек җыйнаштырды,
капылт кына менеп болдырдан...
Илаһыбыз, имеш, инсанына
Ата яратканда «Бул!» дигән.

Большевизм затлы балыкларны
байтак тотты, дөнья болгатып.
«Хәлифәләр» хәләл халыкларны*
һәлакәткә илтте «Булма!» дип...

...Кассапчының хәле кәйләнүгә,
мордар китеп барыр алдыннан,
ыругдашлар ихлас ыргылышты:
«Каным бирәм, Аллам, ал миннән!»

«Икеләнми, икмәк, икеләнми,
йөрәгемне әзер бирергә!»
«Бөеремне бирәм боерсалар —
дөнья кимер, әйдә, бер иргә...»

Иләмәнгә, имеш, ияләшкән
илдәшләрне бизәр билге бу...
Кешеләрне колдай кешәнләгән
«Бардыр — бердер!» диеп бил бөгү.

---

* Совет хакимияте елларында дистәгә якын халыкның юкка чыгуына ишарә.

Лəгыйньчəлек илне ләббәйкәгә
әйләндереп куйган лабаса.
Куркытылган күндәм күңелләрне
гаҗәпмени һаман ләм басса.

...Кассапчының кәүсәр касәсендә
каннар канга кат-кат катышты.
Махмырлаткан мәхшәр мәкереме —
имсез хаста иртән кан косты.

Күзәттеңме, Хозыр, күзәттеңме,
күргәнсеңдер син дә, Ай кызы:
кәсебеннән мәхрүм кассапчының
канлы килеш калды авызы...

**Унынчы баб**

Тәкъдирендә адәм тәганәсе
нинди генә хәлгә тап булмый!
Кассапчының табут капкачына
кагар өчен... кадак табылмый (?!)

Пәйгамбәрне, әнә, пәйгамбәрне
кадаклаган чакта табылган.
Казаматлар кору казанышын
яулаганда байлык тау булган...

Искәрткәләп тора исәрлекләр
иманлыга илдә сан югын.
Кадаклаган кансыз кадимилек
Таһир белән Зөһрә сандыгын.

Табутына йозак табылмаса,
казаларың кайтыр — көт кире.

Кадак кайда, казна, кадак кайда,
кадак?.. Кадалышып киткере!

(Имансызны инде имәндермәс
«катыкул»ы кире кайтса да.)
Казачының үзен кадакларлык
кадак кына бардыр Гайсада...

Югалышып калмыйк, юксылларым,
көннәр кичеп кадак очында.
«Атакай»га берне арттырыгыз
кадакланган телләр өчен дә.

«Казаларың» өчен казаматка
«кыстырылган» кырыс Былтырым,
ярыкларын капла, ярыкларын,
өркемичә укып бер ырым.

Табындырган затка табылырмы
табу сала торган табутлар?!
Бәгырендә ята бәндәләрнең
бәхилләшә белмәс таш потлар.

Табындырган затның табутына
сыяр иде илаһ азгын да.
«Катыкул»ның күпме катилләре
атылгандыр «ата» алдында...

Эләкмичә итче элмәгенә,
Иблис ибен тапкан анда да.
...Кадакларым юк, дип, казыйларны,
әйдә, казна, әйдә алдала...

Уянмасын өчен уҗарлыгы,
җирәндереп хәтта... җир өен,
җырлашырга кала җыйнаулашып
бәддогалы бишек җыруын.

## Унберенче баб

*Әлли-бәлли итәр бу,*
*Әмеренә китәр бу;*
*каргышларда кыйналып,*
*кыяматкә җитәр бу.*

*Араларны өз инде,*
*бүтән ачма күзеңне;*
*төкәндерден тәмамән*
*түбәләмә түземне.*

*...Халык үлеп йоклады,*
*кулы кулга йокмады;*
*«татлы-тәмле» өенендә*
*аздан ... телен йотмады.*

*Йокламыйдыр өрәгең,*
*кавемеңә кирәк син;*
*күпләр, казып алырга,*
*кайрап тора көрәген.*

*Һәркем туган телендә*
*каргый: «...Кабат терелмә!»*
*Үҗәтләнеп уянсаң,*
*Хозыр йоклар ... тегендә.*

**Уникенче баб**

Сусаганмын Хозыр сурәтенә —
күпме күздән эзләп карадым.
Билгесезлек арты билгесезлек
алып килә миңа һәр адым.

Нәсыйхәте истә Нәсихәнең:
«Шәрифлекне күздән шәйлә син...»
«Чалдон»*нарда әүвәл чалымлыймын
шомландыргыч шәфәкъ шәүләсен.

Күпмесендә, Кадир, күпмесендә,
күпмесендә күрмим... сер затын!..
Юксыллыкта кан-яшь югандырмы
күзләрдәге Хозыр сурәтен?!

Изаланган җанда изгелеккә
урын бармы, Аллам — чамала...
Телебездән гөл-бал тамызганда,
күңелләрдә кайный... сумала.

Күңелләрнең төбе күренмәле,
маңгай күзе — ботак тишеге...
Китерсәләр, канлы күлмәгенә
сәҗдә кылыр идем, һич югы.

Тәүбә, тәүбә, тәүбә, тәүбә, тәүбә —
сөйлим бугай сезгә көфер сүз.
Вөҗүденә сыймас вөҗданыбыз
гомер кичерәдер көфүсез**.

---

* Чалдон — Себергә сөрелгәннәрне халыкчарак атау.
** Җисмани тиндәшсезлек мәгънәсендә.

**Унөченче баб**

Каргагансың карьяләрне,
Хозыр хәзрәт, һай, ачы:
«Алтмыш өйле Көтернәсең
алты өйгә калсачы!..»

Каргагансың, күрсәтмәгәч
мөсафирга миһербан...
Авылларда алынмады
инде ничә мең корбан!

Салаларны Себеренә
сөрмәдеме советлар?!
Раслагандыр ристаннарың:
илдә... ике Сәет бар.

Рәсмиятле Рәсәебез
белә ничә Сөн барын.
Күпме авыл төштә күрә
Себердәге сыңарын...

*...Яңавыл,*
*Кушкүл,*
*Тугыз,*
*Турай,*
*Ушмы...*

Башкарактыр, башкарактыр
«катр»дагы Көтернәс.
Мөсафирны мәсхәрәләп,
анда әнчек эт өрмәс.

Бормыйлардыр — бирмиенчә
хәерчегә ямаулык...
Каргалмаган карьяләрнең
күпмесендә иман юк!

Сакны — Соктан, Сокны — Сактан
аерырга сүз җиткән.
Айлап-еллап аерганнар
вөҗданыңны вөҗүдтән.

Тәхеттәге «теләнчеләр»
талап алган барсын да.
Кара көйгән баганалар
гына авыл башында.

Тарханнарны тираныбыз
таркаткандыр иң элек.
Карьяләрне каргышлавың
ышандырмый, ИЗГЕЛЕК!

## Ундүртенче баб

Өммелхәер анабызны өнәмичә,
санламыйча «сары йорт»ка сөргәндә,
хәкимнәрнең хикәятен хәтерләдем:
КАРТка киңәш сорап килгән бер бәндә...

## Киңәш сораучы

Балачакта, билләһидер, белмәгәнмен,
Ана хакы биниһая зур икән!
Инде нишлим, Нәсыйхәтчем, инде нишлим —
киңәшеңә күңел-калебем зарыккан.

Болайлыгын белгән булса балакае,
йөртер иде иңбашына утыртып...
Атам вафат. Анам гарип. Үзем буйдак.
Ничә еллар яшим инде ут йотып.

Чәбәләнер чәчкәйләрен, читенсенми,
гомеремдә инде ничә кат тарыйм.
Кушучымда тәгам-тәбә куырыйммы —
Ана хакын ничек итеп кайтарыйм?!

Аяклана алмавының аянычын
әманәттәй әйтте әни, ачылып:
«Карусызым! Карыйлыкка карамыйча,
барып кына кайтыр идем хаҗ кылып...»

Кышның кече кырлачында китkәнлектән,
карурманнар кичтем, көн-төн көрт ярып;
чайкалмыйча чүллекләрне чакрымладым,
инәемне иңбашыма күтәреп...

Әүлиядай әнекәем әйдәкләсә,
әлхәрәйгә әйләнергә әзер мин.
Биргәнмендер, бабакаем, биргәнмендер
игелекнең икеләтә әҗерен?!

**Пәйгамбәр**

Барсын беләм, балакаем, барсын беләм —
көенечең күңелеңне тырныйдыр.
Вәләкин...
Тормыштагы бөтен, бөтен тырышлыклар
Табучының ... тулгагына тормыйдыр,
тул-га-гы-на тормыйдыр...

## Нәтиҗәсез эзләү соңында

...Куркытасың күптән күренмичә —
хикәяткә «һиҗрәт» кылдыңмы?!
Хозурыңа, Хозыр, хәзерләнәм,
Көтернәскә кабат кил инде!

Хәйранланма, хәзрәт — хәерчене
хәлле халык һаман яратмый.
Иманнарын Иблис имгәткәндер,
ярлыкасаң иде, йа Рабби!..

Күңелләрнең төбе күренмәле —
карьяләргә кереп, калдыр им.
Вөҗданнарын хәләл вөҗүденә
кире кайтарсаңчы, Кадирем...

Көрсенәсең бугай Коръәнеңә:
«Минем монда нинди файдам бар...»
...Кыяматтә генә күрешергә
язган мәллә безгә, пәйгамбәр?!

Тупсалардан сөрдек «теләнче»не,
сөмсез сүзебезне йөз әйтеп:
«Күренәсе булма күзләремә,
кит, кит, бабай, йөрмә йөдәтеп!..»

Тукышулар һаман тукталмыйдыр —
тагын нинди кансыз чорда без?
Ярдәмчесез япь-яшь ятимәне
көн дә, көн дә Айга сөрәбез.

Бәддогадан түбән бәндәләрнең
көн дә корбан сорый вак җаны.

Бүртенешкән бүтән бүреләргә
ашатабыз җиде баҗаны.

Алыпларны, Аллам, алыпларны
кара кабергәчә кем ега?
Йомыкыйлар изге Йосыфыңны
көн дә ыргыталар коега.

Зобанилык Таһир-Зөһрәләрне
тора һаман суга ташлатып.
Күңелләрдән көн дә куалыйбыз
Хозырильяслыкны... таш атып.

Изгелекле Ата эзләренә
өммәтсезлек көн дә көл сибә...
Пакьләндергеч Хозыр пәйгамбәрнең
ясинчысы
яши
кешедә.

## *Автор турында кыскача белешмә*



Зиннур Мөҗип улы Мансуров 1949 елның 15 июлендә Татарстанның Мамадыш районы Түбән Ушмы авылында туган. Урта мәктәпне тәмамлап, бер ел чамасы күмәк хуҗалыкта механизатор булып эшләгәч, 1967 елда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына укырга керә. Татар теле һәм әдәбияты бүлегендә югары белем алганнан соң, офицер буларак, ике ел армия сафларында хезмәт итә. Аннары «Социалистик Татарстан» газетасы (1974 — 1983), «Казан утлары» журналының (1983 — 1986) әдәби хезмәткәре, Татарстан радиосының баш редакторы (1986 — 1990), Язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары (1990 — 1995) булып эшли. Ә 1995 елда, Татарстан Министрлар Кабинеты карары нигезендә, «Мәдәни җомга» атналык әдәбият һәм сәнгать газетасын оештыра, шушы басманың баш редакторы вазифасын башкара.

Шагыйрь Зиннур Мансуров — Казан һәм Мәскәү нәшриятларында басылып чыккан күп кенә китаплар авторы. Алар арасында балалар өчен язылганнары да бар. Шулай ук әдәби тәнкыйть, публицистика, эссе жанрларында да уңышлы эшләп килә. Үзенең мәкаләләрендә милли сәнгать дөньясының көнүзәк проблемаларын да кыю күтәрә. Поэмалары буенча телерадиоспектакльләр эшләнгән. Кайбер шигырьләре композиторлар тарафыннан көйгә салынган. Аерым әсәрләре, рус теленнән тыш, инглиз, поляк, төрек, казак, кыргыз, төркмән, үзбәк, белорус, украин, латыш, эстон һ.б. телләргә тәрҗемә ителгән. Аның «Душицы белый запах» (1991) һәм «Күңел сәфәре» (1999) исемле шигъри җыентыклары Татарстан Милли китапханәсе Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы белән берлектә үткәргән конкурста елның иң укылышлы китаплары исемлегенә кертелде, шулай ук ул «Литературная Россия» атналык газетасының махсус бүләгенә лаек булды (1992), төрки телле илләр шагыйрьләренең Төркиядә уздырылган III Халыкара очрашуында (2002) катнашып, диплом алды.

Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге хезмәтләре өчен Зиннур Мансуровка 1994 елда Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелде.

## *Эчтәлек*

Чәркәдәге чәнечке . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5

**I бүлек**

Аллаһ бүләге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 9
Чистару . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 11
Йөз суы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 12
Дүнү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
Гарештән иңгән кызгану . . . . . . . . . . . . . 14
Тартар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 15
Киек Каз Юлы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 16
Рояльнең кара телләре . . . . . . . . . . . . . . 17
Баш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 18
Чаң . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 19
Екатерина II каретасы . . . . . . . . . . . . . . 20
Илбакча һәм колонист . . . . . . . . . . . . . . . 22
Ай кызына төбәлгән уй . . . . . . . . . . . . . . 23
Һиҗрәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 25
Фәрештәгә әверелү . . . . . . . . . . . . . . . . 27
Ачык рояль . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 28
Төрмә эчендәге читлек . . . . . . . . . . . . . . 29
Кош очар биеклек . . . . . . . . . . . . . . . . . 32
Ике еглау *(Поэма)* . . . . . . . . . . . . . . . 33

**II бүлек**

«Хәтер — уяу...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 75
Сөт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 76
Сызлаулы хәтерне яңарту . . . . . . . . . . . . . 77
Иске Казан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 78
Савыт-саба ватыклары . . . . . . . . . . . . . . . 80
Беренче киселгән ярымай . . . . . . . . . . . . . 81
Татар бугазы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 82
Җыр тәлинкәсен юу . . . . . . . . . . . . . . . . 84
Венера планетасының топонимиясенә кереш . . . . . 85
Борынгы хәрабәләр янында . . . . . . . . . . . . 86
Бульдозерга һәйкәл . . . . . . . . . . . . . . . . 87

Бер сөйләшүдән соң уйлану . . . 88
Иске арба . . . 89
Билгесез рәссам . . . 90
Тәмамланмаган сын . . . 91
Шулай да уйлап куясың... . . . 92
Сүз . . . 93
Хөкемдар . . . 94
Күңел гамәле . . . 95
Туңу. Тукай . . . 98
XX гасырның унөч елы . . . 99
Шагыйрь янәшәсендәге урын . . . 100
Бурыч . . . 101
Сәйдәш ялгышы *(Баллада)* . . . 102
Соңгы сәхнәгә бару . . . 104
Оркестр чокыры . . . 107
Толстой үлгән станциядә . . . 109
Сәер карт . . . 110
Аксакал . . . 111
«Бу фасылда кемгә көз килгәндер...» . . . 112
Йолдызларны йолдыз яктырта . . . 113
Маяклар да адаша . . . 114
Иске тегермән: ат, таш... . . . 115
Ат егу . . . 116
Ефәк тасма . . . 117
Картлык галәмәте . . . 118
Игезәкләр . . . 119
Чәч алу . . . 120
Тәкрарлау . . . 121
Сугышта үлгән дингезчене юксыну . . . 122
Яптылар һәм ачтылар . . . 123
Фидаилык . . . 124
Кызыл балчык . . . 125
Чаң какмагыз әле!.. . . . 126
Иң кыены... . . . 127
Балкыш, яки Хәйретдин Мөҗәйнең сугыш язмаларыннан юллар *(Поэма-рулада)* . . . 128

**III бүлек**

Яшьлек кайтавазы . . . 153
И балачак... . . . 154
Болын чәчәкләре арасында . . . 155

Җир тәме . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 156
Көнгә шөкер кылу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 157
Хәтернең бер хәтерсезлеге . . . . . . . . . . . . . . . 158
Ияр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 159
Башка уй төшү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 160
Ут-малай ат тышаулый . . . . . . . . . . . . . . . . . 161
Көндәшлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 162
Ышаныч . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 163
Ут эчүче ат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 164
Сабан туеның икенче батыры . . . . . . . . . . . . . 165
Югалмаска! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 166
Мәтрүшкә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 167
Пирамида . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 169
Аламачы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 172
Иделгә карап хәтер яңарту . . . . . . . . . . . . . . 173
Чынлап «качышлы» уйнау . . . . . . . . . . . . . . . 174
Күз яшьләре төссез . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 175
Елмаюлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 176
«Оя-оя кошлар китә...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 177
Йөрәкнең очынуы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 178
Туган йортта . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 179
Түшәм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 181
Кайту . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 182
Мөһаҗирләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 183
Күченеп кайт, диючеләргә . . . . . . . . . . . . . . . 184
Авыл карчыклары чәй эчә . . . . . . . . . . . . . . . 185
Баз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 186
Чалгы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 187
Өй күтәргәндә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 188
Көшел өстендәге көрәк . . . . . . . . . . . . . . . . . 189
Мичче . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 190
Сандал . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 191
Көтүчесез авылда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 192
Өзелгән әңгәмә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 194
Балачак эзләреннән йөргәндә . . . . . . . . . . . . . 195
Керәшәле ярлар яныннан үткәндә... . . . . . . . . . 196
Авыл урыны . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 197
Ауган арыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 198
Фанилык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 199
Бер төнлек күбәләкне юату . . . . . . . . . . . . . . 200
Яшәүчәнлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 201

Күңелдәге тартышу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 202
Шаһитлык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 203
Исерек бал кортлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . 204
Идел төбендәге чишмә . . . . . . . . . . . . . . . . . 206
Искәртү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 207
Күзге кичтә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 208
Оя . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 209
Оча алмыйча калу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 210
Казлар авазы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 211
Соңгы акчарлакны озату . . . . . . . . . . . . . . . 212
Юану . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 213
Ак буран . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 214
Алатаудагы кар бөртекләре . . . . . . . . . . . . . . 215
«Ыргый ташкын...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 216
Бөреләр ачылганда уйлану . . . . . . . . . . . . . . 217
Аклык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 218
Тау астындагы чишмә югалгач . . . . . . . . . . . . 219
Меңьяфрак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 220
Нишләрбез?.. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 222
Эт җиләге. Ат кузгалагы... . . . . . . . . . . . . . . 223
Илен сагынучы дөя . . . . . . . . . . . . . . . . . . 224
Балык кычкыруы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 225
Ат ату . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 226
Чалымлау . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 227
Тары чәчәге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 228
Табигатькә бер үпкә . . . . . . . . . . . . . . . . . . 229
Ромашкино ромашкасы . . . . . . . . . . . . . . . . 230
Кайтавазсыз урманда . . . . . . . . . . . . . . . . . 231
Ятим Су анасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 232
Җиләк бердән җыела . . . . . . . . . . . . . . . . . 233
... белән... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 234
Җир җимертеп яшәү . . . . . . . . . . . . . . . . . . 235
Ярымшарлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 236

**IV бүлек**

Иртәләү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 239
«Карабодай басулары...» . . . . . . . . . . . . . . . 240
Август төне . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 241
Кич. Дәрья *(Рәсем)* . . . . . . . . . . . . . . . . . 242
Төнге диңгез ярында . . . . . . . . . . . . . . . . . 253
Тынычлану . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 244

Ерак сәяхәткә чыгу . . . 245
Йөгән күзлеге . . . 246
«Бәйләнчек җил төсле...» . . . 247
Илаһи күк дәфтәре . . . 248
Суга салынган уйлар . . . 249
«Хәзергә...» . . . 250
Кояш чыгъшы . . . 251
«Өз, гитара!..» . . . 252
Әйтешү . . . 253
Чигү . . . 254
«Бик дуамал тай да тора-бара...» . . . 255
Үксезлек . . . 256
Сер . . . 257
Күзләреңә карап уйланганда . . . 258
Үземә дә кадерле . . . 259
«Күзләреңнең тирәнлеген...» . . . 260
Сердәшлек . . . 261
Берлекне тою мизгеле . . . 262
Диңгез буендагы кыз . . . 263
Соңлаган фәрештә . . . 264
«Кыз куу» . . . 265
Төнлә су кергәндә . . . 266
Үзебез булып калыйк . . . 267
«Болын көтә сине...» . . . 269
Табышу . . . 270
Җиңел сөю сорама . . . 271
«Кар илендә каеннар да...» . . . 272
Илаһи яшен язуы . . . 273
Синең авылыңа кайту . . . 274
Килен булып төшкәч . . . 275
Үтәли караш . . . 276
Халәт . . . 277
«Каты күзлесеннән сакланам, дип...» . . . 278
Шигърият алиһәсе . . . 279
Вакыт агышы . . . 280
Кайчак . . . 283
Ачы тәҗрибә ачышы . . . 284
«Арабызда тау булса да...» . . . 285
Сиңа җибәрелмәгән хатлар . . . 286
Каен арасыннан эзлим . . . 289
Сихерләнү . . . 290

Җиләк кагы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 291
Нәрсә булды безгә? . . . . . . . . . . . . . . . . . . 292
Иртә килгән кыш, яки аккош күләгәсе . . . . . . . . 293
Хәтер . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 294
Энә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 295
Сөюнең ачы хакыйкате . . . . . . . . . . . . . . . . 296
Эзәрлекләнү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 297
Иртә кар яугач . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 298
Үлән арасындагы таш . . . . . . . . . . . . . . . . . 299
Беренче... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 300
Яшерен сагыну . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 301
Әй... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 302
Күктә очрашу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 303
Бер туйда килгән уй . . . . . . . . . . . . . . . . . 304
Җиләк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 305
Яшәүнең бер хикмәте *(Хикәят)* . . . . . . . . . . . 306
Сатыш кызы Инҗилә . . . . . . . . . . . . . . . . . . 308
Могҗиза . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 310
Сулкылдау . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 311
«Таң җиледәй кагыласы килә...» . . . . . . . . . . . 312
Дәвам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 313
Әнкәй хатларын укыганда . . . . . . . . . . . . . . . 314
«Кул астыңа шәфәкъ агып кергән...» . . . . . . . . . 315
Санау догасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 316
«Адым саен хатирәләр...» . . . . . . . . . . . . . . 317
Туй күлмәге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 318
Миләш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 319
Сабан туенда чүлмәк вату . . . . . . . . . . . . . . 320
Капка . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 321
Җомга көн күк катында . . . . . . . . . . . . . . . . 323
Үрмә гөл җебе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 324

**V бүлек**

Замана кайтавазы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 327
«Эш җаваплы...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 328
Егылу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 329
«Кем сукты?» уены . . . . . . . . . . . . . . . . . . 331
Күңелне тынычландыру . . . . . . . . . . . . . . . . 333
Чиге күренмәгән юану . . . . . . . . . . . . . . . . . 334
Балта ашы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 335
Сәнәк белән язу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 336

Энциклопедия актарганда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 337
Гадәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 339
Коткару . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 340
Тәкъдир искәртүе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 341
Гаҗизләнү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 342
Сыналган шайтан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 343
Татарлык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 344
Бүре чакыру . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 345
Аерымлык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 346
Кемчә яши? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 347
Карга . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 348
Кешеләрдәй төрле күбәләкләр . . . . . . . . . . . . . . 350
Шайтан шамакае . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 351
«Гаип»тән хәбәр бирүче . . . . . . . . . . . . . . . . . 353
Аерымлык билгесе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 354
Тавык тәпие . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 355
Хуҗасына охшаш бакча карачкысы . . . . . . . . . . . 356
Әйләнмә урындык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 357
Өстәмә сыер . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 359
Катыктан акча эзләү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 360
«Алыштыргысыз син!..» . . . . . . . . . . . . . . . . . 361
Ялланып елаучы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 362
«Өлкәннәр ямьсез елый...» . . . . . . . . . . . . . . . 364
Бәдәл . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 365
Алай-болай . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 366
Үкенечле ләйсән яңгыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . 367
Дәһрилек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 368
Тагын «урысныкы» турында . . . . . . . . . . . . . . . 369
Айга менүчеләргә үпкә . . . . . . . . . . . . . . . . . . 370
Тамаша . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 371
Ретро (?!) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 372
Иртәнге өч кызгану . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 373
Кырым комлыгындагы ханым . . . . . . . . . . . . . . 374
Кавын сатучы хатын . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 375
Җиргә яңадан кайту . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 377
«Мәҗлесләрдә тост әйтәбез...» . . . . . . . . . . . . . 378
Мәңгелек бусагасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 379
«Төзәтелгән ... нче басма» . . . . . . . . . . . . . . . 380
Соңгы киңәш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 381
Яшәү белән үлем арасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . 382
«Нигә ул каласы казларга?!» . . . . . . . . . . . . . . 383

Таш оча... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 384
Ком юу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 385
Бәхәс . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 386
Дөньядан китү сәбәбе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 387
Сурәткә төшү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 388
Җаваплылык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 389
Үкенеч . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 390
Үлеп булмау халәте . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 391
Танк һәм танка . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 392
Ишек тоткасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 393
Циркта туган фикер . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 395
Кызып китү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 396
Кычыткан тиз картая . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 397
Вакбашлар һәм башкалар . . . . . . . . . . . . . . . . . 398
Күңел киңлеге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 399
Шик . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 400
Умарта . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 401
Белмәү бәласе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 402
Көлү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 403
Татлы һәм ачы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 404
«Канат куеп үсендерде...» . . . . . . . . . . . . . . . . 405
Туктап бер уйлану . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 406
Хозыр галәйһис-сәламне эзләү *(Поэма)* . . . . . . . . . 408

Автор турында кыскача белешмә . . . . . . . . . . . . . 439

Литературно-художественное издание

*Зиннур Мансуров*
*(Мансуров Зиннур Музипович)*

**ТЕПЛЕЕ ГРЕЕТ РАНЕНОЕ СЕРДЦЕ**

*Стихи и поэмы*

(на татарском языке)

Мөхәррире *Х.Г.Әюпов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Рәссамы *Р.Х.Хәсәншин*
Китапта *Хәмит Латыйп* рәсемнәре файдаланылды
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *А.С.Газизҗанова*
Корректорлары *Г.Г.Гарифуллина, С.Н.Мифтахова*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия
2001 елның 6 мартында бирелгән.
Оригинал-макеттан басарга кул куелды 18.03.2003.
Форматы 70×108$^{1}/_{32}$. 65 гр. офсет кәгазе. «Т.Балтика» гарнитурасы.
Офсет басма. Шартлы басма табагы 19,60+форз. 0,18.
Шартлы буяу-оттиск 20,39. Нәшер-хисап табагы 12,45+форз. 0,29.
Тиражы 3000 экз. Заказ Я-99.

Татарстан китап нәшрияты.
420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул.Баумана, 19.
**http://tatkniga.ru E-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы
дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.